ЧҮПТӘН ФАЙДА
Казан читендәге Самосырово полигонын юк итеп, анда җыелган газдан энергия алырга җыеналар
> 2

МОРАТ ӘҮЕЗОВ:
«Тамырларыбызда татар каны акканын онытмыйбыз»
> 3

ЯСАЛМА КӨЧ
Нейрочелтәр ярдәмендә фәнни эш язу – уйдырмамы, чынбарлыкмы?
> 3

ХА-ХА-ХАНӘ
Булмас димә, кызык-мызык, фототөрткеләр – биредә
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 31 (28998) | Шимбә | 4 март | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

Нәтиҗә

АЛГАННЫ БИРӘСЕ БАР

Узган ел беренче тапкыр фермер хуҗалыкларында терлекләрнең баш саны кимегән, грант алганнары эшчәнлеген туктата, ә кайберләре, киресенчә, эшләргә кеше таба алмыйча азаплана. Авылның тоткасына әйләнгән, аны ничек тә саклап калырга тырышкан хезмәт кешеләрен тагын нәрсәләр борчый? Татарстан фермерлары, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары ассоциациясе корылтаенда шул хакта сөйләштеләр.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Сүзне проблемалардан башласак та, фермерларның уңышлары күбрәк. Ассоциация җитәкчесе Камияр Байтемиров китергән мәгълүматлар буенча, эре авыл хуҗалыгы оешмаларыннан аермалы буларак, фермер хуҗалыкларының чәчүлек мәйданнары арткан. Берничә ел эчендә мөгезле эре терлек саны да 30 процентка күбәйгән. Егерме ел дәвамында сыерлар саны һәм сөт күләме дә арткан. Әйтик, узган ел фермер хуҗалыкларында 700 мең тоннадан артык сөт савып алынган, бу – республикадагы гомуми күрсәткечнең 38 проценты. Грант алган фермерлар ташландык хәлдә булган җиләк-җимеш бакчаларын яңартырга тотынган, беренче тапкыр республикада балык үрчетә һәм кара уылдык җитештерә башлаганнар.

Тик авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров сүзләренчә, узган ел беренче тапкыр фермер хуҗалыкларында мөгезле эре терлек саны 1,3 мең башка кимегән. Сыерлар – 148, сарыклар 2,8 мең башка азайган.

– Шулкадәрле ярдәм ала торып, фермерларда терлек саны кимү булырга тиеш түгел. Узган ел гына аларга 1,4 млрд сум акча бирелде. Моннан тыш, фермерлар эре авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре белән беррәттән, башка төрле ярдәм чараларыннан да файдаланды. Иң зур ярдәм – фермерларга һәм кооперативларга грантлар. Узган ел 92 фермер 546,3 млн сум грант алды, – дип шелтә белдерде министр.

Аның фикеренчә, хуҗалыкларда терлек саны кимүнең төп сәбәбе – грант алып биш ел узгач, эшләрен туктатучы фермерлар. Марат Җәббаров китергән мәгълүматлар буенча, ун ел эчендә фермерлар 4,4 млрд сумга 1556 грант алган. Аларның 264е (17 проценты) эшчәнлеген туктаткан.

– Монда районнардагы фермерлар ассоциацияләре башлыклары да бар. Эшен туктаткан һәр фермер буенча сәбәпләрен ачыклауны сорыйбыз. Шулай ук бүген эшләүчеләренең проблемаларын да игътибарсыз калдырмасагыз иде. Аларның гозерләрен, теләкләрен министрлыкка һәм фермерлар ассоциациясенә җиткерегез. Фермерның грант алуы гына түгел, ә аның эшләве һәм үз бизнесын уңышлы алып баруы, аны балаларына һәм оныкларына тапшыруы мөһим, – диде министр.

Шул ук вакытта Камияр Байтемиров грант күләмнәрен арттырырга кирәклеген әйтте. Аның сүзләре буенча, бүген грантларга сорау 4 тапкыр артып китә.

– Мин каршы түгел, хезмәттәшләр, – дип мөрәҗәгать итте Марат Җәббаров залда утырган фермерларга һәм күп очракта тәнкыйтьләгәнче, проблеманы чишү юлларын тәкъдим итәргә өндәде. – Тик әйдәгез әле проектларны тагын бер кат карап чыгыйк. Алар арасында төрлеләре бар. Кайберләре чиле-пешле килеп чыккан. Никадәр акча кирәклеген аңлар өчен проектларны төгәлләштерергә кирәк. Әйе, килешәм, дөресен әйткәндә, соңгы вакытта ниндидер бүленеш бар. Министрлык – үзенә, ассоциация үзенә сукмак салды. Ләкин киләчәктә без берләшеп, бергә атларга, үсәргә тиеш. Продукцияне арттырырга, эшкәртү цехлары, заводлар төзергә кирәк.

Корылтайда фермерларның үзләреннән арткан ашлыкны сату проблемасы да күтәрелде.

– Узган ел фермерлар мул уңыш – 1 млн 301 мең тонна ашлык җыеп алды. Тик алар аны сата алмый. Бу хәл узган көздән үк килә. Бүген фермер хуҗалыклары амбарларында 6 миллиардтан артык сумлык ашлык җыелып ята. Бу проблеманы никадәр тизрәк хәл итсәк, язгы кыр эшләренә дә тизрәк әзерләнә башлар иде, – диде Камияр Байтемиров.

Бу мәсьәләгә карата залда утырган фермерлар арасында ук каршылыклы фикерләр әйтелде. Теманың җитдилеген исәпкә алып, газетабызда бу хакта тулырак язарбыз.

Фермерлык – саннарда

- Узган ел хуҗалык итүнең күче формалары 142,9 млрд сум җыелма авыл хуҗалыгы продукциясе җитештергән. Аның 35,6 млрд сумы фермер хуҗалыкларына туры килә.
- Хәзерге вакытта фермерларның 740 мең гектар җире бар. Бу – барлык чәчүлек мәйданнарының 25 проценты дигән сүз.
- Узган ел фермер хуҗалыклары 1,3 млн тонна бөртекле культуралар җыеп алган. Бу – барлык уңышның 25 проценты дигән сүз.
- Шәхси хуҗалыклар белән бергә фермерлар 822 мең тонна (89 процент) бәрәңге үстерә.
- 2021 ел белән чагыштырганда, былтыр алар 9 мең тоннага күбрәк (үсеш – 5 процент) – сөт, 376 тоннага күбрәк ит (1,5 процент) җитештергән.

Әниләр һәм бәбиләргә

Казанда август азагында 7 нче шәһәр хастаханәсе базасында перинаталь үзәк ачылачак. Башкала мэриясенең матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, үзәктә һәр ел саен 8 мең йөкле хатын-кызны кабул итү мөмкинлеге булачак.

Үзәк 7 катлы яңа бинада якынча 20 мең квадрат метр мәйданны биләргә тиеш. Бина тиздән төзелеп бетәчәк. Анда 120 урын булдырылачак.

Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков әйтүенчә, перинаталь үзәк гап-гади бала тудыру йорты гына булмаячак. Биредә шулай ук төрле чирләрдән интегүче йөкле хатын-кызларга медицина хезмәтләре күрсәтеләчәк, аларга кирәкле барлык тикшеренүләр үткәреләчәк.

Моннан тыш үзәктә йөкле хатын-кызларга яралгы үсешендә кимчелекләрне ачыклау өчен УЗИ тикшеренүләре узу мөмкинлеге ачыла. Гадәттән тыш очраклар өчен шоктан чыгару һәм реанимация бүлекләре булачак.

Перинаталь үзәк әлегә 21 процентка әзер. Инде хәбәр ителгәнчә, яңа перинаталь үзәк Татарстанга 942,9 миллион сумга төшәчәк.

Паркларга – миллионнар

Татарстанда парк-сквер, яр буе кебек 19 иҗтимагый киңлекне төзекләндерүгә республика бюджетыннан 793 миллион сум акча тотылачак. Дәүләт сатып алулар сайтында бу җәһәттән тиешле тендер урнаштырылган. Анда әйтелгәнчә, иң күп акча Чаллының Табеев исемендәге яр буен (154 миллион сум) һәм «Яр буе» паркын (151 миллион сум) төзекләндерүгә тотылачак.

Әгерҗедә Ленин паркын яңарту өчен – 19,5 миллион сум, Азнакайда Кара елга һәм Мәнәвез елгасының яр буйлары өчен – 12,5 һәм 21,5 миллион сум, Әлмәттә Фәхретдин исемендәге бульвар өчен – 22 миллион сум, Болгар урамындагы шәһәр күле өчен – 98 миллион сум акча тотылачак. Шулай ук Актанышта Иске Идел күленең яр буе, Түбән Камада мәктәп бульвары, Минзәләдә Ленин исемендәге парк һ.б.лар төзекләндереләчәк.

Язын да киләчәкләр

Татарстанда язгы авыл хуҗалыгы ярминкәләре 18 мартта башланыр һәм 22 апрельгә кадәр дәвам итәр дип көтелә. Анда, гадәттәгечә, җирле фермерлар һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре чагыштырмача арзан бәядән үзләренең продукциясен сатарга ниятли.

Узган ел язгы һәм көзге ярминкәләрдә барлыгы 2,1 млрд сумлык продукция сатылган. Авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре шәһәр халкына 18 мең тоннадан артык яшелчә, шул исәптән 11 мең тонна бәрәңге, 4 мең тонна чамасы суган, 2600 тонна ит, шул исәптән 1500 тонна сыер ите, 360 тонна сөт, 3,5 миллион данә тавык йомыркасы, 1265 тонна шикәр комы, 882 тонна он алып килгән.

Авыручылар арта

Татарстанда икенче көн рәттән коронавирус йоктыручылар саны арта. Соңгы тәүлектә 153 кеше (алдагы көнне – 142) чирләгән. Стопкоронавирус.рф порталы мәгълүматларына караганда, моңа кадәрге 6 көндә чир очраклары кимегән: 24 февральдә 160 булса, 1 мартта 133 очрак теркәлгән. Ике көн рәттән 44 кешене хастаханәгә салганнар.

Пандемия башланганнан бирле Татарстанда барлыгы 198790 кеше коронавирус йоктырган. 195088е савыккан, шул исәптән соңгы тәүлектә – 98.

Республикада коронавирус инфекциясеннән вафат булучыларның гомуми саны, элеккечә үк, 2010га тигез. Соңгы тапкыр үлем-китем турында 20 гыйнварда хәбәр ителгән иде. Гомумән алганда, Россиядә бер тәүлек эчендә 14516 кеше чир иярткән. 1546сы хастаханәләргә озатылган. Соңгы тәүлектә ил буенча 40 кешенең гомере өзелгән.

Сак бул!

Ышанма сүзенә

Уяу булыгыз! Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсендә халыкны шулай дип кисәтәләр. Ник дигәндә, соңгы арада мошенниклар, үзләрен шушы министрлык вәкилләре дип таныштырып, янгын турында хәбәр итүче җиһазлар урнаштырырга тәкъдим итә башлаган.

Depositphotos.com

Мошенниклар халыкны төп башына утыртуның яңа алымнарын табып кына тора. Кырын эшкә тотынганда аларның үзләрен полиция, банк, прокуратура хезмәткәре дип таныштыруларына иярләшеп беттек инде. Соңгы арада исә алар «коткаручы»лар исеменнән эш итә башлаган.

Үзен Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәре дип таныштырган мошенник, өйдән-өйгә йөреп, хуҗаларны янгын турында хәбәр итүче җиһаз урнаштырырга үгетли. Бу җиһазның ни-нәрсә икәнен, янгын кебек афәттән ни дәрәҗәдә нәтиҗәле саклавы турында ишетеп-белеп торабыз. Шуңа күрә махсус ведомство «вәкиле»нең бу җиһазны урнаштырырга тәкъдим итүе беренче карашка бернинди шик тә уятмаска мөмкин. Әмма белгечләр бу урында сак булырга чакыра. «Безнең белгечләр беркайчан да өйдән-өйгә кереп, ниндидер җиһаз сатып йөрми, андый түләүле хезмәтләр күрсәтми», – диелә министрлык хәбәрендә.

Сезнең каршыда мошенник басып торганын аңлау өчен, ул тәкъдим иткән җиһазның бәясенә дә игътибар итәргә кирәк, ди алар. Ник дигәндә, кырыгалдарлар 500 сумлык шушы җиһазны, ун тапкыр арттырып, 5 мең сумга тәкъдим итә. Юкса теләге булган кеше бу җиһазны үзе дә сатып алып куя ала. Бүген күп кенә кибетләрдә, шул исәптән интернет-кибетләрдә дә сатыла. Рәсми саннарга караганда, узган ел әлеге җиһаз ил күләмендә 1175 кешене янгыннан саклап калган.

Гадәттән тыш хәлләр министрлыгында, якын арада Россиядә коткаручылар исеменнән алдауның тагын бер ысулы таралырга мөмкин, дип кисәтәләр. Калининградта шундый беренче очрак теркәлгән инде. Биредә яшәүче 50 яшьлек ир-атка үзен шушы ведомство хезмәткәре дип таныштырган бер хатын-кыз шалтыраткан. «Халыкны эвакуацияли калсалар, кирәк булачак», – дигән сылтау белән аннан милке, аерым алганда, машинасы турында мәгълүмат сораган. Ир-ат үз исемендә бернинди машина да исәпләнмәвен әйтүгә, «белгеч» тизрәк саубуллашу ягын карый. Җилнең кайсы яктан исүен чамалап алган ир-ат бу хакта шундук полициягә хәбәр иткән.

«Мондый шалтыратулар илнең башка төбәкләрендә яшәүчеләргә дә килеп ирешергә мөмкин. Мондый шикле затларга үзегез турында шәхси мәгълүматны әйтмәгез. Россиянең Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы шалтырату яки электрон почтага хат юллау ысулы белән кеше турында шәхси мәгълүмат җыю белән шөгыльләнми», – диелә министрлык хәбәрендә.

Сүзгә-сүз

council.gov.ru

Валентина МАТВИЕНКО, Федерация Советы Рәисе:

Үсеп килүче буынга мөстәкыйль фикерләү культурасын сеңдерергә кирәк. Моның өчен махсус методика кирәкме, аерым фәнме – бу хакта фикер алышасы булыр. Укучы әзер белем алгач, ул яңа нәрсәләр эзләргә, фаразлар ясарга, аларны тикшерергә һәм нәтиҗәләр ясарга өйрәнми.

(«Парламентская газета»дан)

ИҢ МАТУР ШӘҺӘРЛӘР

Tvil.ru хезмәте кышкы чорда иң матур шәһәрләр исемлеген төзегән. Исемлеккә Татарстан башкаласы да кергән. Мәскәү һәм Санкт-Петербургны рейтингтан махсус төшереп калдырганнар.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ



Наил ШӘРИФУЛЛИН

Боливарга көрлек теләгәндә...

«Боливар ике кешене күтәрә алмый» («Боливар двоих не вынесет»). О Генри хикәясеннән кулланышка кереп калган шундый канатлы гыйбарә бар. Боливар – ат исеме. Ягъни атка ике кеше атланып ерак китеп булмый. Ә бәлки буладыр? Ат дигәнең көр, чыдам булса.

Инде килеп, ул икәвенең кемнәр икәнен ачыклыйк. Аның беренчесе – көчәеп, ресурсларны үзенә көннән-көн күбрәк җәлеп итеп торган оборона сәнәгате. Икенчесе – калган барлык төр җитештерүне, хезмәт күрсәтүне үз эченә алган халык хуҗалыгы. «Оборона сәнәгатенә аерым игътибар халык куллану товарлары, азык-төлек җитештерүгә зыян салмаячак». Бу – ил җитәкчелеге авызыннан әйтелгән: «Мы не будем действовать по принципу «Пушки вместо масла», – дигән җөмләнең ирекле тәрҗемәсе. Мондый белдерү яхшыны – «ил икътисады» дигән атның ике юнәлешне дә күтәрәчәген, ягъни халыкның тормыш сыйфатын билгели торган өлкәләрнең «ат»тан төртеп төшерелмәячәген аңлата. Ягъни борчылыр сәбәп юк, «туп»ларны гына түгел, «май»ны да тиешле күләмдә җитештерәчәкбез.

Әлеге сүзләрне ишетүгә, Такташ шигырендәгечә, күңелдә «ике мин» туып, аң икегә аерылып ала. Аның беренчесе ил икътисадының көрлегенә нык шикләнсә, икенчесе оптимистик рухта калып, «Бары да яхшы булачак, илдә акча да, ресурслар да җитәрлек», – дип тынычландыра. Кайсы «мин»нең хаклы, кайсының юк икәнен, ихтимал, алдагы бер-ике ел төгәл әйтеп бирер. Тормыш сыйфаты билгеле бер кысадан чыкмый, бөтенләй үк аска тәгәрәми икән, димәк, оптимист «мин» дөрес фаразлаган. Башкача була икән – пессимист җиңәчәк. Тик «пессимист ул – мәгълүматлы оптимист» дигәнне дә онытып бетерергә ярамый.

Тупмы, маймы, әллә инде икесе дәме дигәндә совет чорының соңгы еллары күз алдына килә – күрдек без аларны. «Май» шартлы сүз, әлбәттә. Тик менә шул май, әле тагын ит, колбаса ише товарлар талонга булган заманнар искә төшә. Ни өчен талонга? Билгеле инде – җитмәгәнгә. Азык-төлек кенә түгел, көнкүреш товарлары, кием-салым, башкасына да кытлык булган елларны өлкән буын яхшы хәтерли. Андый хәлнең сәбәпләре дә билгеле. Алар арасында беренче урында, мәгълүм ки, корал кою, «салкын сугыш» дип аталган тарткалаш торды. Сиксәненче елларга кергәч, совет икътисадының җелеген тагын нәрсә суырды, дигән сорауга, Әфган сугышы, дисәк, ялгышырбыз. Хәлне бераз алса да, партизаннарга каршы көрәш баштанаяк коралланган ике армиянең ачыктан-ачык чәкәләшүе түгел. Җелек суыручы – АКШның 40 нчы Президенты Рональд Рейган гамәлгә ашырырга тотынган СОИ (Стратегик оборона инициативасы) программасына җавапка киткән чыгымнар иде. Орбитага меңгерелгән йөзәрләгән хәрби иярченнең АКШ күген корыч калкандай саклаячагы СССР җитәкчелеген пошаманга салып, күптин-күп миллиардлар «асимметрик җавап» хәстәрләүгә китте. Боливар дигәнебез икенче җайдак – кеше ихтыяҗларын үти торган юнәлешләрне бөтенләй күтәрә алмый башлады. Белүебезчә, хәл аның белән генә дә бетмәде...

Россия халкының Көнбатыштагы кавемнәрдән аермасы шунда: ул түзем, таләпсез. Әмма барыбер бүгенге россияле талонга да яшәргә риза совет кешесе түгел. Чагыштырмача яхшы тормышны күргәннән соң кире фәкыйрьлеккә кереп китүне ул авыр кичерәчәк. Ул гынамы. Тормыш сыйфаты түбәнәю ватанпәрвәрлек градусын да шактый түбәнәйтергә мөмкин. Монысы исә власть өчен үтә дә җитди, хәлиткеч фактор. Әлегә ул сыйфат тиешле дәрәҗәдә булып, хакимият тә, нотыкларына караганда, күтәренке рухта.

Югары җитәкчелектәге оптимизм әйбәт, әлбәттә. Аларга мәгълүмат ирештерүче бераз түбәнрәк баскычта торганнар да, ихтимал, оптимистлардыр. Оптимист булмаганда да алар югары власть коридорларына нииндидер негатив белән керергә, беренче җитәкчеләрнең кәефен төшерергә күнекмәгән. Чөнки негатив тудырган өчен беренче чиратта син үзең җаваплы. Бәлки шул сәбәпледер, статистика белән мәгълүмат чаралары да, зурдан алганда, оптимизм чыганагы. Әмма тәнкыйтьне кабул итми, негативны күрми яшәү үз-үзебезгә, өлкән туган әйтмешли, «аю хезмәте» күрсәтү булмасмы? Бит кайсы тармакны гына алма, аның җитәкчесе хәлләрне яхшы дип, ал да гөл, дип бәяли. Россия дигән ил тарихында барысы да ал да гөл булган заманнар гомумән күп күзәтелде микән?

Февраль урталарында Росстат 2007–2022 еллардагы тормыш сыйфатының динамикасы буенча мәгълүмат чыгарды. Ул куанычсыз. Алсу күзлеген салырга бик яратмаган Росстат исәпләп чыгарган сан – 1 процент! Ягъни 15 ел эчендә халыкның тормыш дәрәҗәсе азга булса да барыбер яхшырган булып чыга. Тик 15 ел ул бит, яңадан совет чоры белән чагыштырып сөйләшкәндә – өч бишьеллык дигән сүз. Хәтта ул дәвердә дә, бер бишьеллык эчендә дә, андый түбән үсешне күз алдына да китереп булмаган. «Экономист» журналы баш редакторы, МГУ профессоры Сергей Губанов ул процентка да ышанмый. Галимнең сүзләре буенча, процент дөрес булган очракта да андый сан – ил икътисадына хөкем карары.

Илдә икътисадны хәрәкәтләндерүче, куалаучы көчләр, механизмнарның нык җитенкерәмәве ачык. Чикләүләр булганнарын да зәгыйфьләндерде. Көчләрне генә түгел, икътисад белән сәнәгатьнең үзен дә. Автопромның җиңел машиналар җитештерү дигән өлешенең 60–70 процентка «утыруы» бүген инде беркемгә дә сер түгел. Ул тармакта без тагын гадиләштерелгән технологияләргә кереп киттек, үткәнгә кайттык. Авиация сәнәгате дигәндә, гомумән, билгесезлек. Тармак җитәкчеләре кайсы баштан тотынырга белмичә аптырый. Микрочиплар килми башлау аркасында биометрик паспортлар бирүне туктату (башканы әйткән дә юк) электроника өлкәсендәге «казаныш»ларны ачып сала. Акчага, әйе, аптыраган юк. Запас та бар, элекке күләмдә үк булмаса да, чимал да сатыла, акмаса да, әлегә яхшы тама. Тик акча авиалайнер түгел, аңа утырып очып булмый. Сәмәнне «тимер»гә әйләндергәнче озын-озак технологик юл үтәсе. Ә без технологияләр белән дә, сәнәгать белән дә дус була белмәдек...

Бүгенге чынбарлык икътисадка да, сәнәгатькә дә яңа төзәтмәләр кертте – бүген оборона өлкәсен ныклап камчылыйсы. Икътисад дигән ат ул юнәлешне күтәрер дә, тик барыбер билгеле бер авырлык белән. Технологик артталык, сәнәгатькә игътибарсызлыкның илдәге күпчелек бәлаләрнең сәбәпчесе булуын соңга калып булса да аңладык кебек. Тик ул ялгышны хәзер ничек төзәтергә?

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ЭШЛЕКЛЕ ДҮШӘНБЕ

Ил өчен дә, республика өчен дә әһәмиятле сәфәр. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның Россия делегациясе составында Таҗикстанга эш визитын әнә шулай бәяләргә мөмкин. Яклар илкүләм дәрәҗәдәге очрашулар гына үткәреп калмыйча, Татарстан үз мөмкинлекләрен дә тәкъдим итте. Таҗикстан Президенты Эмомали Рахмонны бу язда ук Казанда көтәләр.

tatarstan.ru

Инде хәбәр иткәнебезчә, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Россия Хөкүмәте Рәисе Михаил Мишустин җитәкчелегендәге ил делегациясе составында чит илгә сәфәр кылды. Биредә ул пәнҗешәмбе көнне «Россия һәм Таҗикстанның эшлекле һәм инвестицион партнерлыгы» төбәкара хезмәттәшлек буенча тугызынчы конференциянең пленар утырышында катнашты.

Кичә исә Рөстәм Миңнеханов Таҗикстан Президенты Эмомали Рахмон белән очрашты. Былтыр ике арада товар әйләнеше 30,7 миллион доллар тәшкил иткән. Алдагы ел белән чагыштырганда, әлеге күрсәткеч 57 процентка үскән. Хезмәттәшлекне ныгыту өчен мөмкинлекләр дә күп. Эш юнәлешләре турында Рөстәм Миңнеханов пленар утырышта ук әйткән иде. Мәсәлән, республика Таҗикстанга вертолетлар, йөк машиналары җибәрергә әзер. «КАМАЗ» ГАҖнең Душанбедә арадашчысы да бар. Ике яклы очрашу барышында Эмомали Рахмон сәүдә-икътисадый һәм гуманитар багланышларны үстерүгә теләкләре барлыгын әйтте.

Рөстәм Миңнеханов «Россия – Ислам дөньясы» стратегик төркеме эшенә дә аерым тукталды. «Без сезнең илнең эш төркеме эшенә керткән өлеше өчен рәхмәтлебез», – диде Рәис. Форсаттан файдаланып, ул Эмомали Рахмонны быелның 18–19 маенда Казанда узачак «Россия – Ислам дөньясы: Kazanforum» җыенына чакырды.

Таҗикстанда Рөстәм Миңнеханов ил Премьер-министры Кохир Рәсүлзадә белән дә очрашты. Яклар хезмәттәшлекне үстерү турында фикер алышты. Рөстәм Миңнеханов Премьер-министрга Татарстан – Таҗикстан хезмәттәшлегенә күрсәтелгән игътибары өчен рәхмәт әйтте. Бергәләп эшләү өчен өстенлекле юнәлешләр арасында машина төзелеше, авыл хуҗалыгы, сәламәтлек саклау һәм мәгълүматлаштыру тармакларын билгеләп үттеләр.

Кохир Рәсүлзадә 2021 елның апрелендә Евразия хөкүмәтара советының чираттагы утырышында катнашу өчен Казанга килүен искә алды. Ул икътисадый хезмәттәшлекне арттырырга әзер булуын белдерде. Мондый очрашуларның ике як өчен әһәмиятен дә билгеләп үтте. Таҗикстанга Татарстан делегациясе составында республиканың сәнәгать предприятиеләре һәм кече компанияләре җитәкчеләре барды.

Сайлау мөмкинлеге

Алда зур сайлаулар көтә. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның яшь сайлаучылар, «Атмосфера» мәгариф проектында катнашучылар, КФУ карамагындагы Сайлау хокукы мәктәбе тыңлаучылары, блогер, волонтерлар белән очрашуында шул хакта сүз барды. Очрашуда Фәрит Мөхәммәтшин республикада сайлау системасын үстерү һәм парламентның әлеге процесстагы роле турында сөйләде.

Парламент Рәисе очрашуны «бик мөһим һәм вакытлы очрашу» дип бәяләде. «Озакламый яңа зур сайлау циклы башлана, – дип билгеләп үтте ул. – 2024 елда Россия Президентын сайлау булачак, шуннан соң җиденче чакырылыш Дәүләт Советы депутатларын, 2025 елда – республика Рәисен һәм вәкиллекле җирле үзидарә органнарын, 2026 елда тугызынчы чакырылыш Дәүләт Думасын сайлау узачак. Инде быел май аенда Дәүләт Советына өстәмә сайлау көтелә. Барлык шушы сайлау кампанияләренә җитди әзерләнергә, шул исәптән кадрлар барларга, яшьләрне актив төстә җәлеп итәргә кирәк».

Үзәк сайлау комиссиясе мәгълүматларына караганда, алдагы сайлау кампанияләрендә 850 меңнән артыграк егет-кыз катнашачак. Шуның 86 мең чамасы сайлау участокларына тәүге тапкыр киләчәк. «Бүгенге очрашуда катнашучыларның күбесе алга таба кандидатка әйләнеп куярга мөмкин. Бездә яшьләрнең әзерлекле булуларына, актив гражданлык позициясендә торуларына шатмын. Бүген без башлыча яшьләргә таянабыз», – диде парламент җитәкчесе.

Фәрит Мөхәммәтшин республикада парламентны булдыру һәм үстерү мәсьәләләренә аерым тукталып үтте. «Парламент һәм сайлау – сәяси системаның үзара бәйләнгән ике элементы, – диде ул. – Парламентның сыйфаты депутатлар составына бәйле. Ә бу, үз чиратында, сайлау процессында булдырыла. Парламентта төрле сәяси партияләр һәм төркемнәр үзара уртак тел таба, бөтен халык мәнфәгатендә күпчелекнең фикере исәпкә алынып, карарлар кабул ителә».

Очрашу барышында яшьләр сайлау алды процессын камилләштерү буенча үз проектлары һәм тәкъдимнәре белән таныштырды. Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе Андрей Кондратьев әйтүенчә, хәзерге вакытта яшьләр арасында байтак кына шундый проектлар гамәлгә ашырылып килә. Шуларның берсе – инде берничә ел КФУ карамагында эшләп килүче Сайлау хокукы мәктәбе. Хәзерге вакытта мәктәп тыңлаучылары булып асылда Казан университетының юридик факультеты студентлары тора. Проектка карата кызыксыну зур. Шуңа күрә Дәүләт Советы Рәисе белән очрашуда аны вузлар арасындагы проектка әйләндерү тәкъдиме күтәрелде. Фәрит Мөхәммәтшин тәкъдимне хуплады.

Тагын бер проект – «Атмосфера» мәгариф программасы. Аның максаты – сайлау системасының яшьләр активын булдыру. Казан студентлары һәм мәктәп укучылары шулай ук сайлау хокукы буенча Бөтенроссия олимпиадалары һәм бәйгеләрдә катнаша.

УКЫТУЧЫЛАРГА – НОУТБУК

Республика Рәисе Рөстәм Миңнеханов Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллинга республика укытучылары өчен 12 мең ноутбукка сертификат тапшырды. Узган ел да педагогларга шуның кадәр җиһаз бирелгән иде. Бу әле соңгысы түгел.

Дәресне кызыклы итеп оештырам, дисәң, заманча техникадан башка булмый бүген. Укучылар интерактив җиһазлар ярдәмендә бирелгән мәгълүматны җиңел һәм тиз кабул итә. Казанның 187 нче гимназиясендә математика һәм информатика фәннәре укытучысы Камил Абдулвахобов та шулай ди. Әлеге техника аларның эшен ни дәрәҗәдә җиңеләйтә?

– Безнең уку йорты яңа әле. Шулай булгач, укытучылар кирәк-ярак белән тәэмин ителгән, ноутбукларга мохтаҗлык юк, – ди Камил Абдулвахобов. – Укытучыларга техник кирәк-ярак тапшыруны хуплыйм. Ноутбук ул – безнең өчен алыштыргысыз эш коралы. Беренчедән, дәресне кызыклы итеп уздыру, икенчедән, белемне арттыру, алга таба үсеш өчен кирәк. Бүген яшьме, өлкән укытучымы – цифрлы грамоталы булу кирәк. Һәр яңа теманы интерактив рәвештә бирергә тырышам. Атнага биш тапкыр кергән математика дәресенең өчесендә – мәгълүмати технологияләр, икесендә исә совет традицион формасы алымнарын кулланам. Ни өчен дигәндә, балаларның язу, санау күнекмәләрен дә үстерергә кирәк.

Мамадыш районы мәгариф бүлеге башлыгы Илдус Габдрахманов белдергәнчә, быелгы уку елы башында мөгаллимнәргә 570 ноутбук тапшырганнар.

– Авыл һәм шәһәр мәктәпләренә тараттык. Укытучылар бик сөенеп кабул итте. Ул эш урынында торырга тиеш. Әмма аларга өйләренә дә алып кайтырга рөхсәт итәбез. Бу – аларга зур бүләк. Яңа партия ноутбуклар турында исә киләсе җыелышта әйтерләр дип уйлыйм, – диде ул.

Чүпрәле районы мәгариф идарәсе башлыгы Илсур Халитовның да фикерен сораштык.

– Районда барлыгы 385 укытучы белем бирә. Хәзерге вакытта барлык укытучылар да ноутбуклар белән тәэмин ителгән. Техника гел яңартылып тора. Узган май аенда 225 ноутбук алган идек инде. Бездә яше дә, өлкәне дә аны куллана белә, – диде Илсур Халитов.

Биектау районының Дөбьяз мәктәбе директоры Ринат Хәсәнов әйтүенчә, мәктәпкә ел саен 3–5 ноутбук бирелә.

– Бу яктан проблема юк. Ватыла барган саен, яңаны биреп торалар. Минем ноутбук 11 елга чыдады, – ди Ринат Хәсәнов.

Сәрия МИФТАХОВА

Сан

Татарстан мәгарифен үстерү «Киләчәк» стратегиясе кысасында 2010–2018 елларда укытучыларга 1,6 миллиард сумлык 91 мең 878 ноутбук өләшенгән. Узган ел исә 480 миллион сумлык 12 мең шундый җиһаз сатып алынган.

Белдерү

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе быел 28 майда Татарстан Дәүләт Советына өстәмә сайлау һәм муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларын өстәмә сайлау үткәреләчәге турында хәбәр итә.

Татарстан Республикасы территориясендә Татарстан Дәүләт Советына өстәмә сайлауда һәм муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларын өстәмә сайлауда катнашуга хокуклы сәяси партияләр, сәяси партияләрнең, гомумроссия иҗтимагый берләшмәләрнең төбәк бүлекләре, җирле иҗтимагый берләшмәләр турында мәгълүматлар идарәнең «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтына (адресы: https://to16.minjust.gov.ru/ru/pages/vybory-v-rossijskoj-federacii) урнаштырылган.

ТИК ЯТМАСЫН ЧҮП

Әйләнә-тирәлек

Казан читендәге Самосырово полигонын юкка чыгарып, анда җыелган газдан энергия алырга җыеналар. Хәзерге вакытта биредә «Экология» илкүләм проектының «Чиста ил» федераль проекты кысасында рекультивацияләү эше бара. Бу эш 2021 елда башланды. Моның өчен 870 миллион сум акча бирелгән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Миллионлаган тонна чүп җыелган бу урынны киләчәктә агач һәм куаклар утыртылган яшел калкулык итеп күз алдына китерәләр. Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры Александр Шадриков әйтүенчә, чүплекне рекультивацияләү эшләре быелның июнендә тәмамланачак.

– Черегәннән соң барлыкка килгән газны чыгару өчен торбалар урнаштырырга да мөмкин. Ләкин без аннан электр энергиясе алырга ниятлибез. Безнең идеяне «Татнефть» оешмасы да хуплады, алар технологияләрне сайлау буенча фәнни-тикшеренү эшен финансларга әзер, – ди Александр Шадриков.

«Татнефть» һәм «Промбиогаз» белгечләре белән берлектә министрлыкның фәнни-техник советы биш технологияне барлаган. Сыгылмалы скважиналар полигоннан биогазның 95 процентын җыя һәм электр өчен кулланырга мөмкинлек бирә.

Россия өчен бу эш сынау проекты булып санала. Самосырово полигоныннан чыккан газдан 20–25 ел дәвамында энергия алып булыр дип фаразлыйлар.

– «Чиста ил» проектына алмашка «Генеральная уборка» федераль проекты килә. Инвентаризация нәтиҗәләре буенча, республикада чүпкә баткан 21 объект барлыгы ачыкланды. Бер чүплекне бетереп, яңасы килеп чыкмас дип әйтеп булмый. Эшлисе дә эшлисе безгә, – ди министр. – Узган ел республикада яшәүчеләрдән килгән зарларның 67 проценты чүплекләргә бәйле иде. Рөхсәтсез чүп ташланган 3772 урынны ачыкладык. Аларның 99 проценты юкка чыгарылды. Калдыкларның вакытында ташланмавы да бик борчый. Чүп чыгару оешмалары эшләрен җиренә җиткереп башкармый. «Салават Күпере» торак комплексындагы сасы иснең дә полигоннан чыкканын ачыкладык.

Сүз уңаеннан, халыкның зарларын тыңлагач, экологлар бирегә атмосфера һавасының сыйфатын автомат рәвештә анализлый торган махсус станция урнаштырды. Бу автоматик станциядә углерод оксиды, аммиак, азот оксиды, азот диоксиды, водород сульфиды һәм күкерт газы кебек төп пычраткыч матдәләрне контрольдә тоту өчен газ анализаторлары бар. Якын киләчәктә станцияне атмосфера һавасында хуш исле углеводородларны билгеләү буенча автоматлаштырылган хроматография комплексы белән җиһазландыру планлаштырыла.

Автоматик контроль станциясе урыны Казанның атмосфера һавасын пычрату буенча җыелма исәпләүләр нигезендә һәм «Салават Күпере» торак комплексында яшәүчеләр мөрәҗәгатьләрен исәпкә алып сайланган. Автоматик үлчәүләр һәм сайланган урыннар якындагы предприятиеләр һәм объектлардагы атмосфера һавасының сыйфатын онлайн режимда күзәтергә мөмкинлек бирәчәк. Бу предприятиеләр Федераль экологик күзәтчелеккә кертелгән, һәм, артулар теркәлгән очракта, мәгълүмат Росприроднадзорның Идел – Кама төбәкара идарәсенә тапшырылачак. Моннан тыш, атмосфера һавасына контрольне көчәйтү өчен, 1 марттан Роспотребнадзорның Лаборатория анализы һәм техник үлчәү үзәге күчмә автоматик лабораториясе күрсәткечләрен исәпкә алып, микрорайонның өч ноктасында тикшерү уздырыла башлады.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сан

2023 ел башыннан Татарстан Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына республикада яшәүчеләрдән 336 мөрәҗәгать килгән. Халыкны борчыган иң актуаль мәсьәлә булып һаваның сыйфаты тора. Шул уңайдан 192 мөрәҗәгать килгән. Калдыкларны законсыз җиргә ташлау буенча – 111 хәбәр, шуларның 24е карны тиешле урынга урнаштырмауга бәйле. Башка мәсьәләләр буенча (санитар халәт, файдалы казылмалар чыгару кебек) 33 мөрәҗәгать теркәлгән.

МОРАТ ӘҮЭЗОВ: «ҮЗЕМНЕ БИШЕКТӘ ЯТКАНДАЙ СИЗДЕМ»


«Татар-информ»

Шәхес

Бу хисләр, һичшиксез, тарихи ватан белән бәйле. Аның әнисе Фатыйма Габитова Казахстанның Семипалатинск шәһәрендә туып-үссә дә, үзен Казан татары дип йөртә. Мәгълүм сәбәпләр аркасында бу нәсел кайчандыр качып китәргә мәҗбүр була. Галим, дәүләт эшлеклесе, дипломат Морат Әүэзов Казанга бер төркем якташлары белән әтисе, бөек казах язучысы Мохтар Әүэзовның 125 еллыгын билгеләп үтәргә килде. Казахстанның Казандагы илчесе Ерлан Искаковның, казахлар һәм татарлар – бертуганнар, дигән сүзләре шигарь булып яңгырады.

Җыентык

Татарстан Милли китапханәсендә оештырылган бу очрашуда халык хозурына язучының Казан федераль университеты доценты Гөлфия Гайнуллина тарафыннан татар теленә тәрҗемә иткән китабы тәкъдим ителде:

«Мохтар Әүэзов – казахларның бик зур кешесе, классик язучысы, академик галиме. Совет заманында, бигрәк тә сугыштан соң, һәрбер милли әдәбиятта бердәнбер кеше иң беренче урынга куелды. Казахларда андый кеше Мохтар Әүэзов иде».

Казах акыны Абай Мохтар Әүэзовның иҗатында төп рольне уйный дисәк тә, ялгыш түгелдер. Аның макталулары да, кагылулары да, эзәрлекләнүләре дә нигездә шушы исемгә бәйле.

1897 елда Көнчыгыш Казахстанның Семипалатинск өязендә яшәп яткан күчмә казах гаиләсендәге бәби туу хөрмәтенә оештырылган мәҗлескә Абай Кунанбаев та килә. Бу малай Мохтар була. Абай да чит кеше түгел: әтисе Кунанбай Әүэз бабаларының сеңлесе Нурганымга өйләнгән. Шул көннән башлап, бу икәүнең тормышы бер-берсенә үрелеп бара.

1918 елда Мохтар Әүэзов Семипалатинскида «Абай» журналын чыгара башлый. Әмма басма сәяси сәбәпләр аркасында ябыла. Ул арада егет югары уку йортын, аспирантураны тәмамларга өлгерә. Репрессия дә урап узмый. Кулга алынып, ике ел ярымга хөкем ителә. Иреккә чыккач, фикердәшләре аңа атаклы туганы Абайның иҗатын тикшерүгә алынырга тәкъдим итәләр. 1933 елда ул Абай шигырьләренең – «Абай Кунанбай улы толык җинак» дип аталган беренче тулы җыентыгын чыгара. 1937 елда Казахстан ССР Язучылар берлегенең беренче пленумы була, анда Мохтар Әүэзовны нык тәнкыйтьлиләр, шуннан соң НКВД аның әсәрләрен тыя, китапханәдән алдырта, үзен эштән куалар. Ул Ленинградка качып китә. Әмма ниятеннән ваз кичми. 1941 елда Казахстанга әйләнеп кайткач, СССР Фәннәр академиясе Казах филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли. «Абай» романының беренче китабын нәшер итә.

1945 елда, Абайның 100 еллыгында, «Абай» операсының либреттосын, «Абай җырлары» нәфис фильмының сценариен, тәрҗемәи хәленең яңа вариантын яза. Мәскәүдә «Абай» китабы чыга. Аның өчен автор Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә. 1947 елда «Абай» романының икенче китабы казах телендә нәшер ителә, соңрак ике китап та Мәскәүдә рус телендә дөнья күрә. 1949 елда роман I дәрәҗә Сталин премиясенә лаек була, автор Хөрмәт билгесе ордены белән бүләкләнә. Шуңа да карамастан, ни өчендер (беренче чиратта көнләшү сәбәпче дип уйланыла), Мохтар Әүэзовны эзәрлекләүдән туктамыйлар, 1952 елда казах телендә «Абай юлы» дигән китап чыгуга, «Правда» газетасы аны «гражданлык сизгерлеге җитмәү»дә гаепләп чыга. Шундук профессорны «буржуаз-милләтчел хаталары өчен» университеттан эштән чыгаралар, күптомлык «Казах ССР тарихы»н язучы авторлар коллективыннан төшереп калдыралар. Кулга алынудан шикләнеп, язучы Мәскәүгә китә. Анда «Абай юлы» тетралогиясен тәмамлый. «Иностранная литература», «Дружба народов» журналлары мөхәрриятенә сайлана, Абай иҗаты турында чыгыш ясый. Шуннан соң Алматыга кайта, барлык эш урыннарында торгызыла. «Казах шигърияте антологиясе»н төзүдә катнаша, «Абай юлы»н тәрҗемә итүчеләр белән эшли.

60 яшендә Мохтар Әүэзов Ленин ордены белән бүләкләнә. Аңа Казах ССРның атказанган фән эшлеклесе исеме, «Абай юлы» дилогиясе өчен Ленин премиясе бирелә. 1957–1960 елларда Сәрвәр Әдһәмова «Абай» романының 1–2 томнарын тәрҗемә итә.

Муса Җәлил

Мохтар Әүэзов татар халкы өчен дә зур изгелек эшли: «Моабит дәфтәрләре» циклы өчен Муса Җәлилгә Ленин премиясен бирдертүгә ирешә.

1957 елның иң яхшы әдәби әсәрләре өчен премияләр бирү мәсьәләсе килеп тугач, СССР Министрлар Советы каршындагы Әдәбият һәм сәнгать комитеты иң лаеклы кандидатураны ачыклау буенча фикер алышулар уздыра. Мохтар Әүэзов Муса Җәлилне бүләкләүне таләп итеп чыгыш ясый. Шагыйрь иҗатын тәфсилләп бәяли.

«Моабит дәфтәрләре»н укыганда сез нининдидер өстәмә тойгыларның озата барганын – шигырьләрнең төрмәдә, шагыйрьнең «муенында элмәк» булган килеш язылганлыгын сизәчәксез, – ди Мохтар Омархан улы. – Әгәр дә премиягә бер генә исем лаек дип табылса да, ул Муса Җәлил булырга тиеш. Аның исән булмавы мөһим түгел. Ул яши һәм сугышның һәр каһарманы кебек үк, безнең белән киләчәктә дә яшәячәк. Ул кылыч йөзенә басып иҗат итә һәм анда хакыйкать ак карга тамган кан кебек ачык күренеп тора». Мохтар Әүэзов чыгышы иң үтемлесе була. Нәтиҗәдә югары премияне Муса Җәлилгә билгелиләр.

Безне татар үстерде

Әмирхан Еники истәлекләрендә Мохтар Әүэзов белән очрашуы хакында болай яза.

– Минем белән ул татарча дип әйтерлек сөйләште, һәр сүзен аңлап бардым. Ни гаҗәп, сүзен турыдан-туры татар әдәбияты, татар язучыларын мактаудан башлап китте. «Тукайлар, Галимҗаннар сезнең генә түгел, безнең дә беренче мөгаллимнәребез, – диде. – Безнең казахта бары татар әдәбиятында тәрбияләнеп үскән язучылар да бар». Шуларга өстәп, Мохтар ага, татарлар революциягә кадәр Россиядәге төрки халыклар арасында иң алдынгы халык иде, дигән бик кыю фикерен дә әйтте…

Әмирхан Еникинең шушы истәлекләре җиткерелгәннән соң төрки дөньяны өйрәнүче галим, профессор Хатыйп Миннегулов: «Чыннан да, Урта Азиядәге бик күп халыкларның мәдәнияте, әдәбияты бары тик татар зыялылары ярдәме белән генә дөньяга танылды. Әмма, ни кызганыч, бүген бу хакта инде онытылып бара. Үзбәкләрдә дә шул хәл. Казахлар да әллә ни искә төшермиләр», – дип үз фикерен белдерде. Зыялы кеше буларак, дөрес әйтмәсәм, гафу итәрсез, дип өстәп куярга да онытмады. Бу сүзләргә җавап бирүче табылмады.

Морат Мохтарович исә үзе очрашу вакытында күп вакытта татарча сөйләмгә күчте һәм моны әнисенең татар нәселеннән булуы белән аңлатты.

– Әнием бик белемле, гарәп, фарсы, немец телләрен яхшы белә иде. Без балачактан «Кара урман», «Эзләдем, бәгърем, сине» җырларын җырлап, Тукайның «Шүрәле»сен тыңлап үстек. Татар мәдәниятенә якын булу аны авырлыклардан коткарды, яшәргә көч бирде дип беләм. Әтием: «Аллаһ сезне шушы җирдә дөньяга китергән икән, димәк, шушы җирнең бәхете өчен көрәшергә тиешсез», – дип әйтеп килде. Аның әманәтен үтибез. Тамырларыбызда татар каны акканын да онытмыйбыз, – диде.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

БӘЙРӘМ МЕДАЛЬЛӘРЕ

Бердәмлектә – көч! Архангельск өлкәсендәге Малиновка бистәсендә «Чемпионнар биеклеге» илкүләм ярышы уза. 23 февральдә башланган ярышта илнең иң көчле чаңгычылары чыгыш ясый. Араларында дөнья чемпионы булып танылган, Олимпия Уеннарын откан спортчылар да бар. Алар белән ярышканда Татарстан спортчылары да югалып калмый. Бигрәк тә командалы ярышларда. Безнекеләр өч медаль яулады.

«Чаңгы юллары катлаулы, ә янәшәдә дөнья дәрәҗәсендәге «йолдыз»лар чаба! Әмма безнең кызлар югалып калмады», – дип мактады Татарстан кызларын республиканың Чаңгы узышлары федерациясе президенты Илшат Фәрдиев тәүге ярышлардан соң. Кызларның күңеле күтәрелеп китте, шуңа күрә нәтиҗәсе дә озак көттермәде. 26 февральдә узган спринт ярышында Татарстан спортчылары Анастасия Доценко белән Христина Мацокина финишка өченче булып килделәр. Алеся Рушенцева белән Виктория Трошина исә 13 нче урынны алдылар. Шул ук көнне егетләр дә спринт ярышына чыкты. Тик беренче команда – 10 нчы, икенчесе исә 14 нче урын белән канәгатьләнде. Федерация җитәкчелеге егетләргә тәнкыйтьне кызганмады.

Бу атнада узган эстафета ярышында кызлар нәтиҗәне тагын да яхшыртты. Ольга Сергеева, Лидия Горбунова, Виктория Трошина һәм Лариса Рясина финишка икенче булып килделәр. Ә Алеся Рушенцева, Дарья Непряева, Ольга Жолудева һәм Христина Мацокина бишенче урынны алдылар. «Бу медаль генә түгел. Безнең кызларның җиңүе белән Татарстанга яз килде. Ике командабыз да бердәмлеген күрсәтте. Кызларның күрсәткечләрен күрегез! Бу искиткеч саннар хәрәкәт барлыгын дәлилли. Безнең кызлар ярыштан-ярышка нәтиҗәсен яхшырта. Безнең кызлар иң чибәре, нәтиҗәләре тагын да матуррак. 8 Март алдыннан Татарстандагы барлык хатын-кызларга бәйрәм бүләге ясадыгыз», – дип сөенде федерация җитәкчесе Илшат Фәрдиев.

8 Мартка бүләкне егетләрдән дә көттеләр, әлбәттә. Тәнкыйть сүзләреннән соң бигрәк тә. Аңладылар һәм тизлекне арттырдылар. 3 февральдә узган эстафета ярышында Татарстан командасы медаль яулады. Андрей Ларьков, Сергей Ардашев, Иван Горбунов һәм Антон Тимашов финишка икенче булып килде. Дөньякүләм танылган Иван Якимушкин, Денис Спицовтан гына калышып! Ә безнекеләрдән артта командалардагы исемнәрне күрсәгез! Әйтик, өч мәртәбә Олимпия чемпионы Александр Большунов белән Александр Терентьев чыгыш ясаган Архангельск өлкәсе командасы Татарстан егетләреннән 3 минутка соңарды. «Матур һәм якты җиңү булды. Бөтен Татарстан һәм илнең башка төбәкләрендә яшәүче җанатарларыбызга рәхмәт! Сезнең ярдәмегез бик кирәк», – диде Илшат Фәрдиев. Безнең икенче состав исә финишка иң соңгы булып килде. Егылдылар, әмма туктап калмадылар. Димәк, Марсель Шәйхелисламов, Сергей Волков, Евгений Вахрушев, Денис Филимонов киләсе ярышларда көчлерәк булачак.

Мөнәсәбәт

«АЮ ХЕЗМӘТЕ»МЕ, ЗАМАНА ХИКМӘТЕМЕ?

Россия дәүләт гуманитар университет студенты Александр Жданов дипломын бер көндә язган. Үзе түгел, ChatGPT нигезендәге нейрочелтәр ярдәмендә. Аның «кырын» гамәлен хәтта Россия фән һәм югары белем бирү министры Валерий Фальковка да җиткергәннәр. Тик дәлилләр таба белгән студентның фәнни эшен юкка чыгармаганнар. Болайга китсә, яшьләр белем алуга бик җиңел карый башламасмы? Энә белән казылмаган сай коеның кирәге бармы?

– Ясалма интеллектның кеше хезмәтен алыштырмаганын беләм. Әлеге чат-бот фәнни хезмәтне язуның вакытын тизләтә, әмма төзәтмәләр кертүне таләп итә. Бу эшкә керешкәнче, башта план төзедем. Язып бетергәч, фәнни җитәкчемнең төзәтмәләрен керттем. Бу эшемә «3ле» алдым, – ди студент.

Артта калган мәгариф

Интернетта мондый мөмкинлекләр тудырылганга студентның гаебе бармы соң? Вуз мөгаллимнәре, студентлар бу хакта ни уйлый?

«Россия – мөмкинлекләр иле» Президент платформасының «Киләчәк укытучысы» бөтенроссия бәйгесендә җиңү яулаган, Иннополис мәктәбенең рус теле һәм әдәбияты укытучысы Айсылу Сәгыйтова да әлеге бәхәсле очрак турында ишеткәч, видеосын караган.

– Анда бу студент ни өчен мондый адымга баруының сәбәпләрен аңлата. Аның фикерләре бик төпле. Бу – диплом эшен яза алмыйча, аны нейрочелтәр тапшырган ахмак студент түгел. Ул чыгарылыш эшен язарга мөмкинлек бирә торган алгоритм төзегән. Һәм бу җиңел түгел. Иннополиста диплом язуның мондый очраклары турында ишеткәнем юк, – ди Айсылу Сәгыйтова.

Студентларның диплом язу өчен нейрочелтәргә мөрәҗәгать итүенә карата аның фикере болайрак.

– Технологияләр бик тиз үсә, без – моның шаһитлары. Интернет барлыкка килгәч, студентлар аннан мәгълүмат ала, ә аннары диплом эшләрен чыгарта (скачивать) башлады. Моңа җавап буларак, эшнең урланган-урланмаганын тикшерүче программалар барлыкка килде. Мөгаен, бу очракта да тора-бара нидер уйлап табарлар, – ди укытучы. – Минемчә, болар барысы да авыруны түгел, симптомнарны дәвалау. Проблеманы мәгариф системасының заманча чынбарлыктан сизелерлек артта калуында күрәм. Бигрәк тә вузда. Мин вузларда 5 ел эшләп, аннан мәктәпкә күчтем. Һәм югары уку йортларында


Илдар Мөхәммәтҗанов

вазгыять чыннан да аянычрак дип әйтә алам. Мәсәлән, лекцияләр форматы инде күптән искергән. Студентларга дәресләрнең заманча формалары кирәк. Алар дипломны ни өчен ел буе (ә кайчагында берничә ел) язарга кирәклеген аңламый. Әгәр яшьләр «Ни өчен?» дигән сорауга җавап таба алмый икән, системаны читләп узу яки җимерүнең җаен эзлиләр. Монда мәгариф системасын үзгәртү турында уйларга кирәк.

Айсылу Сәгыйтова нейрочелтәргә уңай карый. Дәресләрендә укучыларына аның ярдәмендә эшли торган биремнәр тәкъдим итә икән. Ни өчен әлеге челтәрдә ясалган рәсемнәрнең укучыларныкыннан калышуын да бергәләп карыйлар. Алга таба текстларны да тикшерергә җыеналар.

Укытучыны алдалыйм, димә…

КНИТУ-КАИ мөгаллиме Светлана Шәвәлиева дипломны нейрочелтәр ярдәмендә язуны хупламый. Аның фикеренчә, башкарылган эшне студент үзе өйрәнергә тиеш. Ә болай ул белмичә калачак. Ясалма интеллект ярдәмендә кирәкле эшне башкарырга була. Ә аны укуда куллану начар.

– Бүген яшьләрнең бәласе – күләмле мәгълүматның кирәклесен генә алып, системага салып, нәтиҗә ясый белмәү. Әйтик, кызны чүпрәкне чылатып, яхшылап сыгып, бөтен почмакларына җиткереп, идән юарга өйрәтәсең. Көн саен чиста булсын өчен, робот-суырткыч алып куйсаң да ярый. Әгәр шундук сатып алсаң, кызың бернигә өйрәнми кала. Кияүгә чыккач, әнисенә, эшкә өйрәтмәгәнсең, дип әйтәчәкләр. Монысы – бер. Тагын әле ышаныч дигән нәрсә бар. Билгеле булмаган нейрочелтәргә ничек ышанасың ди? Дөрес эшләгән булса ярый, ә эшләмәсә? Әгәр программада хата булса… – ди Светлана Шәвәлиева.

Фәнни хезмәтләрен сатып алучылар да бар. Барыбер беленә бит ул, студентлар, укытучылар күрми, дип уйламасыннар, ди галимә. Аны шундук чамалыйлар икән. «КАИда андый нәрсәләр эшкә ярамый. Ярар, студент «зачет» алды, ди. Эшкә баргач, нишләрләр? Алар үзләренә үк «аю хезмәте» күрсәткән булып чыга», – диде Светлана Шәвәлиева.

Акча түләп язу эш түгел

Бу көннәрдә Санкт-Петербургтан редакциягә «Татарский с нуля» үзөйрәткече авторы Максим Кузнецов кунакка килгән иде. Аның белән дә шушы теманы кузгатып алдык.

– Бүген «намусы чиста» булмаган студент өчен диплом язуның төрле ысуллары бар. Интернетта басылмаган дипломнарны, диссертацияләрне күчерү дисеңме, махсус консультация сайтларыннан акча түләтеп яздыртумы… Минемчә, менә шундый өй эшләре эшләүче, диплом эшләре язучы сайтларны ябу буенча көрәшергә кирәк, – ди ул.

Аның фикеренчә, фәнни эшне нейрочелтәр ярдәмендә язу – гадәти булмаган, технологик алгарышларның берсе. Әмма аны ничек кулланасын, нинди өстәмәләр кертәсен белергә кирәк.

– «Ы» операциясе, яки Шурикның башка маҗаралары» фильмындагы профессор әйткәнчә, уйлап табуыңа – «5ле», имтиханга – «2ле». Бу очракта да галим студентның эшен «3ле»лек дип бәяләгән. Бу бәя – ясалма, ә нейрочелтәр язган текст өчен гаделдер. Әлбәттә, әлеге студент дипломын алачак. Ә бит бүген югары дәрәҗәдә булмаган бик күп фәнни эшләр мөстәкыйль языла һәм аларга «4–5ле» билгеләре куялар. Студентлар арасында фәнни алгарыш сирәк. Аңа омтылырга һәм үз эшеңне интернеттагы очраклы авторларга һәм нейрочелтәргә йөкләмичә, мөстәкыйль башкарырга кирәк, – ди Максим Кузнецов.

Студентлар арасында ясалма интеллект турында белгәне һәм белмәгәне бар. 1 курста белем алучы Мәрьям Химәтова: «Бик кызык тоела бу. Әмма мин дипломымны тулысынча болай язмас идем. Бәлкем, яңалык өчен берничә абзац яки җөмлә кертеп карармын. Өстәвенә, нейрочелтәр антиплагиат буенча яхшы күрсәткечләр бирә», – диде ул.

Сәрия МИФТАХОВА

Язучы фикере

Моны ашарга мөмкинме?

Хастаханәдә ятканда игътибар иттем мин аңа. Андый вакытта күңел күзе үткенрәк була бугай инде ул, бүтән чакта әһәмият бирмәгән нәрсәләрне дә күрә башлыйсың. Монысы бөтенләй гади генә: операция ясадылар да бер атна чамасы ашамый торырга куштылар. Нихәл итәсең, ярамагач ярамый, димәк, түзәргә кирәк. Түзүнең бер кыенлыгы да юк, тыелган икәнен күңеленә сеңдерсәң, бик ашыйсы килми. Яшәргә тырышуның бер чагылышы инде бу: ничәдер көн ачыксаң ачык, әмма аягыңа бас. Менә шул вакытта игътибар иттем: кешенең гомере ашаудан гына тора икән.

Иртән торып, беркадәр вакыт үтүгә, коридорда: «Иртәнге аш!» – дип сөрән салалар. Палатадашлар алып керә инде. Аларның авыз чәпелдәткәнен тыңлап утырмас өчен мин чыгып китәм дә беренче каттагы фойега төшәм. Анда – буфет. Буфетта бер төркем өстәл янында утыра, икенче төркем чиратта тора. Аптырап арырак китәм: төрле ишекләр төбенә чират хасил булган. Кемдер минераль су чөмерә, кемдер сагыз чәйни, кәнфит суыра, кайчагында туңдырма ялаучылар да очрый. Гаепләмим инде, сәерсенәм генә, үземә ярамагач, кешеләрнең мәрәкә гамәлен өстән генә күзәтеп йөрим. Яраса, бәлки, үзем дә шулар арасында булыр, һич югында чемечке чиртеп булса да торыр идемдер.

Палатага керәм. Иртәнге ашны яңарак кына ашадылар бит инде. Кайсыдыр чәй кайнатып йөри. Аннан күреп икенчесе капкалап ала. Өченчесе чәй эчми, алма кимерә башлый. Коридорга чыгам: берәү суыткычка сөт илтә, икенчесе кефир күтәреп килә, өченчесе якындагы өстәлдә колбаса кисеп маташа. Аның тәмле исе таралганга мин генә түгел, шәфкать туташы да игътибар итә:

– Колбаса рөхсәт ителми! – дип кисәтә. Теге ханым гаепле елмаеп аңа карый да:

– Яхшы, яхшы… Әйтермен, бүтән китермәсләр, – ди. Ә үзе теге колбасаны пакетына йомдырып палатасына кереп китә.

Тиешле уколларны кадатып, мин тагын палатага керәм. Гәпләшәләр инде күршеләр, берсе мандарин әрчи, икенчесе банан чәйни. Гел менә шундый хәлләргә очрагач, кешеләр бертуктаусыз ашап кына торадыр шикелле тоела. Мин болардан аерылып, югары даирәгә, рухият дөньясына күчим дип кулыма китап алам. Мәхәббәт турында ул. Егет белән кыз очрашалар. Парк буйлап узалар. Матур сүзләр сөйләшәләр. Һәм якындагы кафега күзләре төшә. Тагын кафе!

Телевизор карарга китәм. Онытылырлык яхшы кино кирәк. Нининдидер сериал бара. Сөйләшә-сөйләшә ашап утыралар. Ашый-ашый сөйләшүчеләрдән качып, яңалыклар программасын ачам. «Менә монысы ярый инде», – дип уйлап та бетермим, реклама башлана. Монда да оста кешеләр эшли икән, авыздан сулар китерерлек итеп төрле-төрле ризыкларны, эчемлекләрне мактыйлар. Хәзер инде бөтен кешелекнең максаты ашау-эчү генәдер шикелле тоела башлый. Ул арада кемдер килеп, минем исем-атымны сорый. «Сезнең янга килгәннәр», – ди.

Беренче катка төшәм. Дуслар килгән. Шатланышып күрешәбез, сөйләшәбез. Китәр алдыннан алар миңа зур бер пакет тоттыралар. Ризыклар белән тулы.

– Кирәкми, рәхмәт! Миңа ашарга ярамый бит.

– Ярый башлагач ашарсың, бозыла торган түгел алар.

– Алмасаң, үпкәлибез.

Үпкәләмәсеннәр дип мин пакетны алып кереп суыткычка куям. Алар артыннан хатын, балалар, тагын берничә кеше шундыйрак пакет калдырып китә. Телефоннан берничә кеше белән сөйләшәбез. Аларның да беренче соравы диярлек шул була:

– Хәлләрең ничек? Әйбәт ашаталармы? Нәрсәләр китерик?

Махсус оештырылган нәрсә түгел бит инде бу. Адәм баласының табигате шундый. Аның өчен иң зур нәрсәләрнең берсе – тамак хәстәре.

Интернетта да эзләгечләрдә иң күп соралган нәрсәләр төрле ризыкларга бәйле: аш-су рецептлары, ашчы җайланмалары, савыт-саба һ.б. Телевидениедә дә шулай. Аш-суга бәйле китаплар – бестселлер рәтендә. Ризыкка бәйле нәрсәләр һәрвакыт популяр булачак. Чөнки кешелек белән ашау теләге идарә итә.

…Дәүләтләр дә бер-берсенә шулай карый бугай:

– Моны ашарга мөмкинме?

Марат КӘБИРОВ

ХА-ХА-ХАНӘ

Шушы урында көләсе

Шаян шарж

Наил Галимов шаржы

Айдарның йөргән юллары –
Уфа – Казан арасы.
Тамашачы күңеленә
Ерак икән барасы.

Мамадышта кемне күрим –
Айдар бит басып тора!
Мантый ашап, тамак туйса,
Жырлавы да шәп була!

Белеп тор!

УЙНАШТАН ТУГАН СҮЗЛӘР

☑ Кем чын ир? Ким Чен Ынмы чын ир? Ким Чен Ир – чын ир!

* * *

☑ Элек егетләр тальян тарта иде, хәзер кальян тарта.

* * *

☑ Халит! Хәләлме бу ит, хәлеңнән килгәнчә хәл ит.

* * *

☑ Бүген стендап-комик ситдаун-комикка әйләнергә мөмкин.

* * *

☑ «Ә бу ни бу?» – диде Биби. «Ә бу, Биби, – диде әби, – була Абу-Даби».

Шаян хикәя

ТОРМЫШ ӘЙБӘТЛӘНӘ

Менә сезнең искә алганыгыз бар микән, соңгы арада тормыш әйбәтләнә бит, җәмәгать. Элек ничек иде? Кибеткә керәсең, очсыз гына хакка бер куртка алып киясең. Шуның белән йөрисең.

Хәзер алай түгел. Хәзер без очсыз нәрсәгә бик якын килмибез. Чөнки беләбез: хакы түбәнрәк булган саен, аның сыйфаты начар була.

Узган җәй Вьетнам базарыннан арзан гына хакка бер ботинка сатып алган идем, кайтып җиткәнче табаны төште. Юл уңаена аяк киеме остаханәсенә керергә туры килде. Шул аяк киеме остасы сорый: «Сезгә ничек? Биш йөзгә төзәтимме, ике йөзгәме?» Дүрт йөзгә алган аяк киемен кайсы сантый биш йөзгә төзәтсен инде? «Ике!» – мәйтәм. Шуннан бу ботинканы алып, квитанция язып бирде дә: «Өч айдан килерсез», – ди. Биш йөзне түләргә туры килде. Яланаяк кайтып булмый.

Кайткач, хатынга сөйләгән идем, көлә: «Юләр син, – ди. – Хәзерге заманда очсызлы нәрсәгә якын баралармыни?! Начар товарга гына арзан хак куялар, ә әйбәт әйбер һәрвакыт кыйбат була...» Хатын да шулай дигәч, дөрес инде. Аның сүзе һәрчак дөрес була.

Әле менә тагын базарда йөреп килдем. Сирәк чыгам мин анда. Узган ел бер ураган идем... Вәт менә шул... Тормыш әйбәтләнә икән, җәмәгать. Помидор былтыргыга караганда ике тапкыр әйбәтләнгән. Лимон биш тапкыр әйбәтләнгән. Сарымсак – ун тапкыр. Былтыр бер сарымсакны өч сумга сатып алган идем, быел утызны сорадылар. Алмадым. Кыенсындым шулкадәр әйбәт сарымсак ашарга.

Тормыш әйбәтләнә, җәмәгать. Икмәк белән сөт тә әйбәтләнә. Сабын-порошок та. Кием-салым әйбәтләнә. Нәрсә кирәк, барысы да әйбәтләнә. Менә шундый гомум әйбәтлек чорында кешеләр дә әйбәтрәк, затлырак була барадыр дип уйлаган идем. Юк икән, кеше һаман әйбәтләнми икән. Кеше һаман зарлануда икән:



– Бу дөньяда бөтен нәрсә кыйбат, адәм башы гына арзан!.. – диләр.

Дөрес түгел!.. Түгел...
Нишләп арзан булсын адәм башы?!.
Беркөн чәчтарашка кергән идем...

Марат КӘБИРОВ

Шулай булды шул

ИНТЕРНЕТТА АРАЛАШУ

– Сәлам.

– Ну, сәлам. Шушы бер сүзме? Мин сине белмим дә. Кем син? Миңа «сәлам» дип язып, минем белән шулай танышмакчы буласыңмы? «Ничек хәлләрең?» дип тә язарсың әле. Мин «ярыйсы» дип язармын. Бар да стандарт буенча. Шуннан? Сез, егетләр, барыгыз да шундый! Җүнләп таныша да белмисез.

– Мин – синең курс эше җитәкчесе. Эшеңне кайчан яза башларга уйлыйсың?

Тугры фанатлар

Мин – гади генә кеше. Әмма минем фанатларым бар. Әйе, әйе, алар – минем чын фанатларым. Алар минем авызыма гына карап тора. Миңа охшарга тырышалар. Алар мине күрергә һәрвакыт шат. Алар мине кочаклап ала. Мине чын күңелдән яраталар. Еш кына бүләкләр бирәләр. Алар миңа ярдәм сорап килә, әйтерсең, мин барын да эшли алам. Алар һәрвакыт мин әйткәнне генә эшли. Минем сүздән чыкмыйлар. Мин аларны кулларыннан җитәкләп, теләсә кая алып китә алам. Алар миңа йөз процентка ышана һәм күзләремә генә карап торалар. Башкача була да алмый. Ни дисәң дә, мин башлангыч сыйныфлар укытучысы бит.

Булган хәл

Шулай бервакыт...

Соңгы интервью

«Ялкын» яшьләр журналында күп еллар балалар редколлегиясе эшләп килә. Анда басмага даими язмалар әзерләүче яшь актив хәбәрчеләр керә. Шул балалар «Лидерлар мәктәбе» дигән проект кысасында түрәләргә кунакка йөри башлый. Зур урында хезмәт итүче абый-апалар белән интервьюлар эшлиләр. Тик бер нәрсә генә күңелне тырный. Очрашудан соң күп тә үтми, түрәләрне башка эшкә күчерә башлыйлар. Энгель Фәттахов, Рафис Борһанов, Айрат Сибагатуллин, Айрат Хамаев белән шулай килеп чыга. «Ялкын»лылар уйлап-уйлап куя да, әллә гаеп бездә микән дип, әлеге проектны ябарга дигән карарга киләләр. Менә шулай, җәмәгать, әгәр сезгә берәр министр ошамаса, безгә әйтегез. Кунакка «Ялкын» журналын җибәрәбез!

Экскурсоводың кем?

Редакциядә матур гадәт бар. Кызлар-егетләр бергәләшеп елга 2–3 тапкыр төрле шәһәрләргә сәяхәт итәләр. Болгар, Зөя, Мәскәү, Чабаксар... Бу хәл Зөядә килеп чыга. Матур көн. Кеше күп. Туристлар шактый. Бер зур гына төркем игътибарны җәлеп итә. Минтимер Шәймиев бит бу! Сакчылар, ярдәмчеләр, телеоператорлар урап алган үзен. «Ялкын»лылар якынрак килә. Сакчыларның каршы килүенә карамастан, Минтимер Шәрипович күреп ала боларны. «Ялкын» егет-кызлары үзләре белән таныштыра, сөйләшә башлыйлар. Шулай итеп, сүз ара сүз, Шәймиев экскурсия ясый башлый боларга. Бер 20 минут Зөя турында сөйли. Инде сакчылары, ярдәмчеләре «Ялкын» кызларына кырын карый башлый. Баксаң, бу төркем монда эш белән йөргән икән. Фильм төшерү алдыннан план корулары. «Минтимер Шәрипович безгә Зөядә үзе экскурсия ясады!» – дип горурланып искә ала хәзер әлеге очрашуны «Ялкын» яшьләре.

Ә хәзер татар җыры!

Икенче шундый сәяхәт Мәскәүгә була. Башкала «Ялкын»лылар өчен аеруча якын. Чөнки журналга нәкъ менә шушында нигез салынган. 1924 елда Муса Җәлил вакытлы матбугаттагы язмасында яшьләр өчен журнал кирәклеге турында ассызыклый һәм якын арада «Кечкенә иптәшләр» дигән басма чыга башлый. Киләсе елга юбилей, Аллаһы боерса.

Мәскәү белән бер кат танышып чыккач, яшь хәбәрчеләр Арбатта урнашкан төрек кафесына керәләр. Бар да бик матур, һәрнәрсә тәмле, әмма музыкасы гына ошамый бит менә. «Ялкын» кызлары бик чая, администраторга мөрәҗәгать итеп, татар җырын куйдырталар. Шулай итеп ул көнне шул тирәдәге мәскәүлеләр төшке ашларын татар җырларын тыңлый-тыңлый ашый. Тәмле булсын!

ДИРЕКТОР ЧАБА

Сүземне тикмәгә генә болай башламадым, чөнки элекке совет чорында мәктәп директоры, көн туса, каядыр чаба-йөгерер иде. Аны барыннан да алда галәмәт озын иске агач бинаның төзеклеге борчый, тузганын алыштырып кадакласаң, икенчесе авызын ача – тәмам гарык төзәтеп. Аның кырыенда шул өлкән яшьтәге агач интернат – тирә-яктан, башкорт аръягыннан да килгән балаларны укытырга-тәрбияләргә. Бигрәк тә көчне сораганы: бу биналарны җылытырга – йөзләгән мичләргә ягар өчен кыштан кышка җитәрлек утын әрдәнәләре таучыкларын өеп куярга – директор җәй буе шуның артыннан чаба. Безнең Югары Стәрле урта мәктәбендә мондый олы мәшәкатьләрнең бетмәс йөген кырык еллар дәвамында Зиннур абый Гыйльфанов үз җилкәсендә йөртте. Менә берчак ул, Сукаеш урманыннан делянка алып кайтуга, үзенең «Восход» мотоциклына утырып, анда китеп бардык. Агач-ботаклардан шалаш корып, урман кисәргә оешу башланып китте. Кисәргә төп корал – аркылы пычкы, беләк-мускулларның егәре генә чыдасын! Ә кисүчеләре кемнәрме – безнең инәкәйләр – дүрт хатын-кыз. Алар янында бер елны Рәис, икенче елны Азат абыйлар, колхоздан калган иске «ГАЗ»икта – шуның белән ташыйлар бу галәмәт өеләсе утын хикмәтләрен. Без үсеп, егетләр булып җитешкәч, әниләр урынына урман кисә башладык. Монда бигрәк тә таза гәүдәле Альберт энекәш аерылып тора иде. Укытучылардан Хәйдәр абый, уртача гына гәүдәле үзе, әмма һич арыдым димәс, утын йөкләрен тоткарлыксыз төяп җибәрүне оештырып торыр.

Менә беркөнне Зиннур абыйны районга ашыгыч киңәшмәгә чакырып алдылар. Ә шактый ук киселгән утынны сакларга кирәк, урларга гына торалар. Куышта сакларга мелкашка мылтыгын да калдырды: «Килмичә калмаслар, килерләр, шунда ук куркытыр өчен һавага атарсың!» Мин – яшь егет, беренче тапкыр караңгы урман куышында ятам. Һәм чынлап та төн уртасында машинада килеп тә төште урман караклары. Курку тиз басканчы дипме, мин мелкашканы алып, һавага атып җибәрдем. Урман каракларына бу җитә калды – бик тиз төялеп олактылар.

humus.livejournal.com

Шушындый шартларда ул чакта мәктәп директоры, һич киме 300дән күп балага урта белем бирергә дип, иске агач мәктәпнең йөзләгән мичләренә ягып җылытырга гектардагы урманны кистерү артыннан көз айларына чаклы туктаусыз чабып-йөгерүдә булыр иде. Аңа эшче көч тә, техника-машина да бирәм диюче юк, бөтенесе үзе өстендә. Безнең инәкәйләр исә юан-юан шул усак, каен йөкләрен кузлаларга салып, аркылы пычкылар белән кисеп-ярып утын әрдәнәләренә өяләр, аннары көздән яз азакларына тикле төнге сәгать 2ләрдән килеп мичләргә ягалар. Билгеле инде, директорның монда да йокысы йокы түгел – кереп-карап чыкмыйча йөрәге тынмый.

Менә шундый иде ул чакларда мәктәп директорының хезмәт вазыйфасы. Ул гынамы әле, бөтен уку-укыту эшләреннән соң лектор-агитатор, колхозның партком әгъзасы. Авыл сәхнәсендә «Галиябану», «Шәмсекамәр»ләрне куюда катнашу дисеңме. Ләкин аңа карап кына Зиннур абыйның түшендә әллә нинди медаль-билет балкымады. Бөтен гомерен мәгърифәт-мәгарифкә багышлап, югарыдагы күпме шәкерт-затларга бөтен көче-ярдәмен куеп та, лаеклы ялына күңеле булырлык озата да алмадылар кебек аны. Моның өчен, ни әйтсәң дә, әрсезләр кавеменнән булырга кирәк иде шул.

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай районы Югары Стәрле авылы

Менә сиңа мә!

Яз, яз, яз килә...

✓ Ни өчен февральдә 28 генә көн? Чөнки бөтен кеше тизрәк яз җитүен тели.

✓ Яз килү белән кояш күренә башлады. Йорт-җир түләүләрен карагыз әле, кояш җылысын да квитанциягә кертмәгәннәрме?

✓ Март аенда кышкы кием белән эссе, ә язгы кием белән салкын.

✓ Яз ул шундый вакыт: зур пычракны урап узар өчен кечерәк пычрак сайлыйсың.

✓ Безнең песи инде февральдә үк март мәчесенә әйләнде.

✓ Яз көне авитаминоз шулай итә: кайвакыт «Ха-ха-ханә» өчен мәзәк язып утырганда йокымсырап китәсең дә башыңны клавиатурага салыпроы?%%кгра=г//о4......

Әз-мәз мәзәк

Кыш. 30 градус салкын. Төнге сәгать ике. Бер балыкчы боз өстендә утыра, балык чиерткәнен көтә. Берзаман карый: ерактагы йортның түбәсендә бер адәм авызына фонарь тотып, антенна урнаштыра. «Радио җене кагылган кешедер инде, нинди генә фанатиклар юк дөньяда», – дип уйлап куя балыкчы.

* * *

– Кичә иремә: «Минем сиңа хатын гына түгел, дус та буласым килә», – дидем.

– Ә ул?

– Ярар, алайса, утыр, диде. Һәм суыткычтан үзенекен чыгарып, миңа хатыныннан зарлана башлады.

* * *

– Бүген математикадан нинди билге алдың, улым?

– Биш плюс дүрт минус җиде.

Автобуста

Автобуста бер әби яшь кызга бәйләнә:

– Кара син аны! Чәчләрен буяган. Колакчын кигән. Музыка тыңлый. Мин инде 25 яшьтә ике баламны тудырган идем!

– Миңа 27 яшь һәм 3 бала үстерәбез. Әле тагын табарга исәп.

– Кара син аны! Нигә кирәк шулхәтле бала? Үзең кебек наушниклы балалар үрчетәсеңме? Әле каршы дәшкән була.

Мач әйткән!

Уинстон ЧЕРЧИЛЛЬ, британ сәясәтчесе



Һәр өргән эт янында туктасагыз, барасы җирегезгә гомер барып җитә алмаячаксыз.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5332 данә
Гомуми тираж – 15281 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 231

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА КЕШЕ ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛНЕҢ 2022 ЕЛДАГЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА КЕШЕ ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛ ДОКЛАДЫ

КЕРЕШ

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге турындагы әлеге еллык доклад 2000 елның 3 мартында дөнья күргән 95 нче «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында»гы Татарстан Республикасы Законының 26 нчы маддәсенә ярашлы рәвештә әзерләнде һәм Татарстан Республикасы Рәисенә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасы Югары суды рәисенә, Татарстан Республикасы Арбитраж суды рәисенә, Татарстан Республикасы Прокурорына җибәрелә.

Әзерләнгән доклад Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә килгән шикаятьләрне карау нәтиҗәләренә, тикшерү йомгакларына, «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы белешмәләренә, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары мәгълүматларына, шулай ук Вәкилнең җәмәгатьчелек ярдәмчеләре биргән мәгълүматларга, кеше хокуклары бозылу турында хөкүмәтнеке булмаган хокук саклау оешмаларыннан килгән яки массакүләм мәгълүмат чараларында басылган мәгълүматларга, республика ведомствоара комиссияләре материалларына һәм башка чыганакларга нигезләнә.

Докладта Вәкаләтле вәкилнең 2022 елгы эшчәнлегенә статистик мәгълүматлар китерелде. Шул ук вакытта докладта гражданнарның социаль хокукларын яклау, хәрби хезмәткәрләрнең һәм аларның гаиләләренең хокукларын яклау, мәҗбүри тоту урыннарында гражданнарның хокукларын яклау, кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре өлкәсендә хокукый агарту турында мәгълүмат, законнарны камилләштерү эшчәнлегендә Вәкаләтле вәкилнең катнашуы турында мәгълүмат чагылдырылган.

Шуңа бәйле рәвештә доклад структурасы тиешле бүлекләрне үз эченә ала, ә аның йомгаклау өлешендә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый оешмаларга кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауны көчәйтүгә юнәлдерелгән кайбер чараларны гамәлгә ашыру мөмкинлеген карау тәкъдим ителә. Әлеге тәкъдимнәр хокук яклау эшчәнлеген камилләштерер дип өметләнәбез.

Бүлек 1. МӨРӘҖӘГАТЬЛӘРНЕҢ МАСШТАБЛАРЫ, ДИНАМИКАСЫ ҺӘМ СТРУКТУРАСЫ

Дәүләт органнарына мөрәҗәгать итү хокукы – һәр гражданның аерылгысыз хокукы. Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил институты эшчәнлеге гражданнар мөрәҗәгатьләреннән башка мөмкин түгел. 2022 елда гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүгә анализ күрсәткәнчә, елдан-ел арта барган мөрәҗәгатьләр саны, һичшиксез, гражданнарның Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил институтына ышанычының югары дәрәҗәсен төгәл чагылдыра.

Әйтик, хисап чорында Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә (алга таба – Вәкаләтле вәкил) 6746 тапкыр мөрәҗәгать иттеләр, бу 2021 ел белән чагыштырганда 551 тапкыр күбрәк.

Язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны 5171 тәшкил итте, шулардан 675 мөрәҗәгать – почта элемтәсе аша, 772се – электрон почта, 1134 – Интернет-кабул итү бүлмәсе, 275 – күрешеп сөйләшү, 473 – телефон аша шалтырату, 602 мөрәҗәгать Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы аша алынды.

2022 елда Вәкаләтле вәкил 78 кабул итү үткәрде, анда 328 граждан кабул ителде, шул исәптән 50 шәхси һәм 28 уртак тематик кабул итү.

Хисап чорында Татарстан Республикасы Прокуратурасы җитәкчелеге белән (15.03.2022 – 29 мөрәҗәгать, 28.06.2022 – 33, 28.09.2022 – 21, 13.12.2022 – 11), Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе белән (29.11.2022 – 5), Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсе белән (16.05.2022 – 2, 17.10.2022 – 2), Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге дәүләт учреждениесе һәм «Татарстан Республикасы буенча медик-социаль экспертиза Баш бюросы» белән (17.05.2022 – 10), Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе белән (03.06.2022 – 4, 16.08.2022 – 7), Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән (19.07.2022 – 14), Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән (27.06.2022 – 5), «Ливадия» шифаханәсендә Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе һәм Татарстан Дәүләт Советы депутаты – Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе рәисе белән (19.05.2022 – 11), Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутаты А.З. Фәррахов белән (02.12.2022 – 8), «Васильевский» шифаханәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе – Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе рәисе белән (14.06.2022 – 14), Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутаты Ә.М. Хәмитов белән (02.06.2022 – 11, Яр Чаллы шәһәрендә урынга барып) 16.12.2022 – 5) уртак тематик кабул итүләр үткәрелде.

Шулай ук Вәкаләтле вәкил видеоконференцэлемтә (телемедицина) системасын кулланып, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Татарстан Республикасы Премьер-министрының хокук саклау һәм административ эшчәнлек буенча ярдәмчесе, Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчелеге, Татарстан прокуратурасы белән берлектә Россия Җәзаларны үтәтү хезмәтенең «16 нчы номерлы медик-санитар часте», Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2 нче, 3 нче, 4 нче, 8 нче, 10 нчы, 19 нчы төзәтү колонияләрендә, КП-17, КП-18, 2 нче, 4 нче, 5 нче тикшерү изоляторларында хөкем ителгәннәрне 10 дистанцион кабул итү уздырды. Россия Җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 1 нче төзәтү үзәгенә барып кабул итү булды, нәтиҗәдә әлеге кабул итүләрдә 77 тоткын шәхси сораулары буенча консультацияләр алды.

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты (алга таба – Вәкаләтле вәкил Аппараты) тарафыннан оештырылган «кайнар элемтә»ләргә ел саен була торган шалтыратуларның кимемәве әлеге түләүсез юридик ярдәм күрсәтү форматына безнең республика халкында ихтыяҗ зур булуын күрсәтте һәм аларны 2022 елда үткәрүне дәвам итү кирәклеген раслады.

Узган ел Вәкаләтле вәкил Аппаратында кызыксынган ведомстволар катнашында 8 «кайнар элемтә» үткәрелде, шулар кысаларында 409 шалтырату кабул ителде.

Кергән мөрәҗәгатьләр белән эшләп, Вәкаләтле вәкил гражданнарның шикаятьләренә карата законда каралган төрле җавап бирү ысулларын: тикшерүләр уздыру, запрослар җибәрү, судларга үтенечләр җибәрү, рекомендацияләр җибәрү һәм башкаларны куллана.

Хисап чорында Вәкаләтле вәкил һәм гражданнарның хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге һәм «Халык контроле» ТР дәүләт мәгълүмат системасы кулланучыларының үзара хезмәттәшлеген координацияләү бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан 750дән артык тикшерү чарасы үткәрелде.

Пандемия шартларында контроль-күзәтчелек органнары тарафыннан тикшерүләр уздыруны вакытлыча чикләүләргә карамастан, 2022 елда Вәкаләтле вәкил йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан кызыксынган ведомстволар экспертларын җәлеп итеп, 13 мөрәҗәгать буенча оешма һәм учреждениеләргә барып тикшерүләр оештырылды.

Болар – граждан Я.ның Казан шәһәре Совет районының Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназиядә белем бирү процессында катнашучылар арасында килеп туган низаглы хәл турындагы мөрәҗәгате буенча;

– гражданин Л.ның «Метроэлектротранс» муниципаль унитар предприятиесе хезмәткәрләрен броньлау буенча вазыйфаи затларның чаралар күрмәве турындагы мөрәҗәгате буенча;

– гражданин Х.ның «Советлар Союзы Герое Б. К. Кузнецов исемендәге Казан кадет интернат-мәктәбе»ндә килеп туган хәл турындагы мөрәҗәгате буенча;

– гражданин Н.ның «Казан шәһәре Вахитов районы Олимпия резервы спорт мәктәбе»ндә укучылар арасында килеп туган низаглы вазгыять турындагы мөрәҗәгате буенча;

– гражданин А.ның Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Иске Суыксу урта гомуми белем бирү мәктәбендә белем бирү процессында катнашучылар арасында килеп туган низаглы вазгыять турында мөрәҗәгате буенча;

– гражданин С.ның Олы Кайбыч урта мәктәбенең – Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының цифрлы һәм гуманитар профильләр мәгариф үзәгенең 3 сыйныф укытучысына шикаяте буенча;

– гражданин Б.ның Бөтенроссия дәүләт юстиция университетының Казан институты (Түбән Кама корпусы) көллиятендә педагогик процесста катнашучылар арасында килеп туган низаглы вазгыять турында мөрәҗәгате буенча;

– Казан шәһәре Совет районының «11 нче күппрофильле лицее» эшен инвалид һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларны укытуны оештыру өлешендә закон таләпләрен үтәү ягыннан оештыру буенча;

– «Соматик авырулары булган балалар өчен озайтылган уку көне булган 168 нче төп гомуми белем бирү мәктәбе» эшен инвалид һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларны укытуны оештыру өлешендә закон таләпләрен үтәүне оештыру буенча;

– Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Чулпан «Мәлки балалар бакчасы» эшчәнлегендә хезмәт законнарын бозу турында М. мөрәҗәгате буенча.

Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәре тарафыннан инвалид һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны укыту буенча мәгариф өлкәсендә законнар белән билгеләнгән таләпләрнең мәгариф өлкәсендә үтәлешенә мониторинг уздыру максатында, әлеге мониторингны үткәрүдә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының мәгариф һәм фән буенча комиссиясе әгъзаларын, «Үзәк психологик-медик-педагогик комиссия» республика психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәм күрсәтү үзәге» хезмәткәрләрен катнашырга чакырып, 11 белем бирү оешмасына бару оештырылды.

Шулай ук 2022 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре тарафыннан гражданнарның «Халык контроле» системасына кергән мөрәҗәгатьләрендә күрсәтелгән объектлар буенча 702 күчмә тикшерү уздырылды һәм мониторинг барышында 7124 шикаять нигезсез статуслар бирелүгә бәйле рәвештә эшкә кайтарылды.

Хөкем ителгән, тикшерүгә-кулга алынган, административ-тоткарланган кешеләрнең урыннарда матди-көнкүреш тәэмин итү шартлары белән танышу максатыннан, шулай ук гражданнарның килгән мөрәҗәгатьләре буенча 30 тапкыр урынга чыгып тикшерү оештырылды: республиканың төзәтү учреждениеләренә – 6, тикшерү изоляторларына – 3, вакытлыча тоту изоляторларына һәм махсус кабул итү бүлмәләренә – 11, эчке эшләр органнарының административ-тоткарланган затлар өчен махсус биналарына – 10.

Хисап елында дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, аларның вазыйфаи затлары һәм оешмалары адресына Вәкаләтле вәкилнең гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре эшчәнлеге өлешендә мәгариф өлкәсендә бозылган хокукларны һәм ирекләрне торгызуның мөмкин булган һәм кирәкле чаралары турында кисәтүләре һәм тәкъдимнәре җибәрелде (әйтик, «П.В. Дементьев исемендәге Казан авиация-техник колледжы» директорына гражданин С. мөрәҗәгате буенча; гражданин П.ның Яшел Үзән муниципаль районы башкарма комитетына – мәгариф идарәсе җитәкчесенә мөрәҗәгате буенча; Әлмәт шәһәрендә яшәүче ата-аналарның балаларны мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә кабул итүгә ярдәм итү турындагы (бертуганнары шунда) Әлмәт муниципаль районы башлыгына мөрәҗәгате буенча; сәламәтлек саклау өлкәсендә (Әлмәт шәһәре гражданы Б.ның медицина хезмәткәренең йөклелеген законсыз өзү факты буенча Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрына мөрәҗәгате буенча); башкарма производстволар кысаларында (Т., С., Х. мәнфәгатьләрендә – Татарстан Республикасы буенча Суд приставлары федераль хезмәтенең Баш идарәсенә – Татарстан Республикасы Баш суд приставына мөрәҗәгатьләре буенча); торак өлкәсендә (Түбән Камада яшәүче гражданин Р.ның Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрына торак урынына социаль наем шартнамәсен озайту турындагы мөрәҗәгате буенча; торак урынын яшәү өчен яраксыз дип тану буенча Казан шәһәре башкарма комитетының торак-коммуналь хуҗалыгы комитеты рәисе урынбасарына – торакны, торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану буенча ведомствоара комиссия рәисенә мөрәҗәгате буенча; граждан Ш.ның каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча коммуналь хезмәт күрсәтүгә түләүне исәпләүдә «Торак-коммуналь хуҗалык предприятиесе» ҖЧҖ генераль директорына мөрәҗәгате буенча; Казан шәһәренең башкарма комитетында яшәү өчен яраксыз дип табылган торак урыны урынына төзекләндерелгән торак урыны бирүдә ярдәм күрсәтү турында граждан Г. мөрәҗәгате буенча; хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә (Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрына) өченче төркем инвалид О. мөрәҗәгате буенча.

Ел дәвамында гражданнар хокукларын торгызу максатыннан Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфадагы затларына, оешмаларга барлыгы 40 тәкъдим һәм кисәтү җибәрде.

Узган чорда Татарстан Республикасы Законының 24 нче маддәсе һәм 51 нче маддәсе 3 өлешенә нигезләнеп, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Конституция судына, аерым алганда, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1132 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү чиратын билгеләү критерийларын куллану тәртибенә кушымтаның 3.2 пункты белән һәм Татарстан Министрлар Кабинетының 2017 елның 30 сентябрендәге 739 нчы карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау зарурлыгын билгеләү тәртибенең 1.2, 3.1 һәм 3.7 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләре белән конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылу турында; «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 2 пунктындагы аерым нигезләмәләр белән, әлеге карар белән расланган Аерым категорияләргә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.11 пункты белән Татарстан Республикасында халык категорияләренә «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымта, «а» пункты белән үзара бәйле аерым нигезләмәләре белән конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылу турында, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының 2013 елның 6 августындагы 7154 номерлы карары белән расланган, Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.6, 2.7 һәм 2.8 пунктларының икенче абзацлары белән конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылу турында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында» 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарының 4 пункты белән конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылу турында 4 заключение җибәрелде.

2018 елда Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе белән хезмәттәшлек турында төзелгән килешү кысаларында 2022 елда бердәм дәүләт мәгълүмат системасы – ГЛОНАСС +112 системасында эш дәвам итте.

Вәкаләтле вәкилнең хисап чорында кабул ителгән хәбәрләр саны 1 575кә җитте.

Без үтүгән иң күп хәбәрләр ГЛОНАСС +112 системасыннан Казан (422), Яр Чаллы (124), Бөгелмә (124), Яшел Үзән (114), Түбән Кама (102) районнарыннан килде.

«112 ашыгыч чакыру хезмәте»нә шалтыратып гражданнар торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге аварияләр (кагыйдә буларак, коммуналь аварияләрне бетерү яки аларны бетерү срокларын озакка сузу), медицина ярдәме күрсәтүдән дәлилсез баш тарту, медицина персоналы ягыннан салкын мөнәсәбәт, иреккә хокукларны бозу, шәхси кагылгысызлык, шәхеснең абруен төшерү (сәламәтлеккә зыян китерү, кыйнау һ. б.), балаларның хезмәткә сәләтсез ата-аналарны кайгырту буенча бурычын үтәмәве һәм аларны ялгыз һәм куркыныч хәлдә калдырулары, ата-аналарның балаларны тәрбияләү буенча бурычларын үтәмәүләре, шулай ук эчке эшләр органнары хезмәткәрләре тарафыннан вәкаләтләрне арттыру яисә югарыда күрсәтелгән органнарның республика гражданнары мөрәҗәгатьләренә битараф булулары турында хәбәр итте.

Күп хәбәрләр гражданнарның социаль тормышына, аерым алганда, техник тернәкләндерү чараларын бирү, зәгыйфь гражданнарның хокукларын яклау, аларны социаль тәэмин итү, авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга ярдәм итү турындагы үтенечләргә кагыла иде.

Субъектив проблемалардан тыш, гражданнар да иҗтимагый әһәмияткә ия проблемаларга: юл хәрәкәте куркынычсызлыгы, территорияне төзекләндерү һәм җәмәгать урыннарын чиста һәм тәртиптә тотуга битараф түгел, шулай ук гражданнар күзәтүсез куркыныч хайваннар турында зарланып мөрәҗәгать иттеләр.

Хокук мөнәсәбәтләренең, тормыш эшчәнлегенең төрле өлкәсендә гражданнарның хокукларын яклауга турыдан-туры бәйле булган мондый мөрәҗәгатьләрне алганда, Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгать итүчеләрнең килеп туган проблемаларын кичекмәстән хәл итү чараларын күрә.

Шулай итеп, хәбәрләрдә күрсәтелгән фактларны ачыклау максатыннан 420 дән артык урынга чыгып тикшерү оештырылды.

Мисал:

Карточка № 4904***–кц

Тасвирлама

Гариза бирүче 1 төркем инвалид, урын өстендәге авыру (склероз). Социаль хезмәткәр килүен яки аны картлар йортына билгеләвен сорый, чөнки ул үзен карый алмый. Улы көн буе эштә. Элек мөрәҗәгать иткән, хезмәтләр җавап бирмәгән.

Карточканың карап тикшерүгә шулай ук Татарстан Республикасы Нурлат районының «Гармония үзәге» учреждениесенә керүен исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил үз чиратында учреждение җитәкчесенә хәл турында, гариза бирүченең мөрәҗәгатен карау нәтиҗәләре турында хәбәр итүне һәм кирәк булса кичекмәстән чаралар күрүне сорап, хат җибәрде.

Вәкаләтле вәкил хатына Н.ның ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының картлар һәм инвалидлар өчен Норлат интернат-йортына билгеләнүе турында җавап килде.

Хисап чорында Вәкаләтле вәкил адресына гражданнарның телдән һәм язма мөрәҗәгатьләрендә кагылган сораулар саны 5 468 тәшкил итте.

Мөрәҗәгатьләр саны арту, тематикалар һәм аларга куелган мәсьәләләр арту сәбәпле, кергән мөрәҗәгатьләргә комплекслы һәм киңәйтелгән анализ төзегәндә, соңгы берничә елда без түбәндәге тематик блокларны куллана башладык.

I. «Гражданлык һәм сәяси хокуклар һәм ирекләр» – 253 мөрәҗәгать.

(Сайлау һәм сайлану хокукы» – 0, «Россия Федерациясе гражданлыгы хокукы». «Ирекле хәрәкәт итү, тору һәм яшәү урынын сайлау хокукы» – 148, «Вөҗдан һәм дин иреге» – 0, «Дәүләт һәм муниципаль органнарга мөрәҗәгать итү хокукы» – 105, «Ачык чаралар үткәрү һәм аларда катнашу хокукы» – 0.

II. «Социаль, икътисадый һәм мәдәни хокукларны һәм ирекләрне яклау»

• **«Торакка хокук»** – 529 мөрәҗәгать.

2022 елда гражданнар тарафыннан торак-коммуналь өлкәгә кагылышлы сораулар елдан-ел үзгәрми диярлек. Мөрәҗәгатьләр саны, кагыйдә буларак, тотрыклы рәвештә югары булып кала. Хисап чорында Вәкаләтле вәкилгә коммуналь хезмәтләрнең (салкын һәм кайнар су белән тәэмин итүне өзү, суның түбән температурасы), гомумйорт мөлкәтенең тиешле дәрәҗәдә булмавы (дымлылык, диварларның катуы, канализация исе, вентиляция системасы бозылуы), идарәче компанияләр хезмәткәрләренең, торак милекчеләре ширкәтләренең һәм милек белән идарә итүнең башка рәвештәге оешмалары гамәлләре (гамәл кылмавы) турында (тиешле булмаган ремонт эшләрен башкару, вакытында ремонтлау, коммуналь аварияләрне бетерү срокларын озакка сузу), тарифларны исәпләү, коммуналь хезмәтләр өчен түләүләр исәпләү һәм торакны карап тоту тәртибен бозу турында мөрәҗәгатьләр керде.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: әлеге хокук категориясенә кагылышлы мөрәҗәгатьләрнең күпчелеге торак белән тәэмин итү мәсьәләләренә кагылды: ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү, инвалидларны һәм инвалид балалары булган гаиләләрне торак белән тәэмин итү, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә кую мәсьәләләре каралды.

Мисал:

23.09.2022. Татарстан Республикасы хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү бүлмәсе аша Вәкаләтле вәкил адресына Казан шәһәре Агрономия урамындагы 18 нче күпфатирлы йортта лифтлар эшләмәү турында мөрәҗәгать килде. Элегрәк күрсәтелгән мөрәҗәгать шулай ук Казан шәһәр торак инспекциясенә җибәрелгән иде, аның нәтиҗәләре буенча, әлеге йортка хезмәт күрсәтүче «Гранит Дом» ҖЧҖ идарәче компаниясенә карата лифтлар эше өлешендә мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау һәм аларны бетерү буенча чаралар күрү турында кисәтү бирелгән иде.

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2000 елның 3 нче мартындагы 95 нче Татарстан Республикасы Законының 16 маддәсенә таянып, шулай ук гражданнар хокукларын яклау максатларында Татарстан Республикасы Прокуроры адресына Агрономия урамы буенча 18 номерлы йортта лифтлар эшен торгызуга ярдәм итү турында, Казан шәһәр торак инспекциясе башлыгының әлеге кисәтүне үтәүне тәэмин итүен сорап хат юлланды.

Татарстан Республикасы Прокуратурасыннан килгән мәгълүматларга караганда, прокуратура үткәргән тикшерү барышында йортны «УК «Гранит Дом» ҖЧҖ карап торуы ачыкланган, ул 2013 елның 11 ноябрендә «Движение» ҖЧҖ белән йортта лифтларга техник хезмәт күрсәтү, эксплуатацияләү һәм ремонтлау өчен килешү төзегән.

2021 елның ноябреннән 2022 елның августына кадәр «УК «Гранит Дом» оешмасының «Движение» ҖЧҖ алдында бурычы барлыкка килгән.

Әмма «Движение» ҖЧҖ, Россия Федерациясе Торак кодексы нигезләмәләре, Россия Федерациясе хөкүмәтенең 03.04.2013 ел, № 290 карары белән расланган, йортта гомуми милекне тиешенчә карап тотуны тәэмин итү өчен кирәкле хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару кагыйдәләрен бозып, 2022 елның сентябреннән йортта лифтлар эшен туктату турында берьяклы карар кабул иткән, бу – шулай ук йортта яшәүчеләрнең, шул исәптән өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның хокукларын бозу.

2022 елның 17 октябрендәге тикшерү нәтиҗәләре буенча прокурор акты кабул ителде: «Движение» ҖЧҖ җитәкчесе адресына торак законнары таләпләрен бозуны бетерү һәм аларны алга таба да булдырмау турында күрсәтмә бирелде, ул каралды һәм канәгатьләндерелде, 2022 елның 21 октябрендә лифтлар эше торгызылды.

• **«Социаль тәэминатка хокук»** – 434 мөрәҗәгать.

Әлеге хокуклар төркемен тәшкил итүче мөрәҗәгатьләр пенсия белән тәэмин итү, инвалидларны социаль тәэмин итү («уңайлы мохит» булдыру, затны инвалид дип тану, техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итү, индивидуаль реабилитация һәм абилитация программасына үзгәрешләр кертү, санатор-курорт дәвалануына юллама рәвешендә дәүләт социаль ярдәмен алмау), социаль хезмәт хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) кагыла иде.

Мәсәлән, 2022 елның 15 мартында Вәкаләтле вәкил Аппаратына «Казан шәһәре «шәһәр округында халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном учреждениесендә тиешсез хезмәт күрсәтү турында гариза килгән. Автор раславынча, социаль хезмәтләр үзәкнең хезмәткәре тарафыннан тиешле сыйфатта күрсәтелми һәм социаль хезмәтләр күрсәтү вакыты таләпләрен бозып күрсәтелә, моннан тыш, социаль хезмәткәр үзен тиешенчә тотмый һәм мөрәҗәгать итүчене мәсхәрәли.

Шулай ук мөрәҗәгатьтән күренгәнчә, Л. «Казан шәһәре «шәһәр округында халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» җитәкчелегенә мөрәҗәгать иткән, әмма күрсәтелгән мәсьәләләр буенча чаралар күрелмәгән.

Безнең Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрына вазгыятьне ачыклау һәм тиешле чаралар күрү турындагы хатыбызга җавап итеп, хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын бәяләү максатларында Л.ның дәлилләре тикшерелде, КЦСОН җитәкчелегенә үзәккә килүчеләргә тиешле хезмәт күрсәтергә кушылды. Хәтта шулай ук тиешле кагыйдәләрне бозган хезмәткәргә дисциплинар чара күреләчәге әйтелде.

• **«Хезмәткә хокук»** – 98 мөрәҗәгать.

2022 елда Вәкаләтле вәкилгә килгән мөрәҗәгатьләргә анализ шуны күрсәтә: гражданнар, нигездә, хезмәт хакын түләмәү, эштән азат итү, законсыз рәвештә эштән азат итү, хезмәт конфликтлары, эшкә урнашу проблемалары буенча мөрәҗәгать иткәннәр.

Мисал:

Мәсәлән, 19 майда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчелегенең, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының гражданнарны бергәләп «Ливадия–Татарстан» шифаханәсенә вакытлыча урнаштыру пунктында кабул итүе вакытында граждан С. кызын эшкә урнаштыруда булышуны сорап мөрәҗәгать итте.

Мөрәҗәгать итүче сүзләренчә, документлар булмау сәбәпле, кызын «Перекресток» кибетенә эшкә алудан баш тартканнар.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, «Совет районы буенча Казан халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ филиалына җибәрелгән мөрәҗәгатькә бәйле рәвештә, С. һәм аның әнисенә Донецк Халык Республикасы территориясеннән килергә мәҗбүр булган кешеләр буларак эш эзләүдә ярдәм күрсәтү йөкләмәсе бирелде.

Министрлык җавабында шулай ук С. ның шифаханәнең склад хезмәткәре итеп эшкә урнаштырылуы турында хәбәр ителде.

• **«Сәламәтлекне саклау һәм медицина ярдәме алу хокукы»** – 191 мөрәҗәгать.

Гражданнар еш кына дару препаратлары белән тәэмин ителмәү һәм тиешенчә медицина ярдәме күрсәтелмәүгә бәйле проблемаларга кагыла.

Мисал:

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратына Казан шәһәрендә яшәүче С. телефоннан мөрәҗәгать итте.

Телефон аша сөйләшү барышында мөрәҗәгать итүче яман шеш авыруыннан җәфа чигүен, бөтен тәнендә җәрәхәтләр китүен хәбәр итте. Табибны өйгә чактырткач, участок табибы килгән, мөрәҗәгать итүчегә белгеч-хирург янына килергә тәкъдим ителгән. Әмма мөрәҗәгать итүче авырлык белән йөри һәм өйдән чыгу мөмкинлеге юк.

Мөрәҗәгать итүче С. шалтыраткач, борчылып, без Казан шәһәре сәламәтлек саклау идарәсе башлыгы – республиканың сәламәтлек саклау министры урынбасары адресына мөрәҗәгать итүчегә табиб-хирург китертүне оештыру буенча оператив чаралар күрү турында үтенеч белән хат юлладык.

Казан шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсеннән безгә С.ның өйдә табиб-хирург тарафыннан каралуы, диагноз куелуы һәм дәвалану билгеләнүе турында хәбәр килде. Туганнарына һәм якыннарына авыруны карау буенча киңәшләр бирелгән.

• **«Мәгариф һәм мәдәни кыйммәтләргә керү хокукы»** – 224 мөрәҗәгать.

Хисап чорында Вәкаләтле вәкилгә уку йортларында уку процессын оештыруга, белем бирү процессында катнашучылар арасында низаглы хәлләр булуга карата шикаятьләр керде. Шулай ук мөмкинлекләре чикле балаларга белем бирү, мәгариф учреждениеләренә керергә ярдәм итү, сәламәтләндерү лагерьларында «инклюзив балалар ялы»н оештыру, мәгариф учреждениеләренә транспорт йөртү, яңа уку йортлары төзү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатьләр килү дәвам итте.

Мисал:

2022 елның декабрендә Вәкаләтле вәкил адресына Питрәч муниципаль районының Яңа Шигали авылындагы «Усадьба Царево» торак комплексында, «Советлар Союзы Герое Г.К. Камалиев исемендәге күппрофильле лицейда» физик культура дәресе вакытында, укытучы булмаган вакытта, 7 сыйныф укучысының имгәнүе, бу факт буенча мәктәп хакимиятенең һәм сыйныф җитәкчесенең чаралар күрмәве, бала ашханәдә кизү тору сәбәпле дәрестә булмаганлыктан өй эшен эшләмәгәч аңа начар билге кую белән килешмәү турында М. нан мөрәҗәгать керде.

Вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы мәгариф министры урынбасары – Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм

tatarstan.ru

контроль департаменты җитәкчесе адресына юлланган хатына җавап итеп, укытучы тарафыннан эш урынын калдыру, спорт залында укучыларны ялгыз калдыру, нәтиҗәдә укучыларның туп белән саксыз эш итү фактлары расланды, дигән җавап килде. Эш инструкциясен бозган өчен укытучы дисциплинар җаваплылыкка тартылган.

Шулай ук ведомстводан кергән мәгълүматта тагын бер фактның раслануы турында хәбәр ителде: укытучы мөрәҗәгать бирүченең улына дәрестә кизү тору сәбәпле, начар билге куйган һәм директор боерыгы белән расланган, педагогик совет тарафыннан кабул ителгән локаль акт таләпләрен бозган.

Ачыкланган фактлар буенча укытучы дисциплинар җаваплылыкка тартылган, билге электрон журналдан алынган.

М. мөрәҗәгатен караганнан соң, директорга педагогларның вазыйфаи бурычларын һәм локаль актларны тайпылышсыз үтәүләрен, шулай ук мәгариф өлкәсендә федераль законнар таләпләрен үтәүне тәэмин итәргә кушылды.

• **«Гаиләне, аналарны, аталарны һәм балачакны яклау хокукы»** – 93 мөрәҗәгать.

Әлеге тематика буенча хисап чорында Вәкаләтле вәкилгә, бала тәрбияләү буенча бурычларын үтәмәгәнлектән ата-ана хокукыннан мәхрүм итү, балалар яки оныклар белән аралашуның мөмкин булмавы, ата-ана хокукларын торгызу, балаларның кайда булуы һәм аларның сәламәтлекләре торышы, бала язмышы өчен борчылу һәм башка мәсьәләләргә бәйле рәвештә, мөрәҗәгать иттеләр.

Вәкаләтле вәкил Аппаратына ЕГИС ГЛОНАСС +112 системасы аша К.ның ата-ана вазыйфаларын тиешенчә үтәмәве һәм балигъ булмаган балаларның яшәү шартлары турында аноним хәбәр керде.

Мисал:

Әлеге хәбәргә борчылып, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә булган барлык хәлләрне ачыклау һәм кирәк булган очракта кичекмәстән чаралар күрүне сорап хат җибәрде.

Кызганычка, аноним хәбәрдәге фактлар расланды. Гр. К. беркайда да эшләми, берничә көн спиртлы эчемлекләр куллана. Хатынның балалары белән өйдә низаг була, шуннан соң балалар (2010 һәм 2016 елгы) өйләреннән күршеләренә кача һәм күрше мунчада йоклый. Алар артыннан әниләре төштән соң икенче көнне генә килә.

Килеп туган вазгыятькә бәйле рәвештә, гражданка К. балаларын, Минзәлә муниципаль районында «Тургай» «балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приют»ка вакытлыча урнаштыру турында гариза язган.

К. гаиләсе ведомствоара исәпкә куелган, әни кеше алкогольгә бәйлелектән дәвалану курсы узган.

• **«Уңайлы мохиткә һәм җиргә хокук»** – 69 мөрәҗәгать.

Сораулар атмосфера һавасын пычратуга, җир бәхәсләренә, санкцияләнмәгән чүплекләргә, су объектларын саклауга һәм башкаларга кагыла.

Питрәч муниципаль районында яшәүче Ч. җир кишәрлеге бирү турында судка дәгъва гаризасы биргән. Җавап бирүче Питрәч муниципаль районы Богородское авыл җирлеге башкарма комитеты иде. Дәгъва предметы җирле үзидарә органына сатулар үткәрмичә генә дәгъвачыга арендага җир участогы бирү бурычын йөкләү булды.

Элегрәк гражданин Ч. мөрәҗәгате буенча үткәрелгән тикшерү барышында җирле үзидарә органы тарафыннан авторның сатулар үткәрмичә арендага җир кишәрлеге бирү турындагы гаризасының асылда карап тикшерелмәве ачыкланды: гариза бирүчегә гамәлдәге җир законнарына аңлатмалар бирелгән яисә аның гаризалары аны карауга вәкаләтсез җирле үзидарә органы каравына җибәрелгән.

Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча Питрәч муниципаль районы Богородское авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе адресына мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгатьләрен карау кирәклеге турында тәкъдимнәр җибәрелде. Суд утырышы барышында Вәкаләтле вәкил Аппараты вәкиле тарафыннан дәгъва гаризасы буенча безнең позиция чагылдырылды һәм суд тарафыннан Питрәч муниципаль районы Богородское авыл җирлегенең җирле үзидарә органына гражданинның асылда сатулар үткәрмичә һәм җир законнары белән билгеләнгән срокларда арендага җир кишәрлеге бирү турындагы гаризасын карау бурычын йөкләү турында карар кабул ителде.

Мисал:

Җәй көне йортларда яшәүчеләр һәм идарәче оешмалар ишегалларын актив төзекләндерәләр. Чәчәк түтәлләрен һәм мәйданчыкларны оештыру өчен автомобиль шиннарын куллану – гадәти күренеш. «Зарарлы матдәләр. Классификация һәм гомуми куркынычсызлык таләпләре» ГОСТ 12.1.007–76 буенча һәм Россия Табигать күзәтчелегенең 22.05.2017 ел, № 242 боерыгы белән расланган кагыйдәләрдә автомобиль шиннары III–IV класслы калдыкларга кертелгән, алар экосистемага зыян китерә һәм йорт яны территорияләрендә урнаштырыла алмый.

Вәкаләтле вәкил адресына Казан шәһәренең Волгоград урамы, 24 йорт адресы буенча покрышкалардан йорт яны территориясен җыештыру мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать килде. Әлеге мәсьәлә буенча гариза «Халык контроле» – № 5012335 (21.07.2022) системасында урнаштырылган иде.

Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре гариза бирүченең дәлилләрен тикшерү өчен урынга чыкты. Казан шәһәре башкарма комитеты әлеге проблеманы игътибарсыз калдырмады һәм территорияне автомобиль шиннарыннан чистарту эшләрен башкарды. Гариза «хәл ителде» статусын алды.

III. Кеше хокукларын җинаять процессында, мәҗбүри тоту урыннарында, административ хокук бозулар турында эшләр буенча, судта яклау – 642 мөрәҗәгать.

(Шулардан «тоткарланган, шикләнелүче, гаепләнүчеләрнең хокуклары» – 145, «зыян күрүчеләрнең хокуклары» – 100, «җинаять башкарма системасында хөкем ителгәннәрнең хокуклары» – 344, «административ хокук бозулар турында эшләр буенча производствода кеше хокукларын яклау» – 16, «суд карарларына шикаять бирү» – 37).

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына кергән һәм иҗтимагый куркыныч гамәлләр кылган затларның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәүгә кагылышлы, аларга карата суд карары нигезендә иректән мәхрүм итү турында карар кабул ителгән һәр мөрәҗәгать игътибар белән карала, шул исәптән урынга чыгып та.

Мисал:

2022 елның мартында Вәкаләтле вәкил адресына хөкем ителгән Г. Эчке эшләр министрлыгының Яшел Үзән районы махсус кабул итү бүлмәсендә тоту мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать итте. Омбудсмен кушуы буенча Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәре һәм Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек ярдәмчесе әлеге мөрәҗәгать итүче янында булды.

Мөрәҗәгать итүче белән әңгәмәдән тыш, сәфәрнең максаты –гражданнарны вакытлыча тоту изоляторында, Эчке эшләр органнарының махсус кабул итү бүлмәләрендә тоту шартларын өйрәнү; күрсәтелә торган туклану сыйфатын, тоту шартларын тикшерү; махсус учреждение хакимияте тарафыннан мөрәҗәгатьләрне тикшерү; аларның хокукларын һәм гомумән законлы мәнфәгатьләрен үтәү.

Шикләнелүчеләр, гаепләнүчеләр һәм административ кулга алынган затларның хокукларын үтәү максатларында Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы җитәкчелеге адресына законнарны бозуның булган фактларын бетерү турында хат юлланды.

IV. «Законлы көченә кергән суд актларын үтәгәндә кеше хокукларын яклау» – 215 мөрәҗәгать (суд приставлары хезмәте эшчәнлеге – 139, суд карарын үтәмәү – 36, гаилә әгъзаларының алимент йөкләмәләре – 40).

Мисал:

2022 елның мартында Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче пенсионер В. мөрәҗәгать итте. Аңа карата кузгатылган башкару производствосы сәбәпле, аның пенсиясенең 50 проценты тотып калынган. Әлеге вазгыятьтә граждан өчен пенсия бердәнбер яшәү чыганагы булган.

2022 елның 1 февраленнән 2021 елның 29 июнендәге 234–ФЗ «Россия Федерациясе Граждан процессуаль кодексының 446 нчы маддәсенә һәм «Башкарма производство турында» федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль законның законлы көченә керүеннән чыгып, түләттерү мөрәҗәгатендә бурычлы гражданның айлык кереме Россия Федерациясе буенча тулаем алганда эшкә яраклы халык өчен яшәү минимумы күләмендә сакланып кала, Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгать итүченең айлык керемен яшәү минимумы күләмендә саклау мәсьәләсен карау турында Татарстан Республикасы Баш суд приставы адресына хат җибәрде.

Безнең мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәсендә суд приставы – башкаручы В.га пенсияне яшәү минимумы күләмендә саклау турында карар чыгарды.

V. «Хәрби хезмәткә чакырылганда кеше хокукларын яклау» – 1839 мөрәҗәгать (альтернатив граждан хезмәте – 12, хәрби бурыч (кичектерү, армиягә чакыру тәртибе, хәрби комиссариатлар эше) – 365, хәрби хезмәт (хәрби хезмәткәрләрнең вазыйфаи вәкаләтләрен һәм хезмәт бурычларын үтәү; контракт буенча хәрби хезмәт узу, контрактны озайту, хезмәтне чакыру буенча узу, ант кабул итү, хәрби хезмәткәрләрнең законны бозу фактлары, хезмәтне узу чорында сәламәтлек саклау һәм медицина ярдәменә хокук) – 1325, хәрби хезмәткәрләрнең статусы (хәрби хезмәттән киткән хәрби хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының социаль яклануы) – 137.

Мисал:

Вәкаләтле вәкил Аппаратына Казан шәһәрендә яшәүче Х. ханымнан тормыш иптәшен өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырудан кичектерү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать керде.

Мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, Х. «Нәфис Косметикс» АҖдә эшче вазыйфасында хезмәт эшчәнлеген башкара, шуңа бәйле рәвештә аңа бронь тиеш була. Ләкин Х. хәрби хезмәткә чакырылган һәм хәзерге вакытта мобилизацияләнүчеләрне җыю пунктында.

Вәкаләтле вәкил Казан шәһәренең Совет районы прокурорына Х. мөрәҗәгатендә китерелгән дәлилләрне тикшерүне оештыруны һәм кирәк булган очракта прокурор реакциясе чараларын күрүне сорап мөрәҗәгать итте.

Казан шәһәренең Совет районы прокуратурасыннан килгән хаттан күренгәнчә, Х. кире кайтарылган, мобилизацияләү буенча чакырылыш комиссиясе карары гамәлдән чыгарылган.

VI. «Финанс һәм хуҗалык эшчәнлеге өлкәсендә кеше хокукларын яклау» – 185 мөрәҗәгать.

VII. Башка мәсьәләләр – 696 мөрәҗәгать.

«Халык контроле» ТР дәүләт мәгълүмат системасы эшчәнлеге дәверендә үзен гражданнарга борчыган проблемалар турында иркен хәбәр итәргә мөмкинлек бирүче нәтиҗәле корал буларак таныткан, Вәкаләтле вәкил тарафыннан 370 мөрәҗәгать каралды.

Мисал:

Җәмәгать урыннарында, бигрәк тә уку йортларында янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре тайпылышсыз үтәлергә тиеш, чөнки гадәттән тыш хәлдә балалар да, өлкәннәр дә зыян күрергә мөмкин.

Мәгариф учреждениеләрендә куркынычсызлыкны тәэмин итүне контрольдә тоту мәгариф учреждениеләрендә тикшерүләр уздыру юлы белән дә, шулай ук гражданнарның «Халык контроле»нә тиешле категория буенча килгән хәбәрләрен көндәлек модерацияләү юлы белән дә алып барыла. Әйтик, 2022 елның ноябрендә системада гражданнарның мөрәҗәгатьләрен мониторинглау барышында Алабуга муниципаль районы балалар бакчаларының берсендә янгынга каршы көрәш чараларын бозу ихтималы ачыкланды.

Мин, әлеге балалар бакчасы хезмәткәрләренең һәм балаларның иминлеген тәэмин итү максатыннан, хәбәрнамәдә күрсәтелгән фактларны тикшерү өчен Татарстан Республикасы Прокуратурасына мөрәҗәгать җибәрдем.

Без оештырган тикшерү нәтиҗәләре буенча, Алабуга районы прокуратурасы тарафыннан янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозу факты расланды. Аерым алганда, термик тәэсир итү эзләре булган электр үткәргечләрне эксплуатацияләү факты, тыюга карамастан порошоклы янгын сүндергеч, электр сүндергечләре барлыгы ачыкланды, шуңа бәйле рәвештә прокуратура мәктәпкәчә учреждение җитәкчеләре адресына хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә кертте, ә гаепле затлар дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

Балалар бакчасы мөдиренә карата прокуратура тарафыннан РФ КоАП 20.4 нче маддәнең 1 өлеше (янгын куркынычсызлыгы таләпләрен бозу) буенча административ хокук бозу хакында эш кузгату турында карар чыгарылды. Шулай итеп балалар бакчасындагы тайпылышлар үз вакытында бетерелде. Әлеге мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча Алабуга муниципаль районы башлыгы адресына әлеге мәктәпкәчә учреждениенең янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү турында тәкъдим җибәрелде.

Алдагы хисап чорындагы кебек үк, гражданнар үз мөрәҗәгатьләрендә системаның баш модераторы буларак Вәкаләтле вәкилгә куйган мәсьәләләр: мөрәҗәгатьләргә «Гариза хәл ителгән» һәм «Дәлилләнгән кире кагу» статусы бирүнең нигезлелеге, шулай ук күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне киләчәктә аларны чишү өчен системага кайтару турындагы үтенечләр үзгәрмәгән.

2022 елда «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында, барлык статуслардан кире кайтарылган хәбәрләрне исәпкә алып, 91082 белдерү бастырылган, бу 2021 ел белән чагыштырганда 8 процентка күбрәк (83789 мөрәҗәгать), шуларның 70817е хәл ителгән – 78% (узган ел белән чагыштырганда 1 процентка күбрәк – 69889 мөрәҗәгать), 13332 гариза буенча эшләр планлаштырылган, 5424 шикаять дәлилле кире кагылган, 1509 мөрәҗәгать – эштә.

Хисап чорында гражданнардан килгән комментарийларның гомуми саны 2 млн 743 мең 711гә җитте, телләктәшлек итүчеләр саны – 1 млн 619 мең 809.

Хисап чорында система кулланучылары күбрәк түбәндәге төрләр: «Территорияне комплекслы төзекләндерү» – 24540 мөрәҗәгать, «Муниципаль юлларны карап тоту һәм ремонтлау» – 13070, «Кышкы чорда урам-юл челтәре объектларын карап тоту» – 12821, «Атамаларда һәм язуларда хаталар» – 7226 шикаять, «Тышкы яктыртуны оештыру» – 4379, «Коммуналь хезмәтләр» – 2374 шикаять, «Тышкы рекламада хокук бозу» – 2125 мөрәҗәгать, «Җәмәгать транспорты» – 1558 шикаять, «Йортсыз хайваннар» төре буенча – 1053 мөрәҗәгать җибәрде.

Агымдагы елда республика территориясендә гамәлгә ашырыла торган тармак инвестицион программалары ярдәмендә гражданнарның автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау буенча 11108 мөрәҗәгате һәм территорияләрне төзекләндерү һәм инфраструктураны үстерүгә кагылышлы 24461 мөрәҗәгате уңай хәл ителде.

«Дәүләт хезмәтләре. Бергәләп хәл итәбез» «Россия Федерациясенең дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» кире элемтә порталы аша 23668 хәбәр керде, шуларның иң күбе социаль түләүләр алу мәсьәләсе буенча (4109), комплекслы төзекләндерү буенча (703).

Татарстан Республикасының «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасын камилләштерү буенча даими эш алып барыла. Әйтик, торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү сыйфаты мәсьәләсе безнең халык арасында иң популяр мәсьәләләрнең берсе булып тору сәбәпле, хисап елның июнендә «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына барлык муниципаль берәмлекләрдә сыйфатлы торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен турыдан-туры җаваплы барлык идарәче компанияләр, торак милекчеләре ширкәтләре һәм башка оешмалар тоташтырылды.

Әлеге үзгәрешләр, беренче чиратта, республика халкының тормыш сыйфатын һәм идарәче оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру өчен, алар ягыннан кичекмәстән реакция таләп итә торган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән.

«Халык контроле»ндә мөрәҗәгатьләрне сыйфатлы һәм оператив башкару максатларында 2022 елда Вәкаләтле вәкил Аппаратында һәм республиканың муниципаль районнарында 44 эш киңәшмәсе үткәрелде, шул исәптән видеоконференция режимында, киңәшмәләр Татарстан Республикасы Президенты администрациясе, Татарстан Республикасы Прокуратурасы вәкилләре, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетларының структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм җаваплы башкаручылары катнашында узды.

Үткәрелгән чаралар нәтиҗәсендә һәм «Халык контроле» ТР дәүләт мәгълүмат системасына керүче мөрәҗәгатьләрнең сыйфатын күтәрү һәм вакытында карау буенча дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары белән уртак эш нәтиҗәсендә, хисап чорында, карау сроклары бозылган мөрәҗәгатьләр санын сизелерлек киметүгә, шулай ук уңай хәл ителгән мөрәҗәгатьләр санын арттыруга ирешелде. Шулай ук республиканың барлык муниципаль районнары һәм шәһәр округлары «Уңай хәл ителгән мөрәҗәгатьләр өлеше» индикаторын үтәүгә ирештеләр.

«Халык контроле» системасында мөрәҗәгатьләрне үтәү буенча аеруча актив эш Саба (98%), Мөслим (95%), Мамадыш (92%), Яр Чаллы шәһәре, Балык Бистәсе, Яңа Чишмә, Минзәлә (89%), Чистай (88%), Аксубай, Чүпрәле (87%), Апас (84%), Ютазы (83%), Азнакай, Тәтеш, Яшел Үзән (82%), Алексеевск, Баулы, Бөгелмә, Түбән Кама (81%), Спас (81%), Зәй (80%), Лениногорск (79%), Тукай (77%) муниципаль районнары башкарма комитетларында булды, системага килгән хәбәрләр сыйфатлы һәм вакытында карала һәм хәл ителә, аларда башкарылган белдерүләр өлеше 77–100% тәшкил итә.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендәге 1319 нчы «Халыкка хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын бәяләүне оештыру һәм үткәрү тәртибен раслау турында» карары нигезендә, без Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының (алга таба – Сервис) «Халыкка социаль әһәмияткә ия хезмәтләрне бәяләү» сервисы мәгълүматын анализлау буенча эш алып барабыз.

Халык бәяләве нигезендә «Табибка язылу» һәм «Торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре өчен түләү» сервислары кысаларында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы күрсәтә торган хезмәтләр сыйфаты рейтингы формалаштырылды.

Рейтинг нәтиҗәләре квартал саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, ай саен тиешле министрлыкларга җибәрелә. Татарстан Республикасы гражданнарының хокукларын һәм ирекләрен яклау эшендә муниципаль берәмлекләрдә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек ярдәмчеләренең роле кимеми. Алар – тәҗрибәле һәм абруйлы кешеләр. Алар арасында төрле белгечлекләр вәкилләре: юристлар, педагоглар, икътисадчылар бар. Аларның барысы да зур тормыш тәҗрибәсенә ия һәм халык проблемаларын белә, хокук яклау һәм агарту эшләре алып бара, күп кенә проблемаларны урыннарда оператив, артык хат алышмыйча һәм көттермичә хәл итә. Аларга килгән бер генә мөрәҗәгать тә игътибарсыз калмый. Аларның һәркайсы буенча диярлек тикшерүләр үткәрелә, запрослар һәм үтенечләр җибәрелә, мөрәҗәгать итүчеләргә квалификацияле киңәшләр һәм аңлатмалар бирелә.

Узган елда җәмәгатьчелек ярдәмчеләре 720 гражданны һәм 1000гә якын мөрәҗәгать кабул итте; 420 тапкыр алар ГЛОНАСС +112 системасы аша килгән мәгълүмат буенча тикшерүләргә барды; районнарның: хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу, коррупциягә каршы көрәш буенча; халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча; террорчылыкка каршы; балигъ булмаганнар эшләре, торак һәм башкалар буенча комиссияләр утырышларында катнашты; 10 хәрби частьта (Хабаровск крае, Оренбург һәм Свердловск өлкәләре, Башкортстан Республикасы) булды.

Әлеге бүлеккә йомгак ясап, шуны әйтәсе килә: 2022 ел дәвамында гражданнарның мөрәҗәгатьләре тематикасы сизелерлек үзгәрмәде. Елдан-ел гражданнардан алынган мәгълүмат күләме республика халкының кискен һәм социаль әһәмияткә ия проблемаларын ачыкларга мөмкинлек бирә, бу әлеге докладны төзү өчен нигез булып тора.

Вәкаләтле вәкилнең гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эше һәрдаим, теләсә нинди рәвештә алып барыла. 2022 елга бурычлар арасында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүдә Вәкаләтле вәкил түбәндәгеләрне билгеләде:

гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшне камилләштерүгә комплекслы якын килүне гамәлгә ашыру, бу мөрәҗәгать итүченең проблемасын гына түгел, тулаем проблеманы хәл итүне дә күздә тота;

гражданнар тарафыннан билгеләнгән иң кискен проблемаларны билгеләү, әлеге темалар буенча «түгәрәк өстәл»ләр уздыру;

Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Эксперт советы утырышлары;

республика дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарына, федераль хакимият органнарына рекомендацияләр һәм тәкъдимнәр әзерләү һәм җибәрү;

иң актуаль темалар буенча «кайнар элемтә»ләрне оештыру һәм уздыру, видеоэлемтә аша гражданнарны кабул итү, гражданнарны күчмә кабул итү;

министрлыклар һәм ведомстволар вәкилләре белән гражданнарны уртак (тематик) кабул итүне оештыру һәм уздыру эшен камилләштерү;

Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең һәм судларда Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләренең гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча өченче затлар сыйфатында катнашуы:

Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек ярдәмчеләренең эш нәтиҗәлелеген арттыру, шул исәптән укыту семинарлары үткәреп тә.

Бүлек 2. ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛНЕҢ КЕШЕНЕҢ СОЦИАЛЬ, ИКЪТИСАДЫЙ ҺӘМ МӘДӘНИЯТ ХОКУКЛАРЫН САКЛАУ БУЕНЧА ЭШЧӘНЛЕГЕ

2.1. ХЕЗМӘТ ХОКУКЛАРЫ

Социаль өлкә – кеше тормышының төп өлкәсе, чөнки ул медицина ярдәме, социаль яклау, мәгариф, эш белән тәэмин итү һәм торак сорауларын үз эченә ала.

Россия Федерациясе Конституциясе белән гарантияләнгән социаль, икътисадый хокуклар Россия кеше хокуклары һәм ирекләре системасында аерым урын алып тора.

Алдагы еллардагы кебек үк, безнең адреска кергән мөрәҗәгатьләрнең күпчелеге хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә кеше хокукларын яклау; гаиләне, аналарны, аталарны һәм балачакны яклау; социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклау; дәүләт һәм муниципаль торак фондларында торакка хокукны тәэмин итү: медицина ярдәмен дә кертеп, сәламәтлекне саклау; уңайлы әйләнә-тирә мохиткә, мәгарифкә хокукны тәэмин итү мәсьәләләренә кагыла иде.

Гадәттәгечә, хезмәткә хокук кешенең социаль-икътисадый хокуклары арасында аерым урын алып тора.

Соңгы елларда хезмәт хокуклары гарантияләрен арттыру минималь хезмәт хакы күләмен яшәү минимумына кадәр күтәрү буенча эзлекле сәясәт аша башкарылды.

Ел дәвамында минималь хезмәт хакы күләме сизелерлек артты (16,9 процентка). 2022 елның 1 гыйнварына ул 13890 сум, 2023 елның 1 гыйнварына 16242 сум тәшкил итте. Шул ук вакытта икътисадның бюджеттан тыш өлкәсе оешмаларында минималь хезмәт хакы турында өч яклы килешүләр нигезендә минималь хезмәт хакы күләме 2022 елның 1 гыйнварыннан – 16700 сум, ә 2023 елның 1 гыйнварыннан аена 19565 сум күләмендә билгеләнде.

Хезмәт өчен түләүнең минималь күләмен һәм уртача айлык хезмәт хакын арттыруга юнәлдерелгән дәүләт сәясәте күпчелек гражданнарның мәнфәгатьләренә җавап бирә һәм гражданнарның керемнәре, шул исәптән уртача хезмәт хакы үсеше темпларын арттыру буенча бурычларның берсе булып тора.

«2014–2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру барышында 2022 елда халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү чараларын гамәлгә ашыруга 2606935 сум күләмендә акча каралган, 2014 елдан 2022 елга кадәр Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә исәптә торучы гражданнар саны ике тапкыр – 15,2 меңнән 7,6 меңгә кадәр кимегән. Республикада эшсезлек дәрәҗәсе шулай ук Идел буе федераль округы буенча уртача күрсәткечтән ике тапкыр диярлек кимрәк (республика буенча 0,38%, Идел буе федераль округы буенча уртача 0,65%).

Статистик мәгълүматларга караганда, 2022 елның гыйнвар – октябрь айлары өчен Татарстан Республикасында уртача айлык хезмәт хакы 50287,7 сум тәшкил иткән, үсеш темпы 116,6% булганда, реаль хезмәт хакы – 101,8%.

Шул ук вакытта, нәтиҗәле хезмәт базарын үстерү, эшче көчләргә ихтыяҗ һәм тәкъдимнәрнең структур туры килмәвен җиңү һәм минималь хезмәт хакын арттыру хезмәт хакы түләмәү яки минималь күләмнән түбән түләү очраклары арту белән туры килмәве мөһим.

Әйтик, 2022 елның 11 аенда муниципаль берәмлекләрнең һәм шәһәр округларының территориаль ведомствоара комиссияләре тарафыннан 3664 предприятие каралган, 214 предприятиедә хезмәт хакының минималь хезмәт хакыннан кимрәк түләнүе ачыкланган. Хезмәт хакын вакытында түләмәү фактлары масштабы турында контроль-күзәтчелек органнарының статистик мәгълүматлары раслый. Татарстан Республикасында дәүләт Хезмәт инспекциясе мәгълүматларына караганда, 2022 елда узган елның 1 декабренә хезмәткәрләргә тоткарланган хезмәт хакы күләме ел башы белән чагыштырганда 2 тапкыр диярлек кимегән. Шуның белән бергә бурыч суммасы 140 млн сумга якын тәшкил итте.

2022 елның 11 аенда хисап даталарында (һәр айның беренче көне) бурычлы оешмалар саны 61дән 45 кә кадәр (шул ук мәгълүматлар буенча 2021 елда – 70–112, 2020 елда – 81–159) тәшкил иткән. Шуның белән бергә, хезмәт хакы буенча бурычлары булган хезмәткәрләр саны 1977дән 2798гә кадәр һәм бурыч 139,6дан 266,8 млн сумга кадәр (2021 елда – 2556дан 4613гә кадәр һәм 218,9 млн сумнан 350,2 млн сумга кадәр, 2020 елда 2983 дән 4712 гә кадәр һәм 226,8 млн сумнан 305,0 млн сумга кадәр).

Шулай итеп, 2022 елның аерым айларында республикада хезмәт хакы буенча бурыч күләме буенча вазгыять, алдагы ике ел белән чагыштырганда, тагын да начарайды. Шул ук вакытта хезмәт хакы буенча бурычлары булган хезмәткәрләр саны киму тенденциясен дә билгеләми булмый.

Хезмәт законнары белән хезмәткәрләрнең хезмәт хокукларын төгәл һәм җентекле регламентлауга карамастан, дәүләт тарафыннан гражданнарның хезмәт хокукларын якларга вәкаләтле органнарның вәкаләтләрен җентекләп регламентлауга карамастан, хезмәт хакын да, пособиеләрне дә вакытында түләмәүгә бәйле хокук бозулар хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә иң киң таралган булып кала.

Әйтик, Татарстан Республикасында дәүләт Хезмәт инспекциясе белән берлектә узган елның июнендә Вәкаләтле вәкил адресына мөрәҗәгать иткән Казан шәһәрендә яшәүче пенсионер һәм хезмәт ветераны гражданин К.ның хокукларын торгызуга ирешелде.

Татарстан Республикасында дәүләт Хезмәт инспекциясе Вәкаләтле вәкилнең хатын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча ЧОП адресына хезмәт законнарын бозуга юл куймау турында кисәтү ясады, шуның нәтиҗәсендә эш бирүче тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә әлеге оешмада ике ай эшләгән өчен хезмәт хакы түләнде.

Аерым очракларда гражданнарның хезмәт хокукларын яклауны тәэмин итү өчен Вәкаләтле вәкил прокуратура органнарына мөрәҗәгать итте.

Прокуратура органнары белән берлектә 2022 елның ноябрендә Вәкаләтле вәкил адресына мөрәҗәгать иткән Чаллы шәһәреннән гражданка Ш.ның хокуклары торгызылды, эш бирүче йөклелек һәм бала тудыру буенча пособие түләү өчен документларны һәм белешмәләрне Социаль иминият фондына җибәрмәгән булган. ҖЧҖ җитәкчесе адресына прокурор акты чыгарылу нәтиҗәсендә кирәкле белешмәләр бирелде һәм мөрәҗәгать итүчегә пособие билгеләнде һәм түләнде.

Хезмәт өчен түләүгә хокукны гамәлгә ашыру проблемасының системалы факторы турында прокуратура органнары статистикасы да раслый.

Татарстан Республикасы Прокуратурасы мәгълүматларына караганда, 2022 ел дәвамында прокурорлар тарафыннан хезмәт хакы буенча 137 млн сумнан артык бурыч ачыкланган. Прокурор реакциясе чаралары нәтиҗәсендә узган елда 612 млн сум күләмендә хезмәт хакы буенча бурыч түләнгән. Шул ук вакытта республикада бюджет өлкәсе, дәүләт һәм муниципаль предприятиеләр хезмәткәрләре алдында хезмәт хакы буенча бурыч юк.

Судка мөрәҗәгать итү – гражданнарның хезмәт хокукларын яклауның иң киң таралган ысулларының берсе. Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе мәгълүматларына караганда, хезмәткәрләр эш бирүчедән хезмәт хакын судка, ә аннары суд приставлары-башкаручыларга мөрәҗәгать итеп кенә ала алган очраклар арткан. 2022 елның 20 декабренә фактик үтәлеш белән гомуми суммасы 113 млн 279 мең сумлык 2129 башкарма эш тәмамланган (2021 елда – 2281 башкарма эш, гомуми суммасы 67 млн 397 мең сум; 2020 елда – 3514 башкарма эш, 92 млн 219 мең сум).

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе мәгълүматларын анализлау күрсәткәнчә, структур бүлекчәләрдә мәҗбүри үтәлештә булган башкарма эшләр саныннан «Башкарма эш турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ федераль законда күрсәтелгән нигезләр буенча фактик үтәлеш белән тәмамланган башкарма эшләрнең чагыштырма авырлыгы кими бара. 2022 ел нәтиҗәләре буенча бу күрсәткеч 46 процентны тәшкил итте. (2021 – 52,8%, 2020 – 73%).

Башка сүзләр белән әйткәндә, узган ел нәтиҗәләре буенча 10 эш бирүчегә карата судның хезмәт хакын түләтү турында карары чыгарылган һәм башкару эше кузгатылган, бары тик 4–5 эш бирүче генә исәп-хисап ясаган. 2021 елда 10 эш бирүченең 5–6сы, 2020 елда 7се исәп-хисап ясаган.

Тулаем алганда, гражданнарның тулы хезмәт хакын яисә хезмәт мөнәсәбәтләренә бәйле башка түләүләрне вакытында алуга хокуклары бозылу турында шикаятьләрен алганда, Вәкаләтле вәкил контроль-күзәтчелек органнарына мондый мөрәҗәгатьләрне тикшерүне үткәрү турында гына түгел, ә оешма җитәкчеләренә, аларны оператив рәвештә бетерү максатыннан, үз позициясен дә белдерде. Бу чара хезмәт хокукларын бозуның сәбәпләре хезмәткәрне эштән чыгару процессында, шул исәптән хезмәт хокукы нормаларын белмәү сәбәпле килеп чыккан бәхәсләр булган очракларда эшләнде.

Мәсәлән, Вәкаләтле вәкил фикеренчә, 2022 елның июлендә Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткән гражданка М.ны эштән җибәргәндә, хезмәт законнары нормалары таләпләре бозылган. Татарстан Республикасында дәүләт Хезмәт инспекциясе вәкиле белән урынга чыгып тикшерү нәтиҗәләре буенча, мөрәҗәгать итүчене эштән җибәргәндә, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 84.1 маддәсендәге 2 өлешен һәм 84.1 маддәсендәге 5 өлешне бозу фактлары ачыкланды. Хезмәт законнары нормаларын бозуны исәпкә алып, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан, Вәкаләтле вәкилнең хатын карау нәтиҗәләре буенча гаепле зат җаваплылыкка тартылган, ә МБДОУ мөдире хезмәт законнары буенча квалификация күтәрү курсларына җибәрелгән.

Башка мисал. Вәкил адресына Казан шәһәрендә яшәүче гр-ка Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы сәламәтлек саклау учреждениесе вазыйфаи затлары аның белән хезмәт килешүен өзгәндә аның хезмәт хокуклары бозылуга шикаять белән мөрәҗәгать итте. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Вәкаләтле вәкилнең мөрәҗәгате җибәрелде, аны карау барышында шикаятьнең дәлилләре расланды. Тышкы алмаштыручы белән хезмәт килешүен туктату факты буенча, хезмәт законнарында каралган эштән азат итү турында белдерүнең ике атналык срогы тәмамлануы һәм моңа якларның ризалыгы булмау сәбәпле, әлеге оешмада кадрлар эше өчен җаваплы вазыйфаи зат дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

Гражданнарның хезмәт хокукларының аерылгысыз элементы булып куркынычсыз хезмәт шартларына хокукны тәэмин итү һәм санитар-гигиена таләпләрен үтәү тора. Хезмәтне саклау өлкәсендәге хәлнең мөһим индикаторы булып җитештерүдә булган бәхетсезлек очраклары саны санала.

Статистик мәгълүматларга караганда, 2019–2022 елларда җитештерүдә үлем белән тәмамланган зыян күрүчеләр саны 2 тапкыр кимегән.

Үз чиратында, производствода, хезмәткәрләр өчен авыр нәтиҗәләргә китергән бәхетсезлек очраклары 2022 елда, оештыру-хокукый формасына бәйсез оешмаларда булган.

Зыян күрүчеләрнең иң күп саны эшкәртү производстволарында теркәлгән: эшкәртү производстволарында – 36 кеше, шул исәптән үлем белән тәмамланган 4 очрак; ташу һәм саклау – 35 кеше, шул исәптән үлем белән тәмамланган 10 очрак; төзелеш – 9 кеше, шул исәптән үлем белән тәмамланган 1 очрак; файдалы казылмалар чыгару – 8 кеше, шул исәптән үлем белән тәмамланган 2 очрак; сәүдә – 7 кеше, шул исәптән 1 үлем очрагы.

Татарстан Республикасы дәүләт Хезмәт инспекциясе мәгълүматларына караганда, 2022 елда производствода 119 төркемле бәхетсезлек очрагы булган, шулай ук Татарстан Республикасында теркәлгән предприятиеләрдә авыр һәм үлем белән тәмамланган бәхетсезлек очраклары теркәлгән. Шулардан: төркемле бәхетсезлек очраклары – 11, авыр нәтиҗә белән – 89, үлем белән тәмамланган очраклар – 19.

Җитештерүдә иң күп бәхетсезлек очраклары Казан, Яр Чаллы, Түбән Кама һәм Әлмәт муниципаль районнарында булган. Шуңа бәйле рәвештә тармак министрлыкларыннан производствода бәхетсезлек очраклары килеп чыгуны кисәтү буенча чаралар һәм профилактик чаралар үткәрүне тәэмин итүләрен сорыйм.

Җитештерүдә авыр нәтиҗәле иң күп бәхетсезлек очраклары Казан, Яр Чаллы, Түбән Кама һәм Әлмәт муниципаль районнарында булган.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: республикада производствода үлемгә китергән бәхетсезлек очраклары санын киметү эше административ йогынты чаралары яки гаепле вазыйфаи затларны җинаять җаваплылыгына тарту чаралары күрүдән тыш дәвам итте. Җитештерүдә бәхетсезлек очраклары санын киметү буенча эш дәвам итте, шул исәптән «Татарстан Республикасында 2014–2025 елларга хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау» ярдәмче программасы чараларын гамәлгә ашыруга ел саен бюджеттан 5 млн сум бүлеп бирү юлы белән дә, шул исәптән, дәвалау-профилактик хезмәт күрсәтүне камилләштерүне һәм эшләүче халыкны индивидуаль һәм коллектив яклауның заманча югары технологияле чаралары белән тәэмин итүне дә кертеп, хезмәткәрләрнең хезмәт шартларын яхшыртуга юнәлдерелгән һәм заманча технологияләр нигезендә хезмәтне саклау буенча чараларны тормышка ашыру бурыч булып тора.

Республиканың муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында муниципалитетлар каршында оештырылган һәм җитештерүдә хезмәткәрләрнең сәламәтлеген саклауга юнәлдерелгән хезмәтне саклауның мөһим мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр эшләргә юнәлдерелгән хезмәтне саклау буенча координацион советлар эшенә дә зур игътибар бирелә.

Уңай динамикага карамастан, производствода бәхетсезлек очраклары саны шактый югары булып кала.

Шуңа бәйле рәвештә Россия Федерациясе Хезмәт кодексына 2022 елның 1 мартыннан үз көченә кергән закон үзгәрешләре һәм хезмәтне саклау өлкәсендәге яңа кагыйдәләрне регламентлаштыру өлешендә хезмәтне саклау өлкәсенә кагылышлы, нигезендә куркынычларны кисәтү һәм хезмәткәрләр имгәнүләрен киметү яткан кайбер норматив һәм хокукый актлар, җитештерү травматизмын профилактикалауның башка чаралары белән бергә киләчәктә җитештерүдә бәхетсезлек очракларын киметергә мөмкинлек бирер дип ышанабыз.

2.2. СОЦИАЛЬ ТӘЭМИН ИТҮГӘ ХОКУК

Татарстан Республикасында дәүләт социаль сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре, беренче чиратта, объектив сәбәпләр буенча җәмгыять кайгыртуы таләп ителүчеләрнең тормыш сыйфатын һәм матди тормыш дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән.

Яңа проблемалар шартларында гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү дәүләт хакимияте органнары тарафыннан аерым игътибар таләп итте. 2022 елда, Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 16 мартындагы 121 нче указы нигезендә, дәүләт тарафыннан адреслы ярдәм күрсәтү максатларында авыр тормыш хәлендә калган төрле категориядәге гражданнарга ярдәм итүнең өстәмә чаралары күрелде. 2022 елның апреленнән 8 яшьтән 17 яшькә кадәрге балалары булган, кереме аз булган гаиләләргә айлык түләү кертелде, уллыкка (кызлыкка) бала алган ата-аналар өчен түләүләр күләме артты.

Шунысы куанычлы: социаль ярдәм чараларын финанслау күләме ел саен арта бара. Узган елда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы линиясе буенча социаль ярдәм чараларына 24,7 млрд сум бүлеп бирелгән, шулардан федераль бюджет акчасы – 10,6 млрд сум, төбәк бюджет акчасы – 14,1 млрд сум.

Татарстан Республикасында 6 федераль һәм 55 республика чараларын үз эченә алган социаль ярдәм чараларының ныклы системасы формалаштырылды.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2022 елда республика территориясендә социаль ярдәм чараларын алучылар саны 1,29 млн кеше тәшкил иткән, шул исәптән 0,88 млн кеше – төбәк социаль түләүләрен алучылар.

Социаль тәэмин итүгә аерым затлар даирәсе хокукларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре Вәкаләтле вәкил эшендә өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып тора.

Узган ел дәвамында Вәкаләтле вәкил социаль тәэмин итү өлкәсендә хокукларны саклау мәсьәләләре буенча максатчан аңлату эшләре алып барды, шул исәптән тиешле тематик «кайнар элемтә» аша да. Консультатив-аңлату эшендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе, «Татарстан Республикасы буенча медик-социаль экспертизаның Баш бюросы» учреждениесе белән тыгыз хезмәттәшлек алып барылды.

Халык белән актив аңлату эшләре алып бару иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең әлеге өлкәсендә гражданнарның шикаятьләре санына да күпмедер дәрәҗәдә йогынты ясады. 2022 елда Вәкаләтле вәкилгә социаль тәэмин итү мәсьәләләре буенча 434 шикаять килде.

Халык белән нәтиҗәле хезмәттәшлекне оештыру инструментларының берсе – «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» кире элемтәсе платформасы. Мәсәлән, әлеге платформа аша 2022 елда социаль түләүләр билгеләү, социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү, социаль ярдәм күрсәтү, торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча компенсацияләр бирү һәм башкаларга бәйле социаль мәсьәләләр буенча гражданнардан 4870 мөрәҗәгать керде.

Нәтиҗәле социаль сәясәтне инвалидларның социаль хокукларын гамәлгә ашыруда башка гражданнар белән тигез мөмкинлекләрне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексыннан башка күз алдына да китереп булмый.

Инвалидлыгы булган кешеләр аларга карата аерым мөнәсәбәткә һәм ярдәмгә мохтаҗ, ә инвалидларның хокукларын гамәлгә ашыру һәм яклау мөмкинлеге дәүләтнең үсеш күрсәткече, җәмгыятьнең җитлеккәнлек индикаторы булып тора.

Татарстан Республикасында хәзерге вакытта 280,9 мең инвалид яши (шулардан 118001 кеше – 3 төркем инвалидлар, 108616 кеше – 2 төркем инвалидлар, 37181 кеше – 1 төркем инвалидлар, 17172 кеше – инвалид балалар).

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, республикада социаль тернәкләндерү буенча 6 инвалидларны тернәкләндерү үзәге, 12 балалар тернәкләндерү үзәге, 11 дәүләтнеке булмаган оешма тарафыннан хезмәт күрсәтелә (3 – өлкәннәр өчен, 8 – балалар өчен).

6101 инвалид (шул исәптән 640 кеше – дәүләтнеке булмаган оешмаларда), 12150 инвалид һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән бала (шул исәптән 5763 кеше – дәүләтнеке булмаган оешмаларда); 396 инвалид бала тәрбияләүче 389 гаиләгә өйләрендә хезмәт күрсәтелде, 6 социаль-тернәкләндерү бүлеге тарафыннан өлкән яшьтәге 3117 кешегә хезмәт күрсәтелде, шулай ук дәүләтнеке булмаган 9 оешмада 5556 инвалидка хезмәт күрсәтелде.

2022 елда, рәисе Вәкаләтле вәкил булган Татарстан Республикасында төбәк белән идарә итү үзәгенең проект офисы ка-

рары нигезендә, «Диалог Регионы» коммерциячел булмаган оешмасының тикшеренүләре буенча белгечләр тарафыннан сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затларның аеруча проблемалы мәсьәләләрен билгеләү максатында, массакүләм сораштыру форматында социологик тикшерү уздырылды, анда 3 мең 440 кеше катнашты.

Аның нәтиҗәләре сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар көн саен очраша торган берничә проблемалы өлкәне күрсәтте. Бу инвалид балалар, шул исәптән инвалид балалар белән эшләү тәҗрибәсе булган табиблар һәм белгечләр җитмәү; мәгариф, спорт һәм тернәкләндерү учреждениеләре җитмәү (кайбер районнарда мондый учреждениеләр төзүне сорап үтенечләр килде); техник тернәкләндерү чараларын алганда кыенлыклар, тоткарлыксыз мохит тәэмин итү; инвалидлыгы булган кешеләр өчен уңайлы шәһәр мохите булдыру буенча гамәлдәге федераль һәм төбәк программалары турында хәбәрдарлык аз булу; инвалидлыгы булган кешеләрне, шул исәптән мәгариф оешмаларында да һәм җәмәгать урыннарында инвалидлыгы булган балаларга карата сабырсыз һәм ихтирамсыз мөнәсәбәт.

Узган елның май аенда Татарстан Республикасында төбәк белән идарә итү үзәгенең проект офисы утырышында республика министрлыклары, ведомстволары һәм иҗтимагый оешмалары белән берлектә уздырылган социологик тикшеренүгә йомгак ясалды, шулай ук инвалидлыгы булган кешеләрнең тормыш сыйфатын яхшыртуга бәйле аеруча мәсьәләләрне хәл итү буенча тәкъдимнәр ясалды.

Инвалидлык һәм сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затларның хокукларын яклауга бәйле аеруча кискен мәсьәләләрне хәл иткәндә үзенең нәтиҗәлелеген Вәкаләтле вәкил Аппаратының иҗтимагый оешмалар белән тыгыз хезмәттәшлеге күрсәтте, шул исәптән аларның вәкилләре белән даими очрашулар да. Вәкаләтле вәкил чакыруы буенча җәмәгать оешмалары вәкилләре киңәшмәләргә, «түгәрәк өстәл»ләргә, Вәкаләтле вәкил каршындагы Экспертлар советы утырышларында актуаль темалар буенча фикер алышуда актив катнаштылар.

2022 елның 1 февралендә Инвалид балаларның ата-аналарының бөтенроссия оешмасының төбәк бүлеге идарәсе әгъзасы Григорьева М.А. Вәкаләтле вәкил каршындагы Эксперт советының киңәйтелгән утырышында читтән торып тикшерү формасында инвалидлыкны билгеләү/озайтуның проблемалы мәсьәләләрен күтәрде. Асылда медик-социаль экспертиза уздыруның бары тик читтән торып үткәрелү тәртибен билгеләүгә бәйле рәвештә инвалидны (инвалид баланы) реабилитацияләүнең индивидуаль программасын эшләгәндә, инвалидка карата тернәкләндерү чараларын сайлаганда, шулай ук инвалидларны техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итү өчен медицина күрсәтмәләрен һәм каршылыкларын билгеләгәндә кыенлыклар барлыкка килде.

Кешеләрнең инвалидлыгын билгеләү/озайтуга бәйле мәсьәләләр Вәкаләтле вәкилнең «Татарстан Республикасы буенча медик-социаль Баш бюросы», Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Россия Федерациясе Социаль иминият фонды Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе вәкилләре белән эш киңәшмәләрендә берничә тапкыр каралу предметы булды.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: 2022 елның апрелендә Россия Федерациясе хөкүмәте тарафыннан гражданнарның медик-социаль экспертиза узу форматын сайлау хокукын кертү өлешендә яңа кагыйдәләр урнаштырылу инвалид кешеләр очрашкан мәсьәләләрне минимальләштерергә һәм аны узу процедурасын камилләштерергә мөмкинлек бирде.

Һичшиксез, инвалидлыгы булган затларны тернәкләндерүнең мөһим өлеше булып инвалид тормышындагы катгый чикләүләрне бетерүдә булышкан техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итү тора.

Социаль иминият органнары эше контрольлек итүче органнар, җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан игътибар үзәгендә тора.

Шул ук вакытта Вәкаләтле вәкил билгеләп үткәнчә, техник тернәкләндерү чаралары бирүне озакка сузулары турында төрле муниципаль районнардан инвалидлардан килгән мөрәҗәгатьләр актуальлеген югалтмыйлар.

Асылда әлеге тема буенча мәсьәлә Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге белән үзара хезмәттәшлектә оператив хәл ителде. Шул ук вакытта аерым очракларда Вәкаләтле вәкил хокук бозуларны оператив рәвештә бетерү максатында үз позициясен белдерде.

Шулай итеп, Вәкаләтле вәкил адресына Татарстан Республикасының Лениногорск муниципаль районында яшәүче гражданин Р.Н. Борһанов, озак вакытлар техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итмәүләре турында, ә атап әйткәндә, шәхси эшләнгән колакча сорап мөрәҗәгать итте. Мөрәҗәгатьне карау барышында безнең тарафтан Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге тарафыннан билгеләнгән подрядчы-җитештерүче тарафыннан үлчәмнәрне алынмавы, нәтиҗәдә гражданинның кирәкле техник тернәкләндерү чарасы белән вакытында тәэмин ителмәве ачыкланды. Шул ук вакытта дәүләт контрактында үлчәмнәрне алу датасын, вакытын һәм урынын килештерү механизмы билгеләнмәгән, шулай ук подрядчы аларны алу өчен яшәү урынына барырга тиешле затлар билгеләнмәгән.

Подрядчы белән дәүләт контрактындагы шартларның билгесезлеге үлчәмнәрне алу датасын, урынын һәм вакытын алучылар белән килештерү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге җаваплы вазыйфаи затлары тарафыннан башкарылган эшләрнең барышын тикшерү тәртибе булмау үлчәмнәрне алу срокларын озакка сузуга һәм аның нәтиҗәсендә, гражданинның тиешле техник тернәкләндерү чарасы белән вакытында тәэмин итмәүгә китерде. Вәкаләтле вәкил катнашканнан соң, мөрәҗәгать итүче колакча белән тәэмин ителде. Вәкаләтле вәкил шулай ук бәян ителгән фактлар буенча тикшерү үткәрү турында Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге җитәкчесенә мөрәҗәгать юллады. Доклад язган вакытта Вәкаләтле вәкилнең хаты карауда иде.

Шул ук вакытта инвалидлыгы булган затларны техник тернәкләндерү чарасы белән тәэмин итү срокларын сузу кайбер очракларда контрактның башлангыч (максималь) бәясен билгеләүнең барлык ысулларын кулланмауга китерде.

Казан шәһәрендә яшәүче гражданка Е. дәүләт контрактын вакытында алда төзәмәү сәбәпле, озак вакыт сидек кудыру өчен кирәкле савыт белән тәэмин ителмәгән. Шул ук вакытта Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге дәүләт учреждениесе биргән мәгълүматтан аңлашылганча, гражданнарның үз вакытында тәэмин ителмәве контрактларның башлангыч (максималь) бәяләрен билгеләү өчен потенциаль тәэмин итүчеләрдән коммерция тәкъдимнәре булмау сәбәпле булган.

Мөрәҗәгатьне карау барышында безнең тарафтан Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге контрактның башлангыч (максималь) бәяләрен билгеләүнең башка ысулларын куллану мөмкинлеге ачыкланды. https://zakupki.gov.ru/ рәсми сайтында урнаштырылган мәгълүматка анализ, Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2017 елның 18 сентябрендәге 1995-р күрсәтмәсе нигезендә, карала торган очракта, контрактның башлангыч (максималь) бәясе контрактлар реестры нигезендә билгеләнә алуын күрсәтте.

Бәян ителгәннәргә бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге адресына сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затларның хокукларын бозуны бетерү максатында, контрактларны үз вакытында төзүгә юнәлдерелгән өстәмә чаралар күрү кирәклеге турында тәкъдимнәр җибәрелде.

Социаль гарантияләрнең һәм инвалидлар хокукларының аеруча әһәмиятен исәпкә алып, гражданнардан шундый ук шикаятьләр күп мәртәбәләр керүгә бәйле рәвештә, Вәкаләтле вәкил Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы буенча Пенсия һәм социаль иминият фонды бүлегенә тернәкләндерү чараларын сатып алуга дәүләт контрактларын үз вакытында төзү максатларында контрактның гамәлдәге законнарда билгеләнгән башлангыч (максималь) бәяләрен билгеләүнең барлык ысулларын кулланырга тәкъдим итүне кирәк дип саный.

Инвалидларны тернәкләндерүнең мөһим инструментларының берсе – спорт. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән күп кенә кешеләр өчен спорт уеннарында катнашу, спорт эшчәнлеге белән шөгыльләнү мөмкинлеге, ярышларда катнашу мөһим физик һәм психологик фактор - тулы кыйммәтле тормыш факторы булып тора.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен спорт эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр мониторингы, безнең карашка, аерым аспектлар буенча эшне камилләштерү кирәклеге турында нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә.

Юл-транспорт һәлакәтеннән соң уң аягын югалткан, әмма спорт белән шөгыльләнүен дәвам иткән Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы кешесенең мөрәҗәгатен карау нәтиҗәсендә, безнең тарафтан спорт белән шөгыльләнүче инвалидлар очраша торган төп проблема ачыкланды – аларның дәресләре өчен Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2005 елның 30 декабрендәге 2347-р күрсәтмәсе белән расланган инвалидка бирелә торган реабилитация чараларының, техник тернәкләндерү чаралары һәм хезмәтләрнең федераль исемлеге кысаларында «Техник тернәкләндерү чаралары (әйберләр) классификациясен раслау турында» Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 13 февралендәге 86н номерлы боерыгы белән билгеләнгән махсус исемлек кысасында махсус техник тернәкләндерү чаралары алу мөмкинлеге булмау.

Махсуслаштырылган техник тернәкләндерү чараларының югары бәясе аркасында инвалидлыгы булган яки сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр аларны ала алмый. Спорт төрләренең төрле төрләре белән шөгыльләнү өчен каралган протезлар үзенчәлекләргә ия һәм файдаланыла торган материаллары, техник характеристикасы һәм конструктив үтәү буенча да федераль исемлек кысасында бирелә торган протезлардан аерылып тора.

Карала торган очракта сноубордта йөрү буенча профессиональ спорт белән шөгыльләнү өчен мөрәҗәгать итүчегә махсус протез кирәк булган, шуның нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүче төрле дәүләт органнарына мөрәҗәгать иткән, әмма федераль исемлектә андый булмаганга күрә, һәркайда кире кагылган.

Күрсәтелгән мәсьәләне хәл итү өчен Россия Федерациясе хөкүмәтенә спорт белән шөгыльләнү өчен махсус техник тернәкләндерү чараларын федераль исемлеккә кертү турындагы тәкъдим белән мөрәҗәгать итү турындагы сорауны карау үтенече белән Вәкаләтле вәкил Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Т.Н. Москалькова һәм Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутаты адресына мөрәҗәгать итте.

Шул ук вакытта Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру кысаларында инвалидларга, инвалид балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм итүнең өстәмә (федераль) чараларын Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары акчалары исәбеннән билгеләргә, шулай ук күрсәтелгән техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итүгә хокукы булган кешеләр исемлеген, техник тернәкләндерү чаралары исемлеген һәм аларны бирү тәртибен билгеләргә хокуклы булуын искә алып, безнең тарафтан Татарстан Республикасы Премьер-министры адресына инвалидларга, инвалид балалары булган гаиләләргә, спорт техник тернәкләндерү чаралары белән республика бюджеты акчасы исәбеннән тәэмин итү мөмкинлеге турындагы мәсьәләне карауны сорап, хат юлланды. Доклад язган вакытта Вәкаләтле вәкилнең хаты карала иде.

Инвалидларның тормыш өчен әһәмиятле барлык ихтыяҗларын яшәү тирәлегенең уңайлылыгыннан хокук бозуларга җайлашу зарурлыгына бәйле. Инвалидларга карата сәясәтне бәяләү критерие булып, торак, транспорт, шулай ук мәгарифкә, эшне, мәдәниятне һәм мәгълүматны да кертеп, физик мохитнең үтемлелеге тора.

«Россия Федерациясендә инвалидларның социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә инвалидларга карата дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы 2011 елдан бирле «Уңайлы мохит» Россия Федерациясе дәүләт программасын гамәлгә ашыруда катнаша.

Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы объектларының файдалануның интерактив картасы гамәлдә (http://karta.tatar.ru), ул Татарстан Республикасы буенча гомуми вазгыятьне анализлап, шулай ук республика муниципаль берәмлекләре кисемендә аерым карап, объектлардан һәркем файдалана алырлык булу мониторингын үткәрергә мөмкинлек бирә.

2015–2030 елларга Татарстан Республикасында инвалидларның хокукларын яклау өлкәсендә гамәлдәге законнар нормалары нигезендә объектлар һәм хезмәт күрсәтүләрдән инвалидларның файдалану мөмкинлеген арттыру буенча чаралар планы («юл картасы») эшләнде. 2022 елда 2030 елга кадәр чорда объектлар һәм хезмәт күрсәтүләрдән инвалидларның файдалана алуы күрсәткечләрен арттыру буенча республика «юл картасы» кысасында социаль өлкәнең 20 объектында 24 млн сумлык адаптация эшләре үткәрелгән. 2022 елның 26 декабренә Татарстан Республикасы объектларыннан файдалануның интерактив картасына паспорт ясау нигезендә 6822 объект буенча мәгълүмат кертелгән.

Мөмкин булган мохитне тәэмин итү һәм биналарга һәм корылмаларга, транспортка һәм мәгълүматка каршылыксыз керүне тәэмин итүнең сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен иң мөһим хокукларының берсе булуын искә алып, без элеккечә дә инвалидлыгы булган инвалидларның, спорт, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына керүен тәэмин итү ситуациясен мониторинглау буенча эшне дәвам иттек, шул исәптән «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасын файдаланып.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: ТРның «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында 2022 елда «Уңайлы мохит» категориясендә 230 мөрәҗәгать бастырылган, шуларның 153е инде хәл ителгән.

Күпчелек очракта без бу юнәлештә республика муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларының уңай эшен билгеләп үттек. Мисалларның берсе сыйфатында Татарстан Республикасы Яшел Үзән шәһәре муниципаль районы башкарма комитетының Яшел Үзән шәһәре, Гоголь урамы, 53 нче йортта урнашкан кибеткә керү пандусының булмавы турындагы гаризасы оператив хәл ителүен китерергә була: хәзер гражданнарның тоткарлыксыз хәрәкәт итү мөмкинлеге барлыкка килде.

Шул ук вакытта әлеге категория буенча заявкаларны үтәү срокларын нигезсез арттыру очраклары да булды. Мәсәлән, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары хакимияте тарафыннан 2024 һәм 2025 елларга пандуслар урнаштыру һәм тротуардагы ян ташны түбәнәйтү эшләрен үткәрү планлаштырыла. Шундый ук хәл җәяүлеләр кичүендә биек бордюр турында гаризаны үтәү буенча килеп туды, аның җаваплы башкаручысы – Казан шәһәренең Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары хакимияте.

Анализланган фактлар, үз чиратында, муниципаль берәмлекләр җитәкчеләрен, җаваплы башкаручыларны чакырып, без оештырган киңәшмәләр кысасында фикер алышу предметы булды, әмма аларны карауның барышы хәл ителгәнчегә кадәр контрольдә алынды.

Алдагы еллардагы кебек үк, «Уңайлы мохит» категориясе буенча «Халык контроле» системасында Казан шәһәренең җир өсте һәм җир асты җәяүлеләр кичүләрендә лифтларның төзексезлегенә гражданнар шикаятьләрен мониторинглау эше дәвам итте, шул исәптән Вәкаләтле вәкил ярдәмчеләре «Стройтехлифтмонтаж» ЖҖҖ эксплуатация бүлеге белән берлектә җир өсте һәм җир асты кичүләрен тикшерде, мониторинг нәтиҗәләре төзексезлекләрне бетерү чараларын күрү өчен Казан шәһәренең башкарма комитетына җибәрелде.

Урынга барып тикшерүләр нәтиҗәләре буенча лифт җиһазларының төзексезлеге санын киметүгә ирешелде, шуңа бәйле рәвештә гражданнар мөрәҗәгатьләре саны минимумга кадәр кимеде. Әгәр 2021 ел ахырында лифтлар белән җиһазландырылган җир асты һәм җир өсте кичүләренең 27 корылмасыннан 16 корылма кулланылмаган булса, 2022 елның декабренә – барлыгы 6.

«Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасының баш модераторы хокукларында Вәкаләтле вәкил, инвалидларның социаль инфраструктура объектларына тоткарлыксыз керүен тәэмин итмәүгә кагылышлы кайбер мөрәҗәгатьләр буенча үз позициясен белдерде.

Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университеты спорт объекты янында (Казан шәһәренең «Гимнастика үзәге») халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәренә керү юлын кирәкле төшү баскычы белән төзекләндерү мәсьәләсе Вәкаләтле вәкил катнашканнан соң уңай хәл ителде. Ә бит әлеге мөрәҗәгатьне караганда җаваплы башкаручылар тарафыннан «Дәлилле кире кагу» статусы бирелүе ачыкланган иде.

Кайбер очракларда Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгатьләрне караганда прокуратура органнарына мөрәҗәгать итте.

Мәсәлән, Казан шәһәрендәге «Көньяк» автовокзалы бинасында лифтның төзексезлеге мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча, җавап системасында урнаштырып, аңа «Дәлилле кире кагу» статусы бирде, аның эчтәлегеннән күренгәнчә, әлеге күчемсез милек объекты автовокзал булып тормый, нәтиҗәдә объектның милекчесенең анда «уңайлы мохит», шул исәптән лифтның эшкә сәләтлелеген тәэмин итү бурычы тумый. Үз чиратында, билгеләнгән проблема инвалидлар һәм халыкның аз хәрәкәтләнә торган төркемнәре өчен җәмәгать туклануы йортына һәм автовокзал бинасында урнашкан бәдрәф бүлмәсенә керү мөмкинлеге булмауга китерде. Безнең инициатива белән оештырылган күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча Казан шәһәре Идел буе районы прокуратурасы тарафыннан «Көньяк» ЖҖҖ җитәкчесе адресына күрсәтмә кертелде. Мәгълүмат системасында җаваплы башкаручылар тарафыннан мәсьәләнең уңай хәл ителүе күрсәтелде.

Тормыш функцияләренең чикләнгән булуына карамастан, инвалидларның, гади кешеләр кебек үк, хокуклары, шул исәптән хезмәт хокукы да бар. Шунысын билгеләп үтү мөһим, кеше өчен хезмәт эшчәнлеге тулы кыйммәтле тормыш алып баруда мөһим шарт булып тора. Ул үзенең яшәешен икътисадый яктан тәэмин итү ысулы гына түгел, үз сәләтләрен тормышка ашыру мөмкинлеге дә.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2022 елның октябренә Татарстан Республикасында хезмәткә сәләтле яшьтәге инвалидлар саны 108196 кеше тәшкил иткән, шуларның 31167 (29%) кеше хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашырган. 2022 елның 11 аенда эш эзләү максатыннан республиканың мәшгульлек хезмәте органнарына 2294 инвалид мөрәҗәгать иткән, шулардан халыкның мәшгульлек үзәкләре ярдәмендә 1562 (68%) кеше эшкә урнаштырылган.

Инвалидларга хезмәт белән тәэмин итүне гарантияләп, дәүләт эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче гражданнарга мәшгульлеккә ярдәм итү программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, өстәмә эш урыннары һәм махсуслаштырылган оешмалар булдыру, индивидуаль якын килүне тәэмин итү юлы белән өстәмә гарантияләр билгеләде.

Шул ук вакытта гамәлдә инвалидлыгы булган гражданның берничә ел дәвамында эшкә урнашырга мөмкинлекләре булмаган очраклар да булган, ә кабул ителә торган чаралар, Вәкаләтле вәкил фикеренчә, рәсми характерда булган.

Вәкаләтле вәкил адресына эшкә урнашу проблемасы белән III төркем инвалид мөрәҗәгать итте. Ул 2017 елдан Бөгелмә муниципаль районының халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә алга таба эшкә урнаштыру өчен исәптә торган, әмма мөрәҗәгать итү датасына граждан эшкә урнаштырылмаган. Шул ук вакытта безнең тарафтан гариза бирүченең вакантлы вазыйфаларга юнәлтелүе ачыкланды, алар юнәлеш бирелгән көнне фактта актуаль булмаганнар, бу мәшгульлек үзәге белгечләренең оешмаларның кадрлар хезмәтләре вәкилләреннән вакантлы вазыйфаның актуальлеген ачыкламаулары турында сөйли. Кайбер очракларда мөрәҗәгать итүченең кандидатурасы һөнәри сыйфатларга туры килмәү сәбәпле эш бирүче тарафыннан кире кагылган, кайбер очракларда мөрәҗәгать итүче үзе өйдән шактый еракта булу сәбәпле тәкъдим ителә торган вакансияләрдән баш тарткан.

Барлык шартларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына мөрәҗәгать итүчене эшкә урнаштыру буенча төгәл чаралар күрү турында тәкъдимнәр җибәрелде.

Күрсәтелгән шартларда сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән гражданнарны эшкә урнаштыруда ярдәм итүнең нәтиҗәлелеген яхшырту максатларында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының, аның белемнәрен, күнекмәләрен, шулай ук тормыш эшчәнлеген чикләүне исәпкә алып, һәр инвалид белән индивидуаль адреслы эш оештыруга игътибарын юнәлтергә кирәк дип исәплибез.

Моннан тыш, хезмәт базарын цифрлаштыру процессы кысасында читтән торып эшләү белән мәшгульлекнең яңа формалары һәм төрләре барлыкка килүен исәпкә алмыйча булмый, бу хезмәт базарында кыенлыклар кичерүче гражданнар, шул исәптән инвалидлар өчен аерым әһәмияткә ия, шулай ук эшкә урнаштыру өчен эш урыннары җитәрлек булмаган территорияләр өчен актуаль. Әйтик, «Демография» милли проекты кысасында маркетплейсларда (Wildberries, Ozon, Яндекс Маркет һ.б.) эш оештырырга һәм алып барырга мөмкинлек бирә торган программаларга түләүсез укыту юлы белән яңа һөнәр алырга мөмкин.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан «Демография» милли проекты кысасында «Маркетплейслар буенча белгеч» программасы буенча түләүсез белем алу мөмкинлеге турында сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән гражданнарга өстенлекле тәртиптә хәбәр итүләрен сорыйм.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән һәм инвалид балаларның ата-аналарын борчый торган иң мөһим мәсьәләләрнең берсе гражданнарның аерым категорияләренең ял итүгә хокукын гамәлгә ашыру. Инклюзив балалар ялы инвалидлыгы булган кешеләрне җәмгыятькә яраклаштыру буенча чаралар комплексының мөһим өлеше булып тора.

Инвалид балаларның ялы өчен республика лагерьларында аерым сменаларны оештыру мәсьәләсенең актуальлеге һәм ихтыяҗы турында узган елның июнь башында Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше хокукларын яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе вәкилләре белән берлектә үткәрелгән, балаларның җәйге ялын һәм сәламәтләнүен оештыру мәсьәләләренә багышланган «кайнар элемтә» мөрәҗәгатьләрнең шактый булуын дәлилләде. Ата-аналарны балаларны озатып йөрүче затлар белән дә, алардан башка да ялны оештыру, инвалид балаларның сәламәтлеген исәпкә алып, тиешле шартлар тудыру мәсьәләләре кызыксындырды.

Шунысы куанычлы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы мәгълүматлары буенча, Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов карары нигезендә, инвалид балалар өчен сәламәтләндерү сменалары уздыру өчен, 2022 елда ата-аналарын озатып йөрүен дә исәпкә алып, 4,1 млн сум күләмендә өстәмә финанс чаралары бүлеп бирелгән. Физик мөмкинлекләре чикле һәм инвалидлыгы булган балалар өчен ата-аналар озатуында сменалар «Заречье» лагеренда, «Мирас – Наследие» балалар лагеренда, А.Д. Губин исемендәге яшьләр сәламәтләндерү үзәгендә, «Восток» лагеренда оештырылган. Гомумән алганда, 2022 елда Татарстан лагерьларында физик мөмкинлекләре чикле һәм инвалид булган 487 бала ял иткән.

2.3. СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУГА ҺӘМ МЕДИЦИНА ЯРДӘМЕНӘ ХОКУК

Сәламәтлек – кешенең тартып алынмый торган иң зур байлыгы, ансыз башка күп кыйммәтләр әһәмиятен югалта. Россия Федерациясе Конституциясенең 41 маддәсе һәр гражданга сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәме күрсәтүгә хокукны беркетә. Бу хокук дәүләтнең кешеләрнең сәламәтлеген саклау бурычы белән туры килә. Шуңа күрә сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп бурычы – сәламәтлек саклауның мондый системасын формалаштыру, аның кысасында һәр кеше медицина ярдәменә конституцион хокукларын гамәлгә ашыра ала.

Сәламәтлек саклау һәм медицина ярдәме хокукларын саклауда халык өчен сәламәтлек саклау инфраструктурасы объектларының үтемлелеген арттыру мөһим. Әлеге максатларда 2022 елда Татарстан Республикасының 142 сәламәтлек саклау объектында төзелеш һәм капиталь ремонт эшләре башкарылган, шул исәптән 61 объект төзелгән, 81 медицина оешмасының бинасы капиталь ремонтланган.

2022 елда Вәкаләтле вәкил төрле формаларда гражданнарга сәламәтлек саклау һәм медицина ярдәменә хокукларын тормышка ашыруда ярдәм итү буенча эшчәнлек алып барды. Беренче чиратта, әлеге юнәлеш буенча Вәкаләтле вәкилнең хокук яклау практикасы гражданнарның мөрәҗәгатьләрен караудан һәм массакүләм мәгълүмат чараларында басылган мәгълүматны анализлаудан чыгып оештырылды.

Вәкаләтле вәкил эшчәнлегендә «Инцидент Менеджмент» реаль вакыт режимында социаль челтәрләрне мониторинглау системасы аша алынган мәгълүматны куллану республика халкының проблемалы мәсьәләләрен оператив рәвештә ачыкларга һәм аларны хәл итү буенча чаралар күрергә мөмкинлек бирде. Узган ел медицина ярдәменә хокукларны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча әлеге системага 1810 хәбәр килгән.

Гражданнарның шикаятьләрен караудан тыш, Вәкаләтле вәкил «Сәламәтлек саклау» юнәлешен үз эченә алган «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасының баш модераторы функциясен башкара.

Сәламәтлек саклау мәсьәләләре буенча мәгълүмат системасына безнең республика халкыннан 2471 хәбәр килгән (шул исәптән «Дәүләт хезмәтләре. Бергәләп хәл итәбез») «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре (функцияләре) бердәм порталы» хәбәрләрен исәпкә алып, 522 кулланучының хуплавы бу мөрәҗәгатьләрнең татарстанлылар өчен актуаль булуын күрсәтә.

Әлеге юнәлеш буенча мөрәҗәгатьләрне анализлау, тулаем республика буенча 2022 елда электрон һәм башка төрдә табибка язылу мөмкинлеге өлешендә системалы проблемалар саклануын күрсәтте.

«Сәламәтлек саклау» юнәлеше буенча гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау әлеге теманың татарстанлылар өчен актуаль булуын күрсәтә.

Сәламәтлек саклау мәсьәләләре буенча мәгълүмат системасына республикабыз халкыннан 2471 мөрәҗәгать килгән, аларны 522 кулланучы хуплаган.

Тулаем республика буенча 2022 елда табибка электрон һәм башка төрдәге язылу мөмкинлеге өлешендә системалы проблемалар сакланды.

Әлеге төр мәсьәләләр буенча «Халык контроле» системасына 2022 елда гражданнардан 639 мөрәҗәгать килгән. Гражданнар медицина ярдәме алу өчен электрон язылу чиратын озак көтүдән зарлана, бу нигездә, республиканың эре шәһәрләрендә күзәтелә.

Казан шәһәре буенча табибка язылып булмау турында иң күп мөрәҗәгатьләр – 168 («7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «8 нче шәһәр сырхауханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «18 нче шәһәр сырхауханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «20 нче шәһәр сырхауханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «7 нче балалар шәһәр сырхауханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе) һәм Чаллы шәһәре буенча – 39 («6 нчы шәһәр сырхауханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «1 нче номерлы балалар стоматология сырхауханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе), Әлмәт муниципаль районы буенча – 13 («Әлмәт үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе); Алабуга муниципаль районы буенча – 10 («Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе), Түбән Кама муниципаль районы буенча – 18 («НЦРМБ» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе).

Узган ел «Халык контроле» системасында мөрәҗәгатьләрне мониторинглау ярдәмендә Әлмәт шәһәрендә яшәүчеләрдән «Алсу» микрорайонында табиб кабинетын ачу зарурлыгы мәсьәләсе буенча күпсанлы мөрәҗәгатьләр килүе ачыкланды, бу исә гражданнарның әлеге проблема белән чынлап та борчылуларын күрсәтте. Әлеге проблема Вәкаләтле вәкил тарафыннан профильле министрлыклар һәм ведомстволар вәкилләре белән оештырылган эш киңәшмәләрендә карау предметы булды. Әлеге мәсьәләне хәл итү буенча тулы чаралар күрү турында йөкләмә бирелде. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына бирелгән йөкләмәне карау йомгаклары буенча Татарстан Республикасы сәламәтлек саклауның башлангыч звеносын модернизацияләүнең төбәк программасы кысасында «Әлмәт үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең «Алсу» микрорайонындагы педиатрия бүлеге белән гомуми практика табибы офисын төзүгә акча бүлеп бирелде. (Адресы: Әлмәт шәһәре, Октябрьнең 70 еллыгы урамы).

Медицина ярдәменең үтемлелеген һәм сыйфатын арттыру – халык сәламәтлеген саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтенең иң мөһим максатларының берсе. Бары тик медицина ярдәме сыйфатын идарә итүнең нәтиҗәле системасын булдыру нигезендә генә уңай нәтиҗәләргә ирешеп була.

Күрсәтелгән хезмәтләрнең сыйфатын бәяләүнең нәтиҗәле инструментларыннан берсе булып Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында «Халыкка хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләү» сервисының эшләве тора. Гражданнар үзләрен борчыган мәсьәләләрне 5 баллы шкала буенча бәяләп мөстәкыйль рәвештә билгели алалар, бу республиканың сәламәтлек саклау учреждениеләре җитәкчеләренә конкрет чаралар күрү кирәклеген күрсәтүче җитди индикатор булып тора.

Вәкаләтле вәкил ел дәвамында «Халык контроле» системасына «Сәламәтлек саклау» юнәлеше буенча «Халыкка хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләү» сервисында уртачадан түбән бәя алган иң күп гаризаларны анализлап, республиканың медицина учреждениеләре арасында охшашлыклар күзәтелүен дә ачыклады.

«Табибка язылу» төре буенча сыйфатны бәяләү системасыннан Татарстан халкы 605 мең тапкыр файдаланган (уртача бәя – 4,5). Мониторинг күрсәткәнчә, респондентларның күпчелеге чиратта озак көткәннән канәгать булмаган 61070 мең бәяләү, бу гомуми санның 10 процентын тәшкил итте.

Әлеге критерий буенча уртача бәядән түбәнрәк бәягә Казан шәһәре буенча түбәндәге сәламәтлек саклау учреждениеләре – «18 нче шәһәр сырхауханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «20 нче шәһәр сырхауханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «2 нче клиник хастаханә» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «16 нчы шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «21 нче шәһәр сырхауханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «11 нче шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «8 нче шәһәр сырхауханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «ДКБ №12» АҖ; Чаллы шәһәре буенча: «Л.Н. Ганиев исемендәге 4 нче шәһәр сырхауханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе; Алабуга муниципаль районы буенча – «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе; Питрәч муниципаль районы буенча – «Питрәч үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе; Биектау муниципаль районы буенча – «Биектау үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе; Бөгелмә муниципаль районы буенча – «Бөгелмә үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе; Әлмәт муниципаль районы буенча «Әлмәт ШП №3» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе билгеләнде.

Хезмәтләрне бәяләү күрсәткечләренең кимүе «Табибның мөнәсәбәте» критерие буенча да күзәтелгән, ул 48 меңнән артык бәяләүне тәшкил иткән, бу гомуми санның 8 процентын тәшкил иткән. Әлеге критерий буенча (уртачадан түбәнрәк) бәяләр гражданнар тарафыннан Казан шәһәре буенча медицина хезмәтләрен алганда түбәндәге учреждениеләрдә билгеләнде: «21 нче шәһәр сырхауханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «18 нче шәһәр сырхауханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «16 нчы шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «20 нче шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «2 нче клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, Казан шәһәренең «8 нче шәһәр сырхауханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «11 нче хастаханә» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе; Чаллы шәһәрендә: «Л.Н. Ганиев исемендәге 4 нче шәһәр сырхауханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «5 нче шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «7 нче шәһәр сырхауханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, шулай ук Әлмәт, Алабуга, Бөгелмә, Биектау, Питрәч муниципаль районнарында («Бөгелмә үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Әлмәт ШП №3» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Биектау үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе, «Питрәч үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе).

Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре тарафыннан квартал саен күрсәтелгән күрсәткечне киметүгә йогынты ясый торган факторларга анализ үткәрелде, аның нәтиҗәләре һәм әлеге юнәлеш буенча эшне камилләштерү турында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының һәм медицина оешмаларының җаваплы затлары катнашында оештырылган киңәшмәләрдә сөйләштек.

Узган елның декабрендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә уздырылган «Сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүнең практик аспектлары» дигән темага белем бирү семинары гражданнарның җаваплы башкаручыларның җавапларыннан канәгать булуы һәм мөрәҗәгатьләрне үз вакытында карау мәсьәләләренә багышланды. Чарада гражданнарның «Халык контроле» системасы һәм кире элемтә платформасы аша керүче хәбәрләре җентекләп тикшерелде һәм аларны караган вакытта җибәрелә торган хаталарга анализ ясалды. Шундый ук чара 2023 елга да планлаштырылган.

Медицина учреждениеләре мәгълүматларына караганда, кайбер учреждениеләрдә табибларга язылу булмау мәсьәләләре буенча шикаятьләр саны артуның бер сәбәбе – белгечләр җитмәү.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2022 елның 1 гыйнварына медицина оешмаларының табибларга ихтыяҗы 1345 кеше тәшкил иткән, уртача алганда, медицина персоналына ихтыяҗ – 858.

Бөтенроссия пациентлар берлеге тикшеренүләреннән күренгәнчә, югары уку йортын тәмамлаганнан соң беренче елда яшь табибларның 10–11 проценты дәүләт медицинасыннан китә, икенчесендә – 10%, өченче елда – тагын 8–10%. Ягъни чыгарылыштан соң өч ел эчендә сәламәтлек саклау системасы барлык чыгарылыш белгечләренең өчтән берен югалта.

Кадрлар кытлыгын бетерү максатыннан республикада «Сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларын квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү» төбәк проекты тормышка ашырыла. Аны гамәлгә ашыру кысасында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан максатчан кабул итү квоталары буенча югары белем бирү оешмаларында (специалитет программалары буенча 464 юллама һәм ординатура программалары буенча 292 юллама бирелгән), Казан дәүләт медицина университетында табибларны адреслы әзерләү программасы, шулай ук ординатура программалары буенча республиканың максатчан акчалары исәбеннән укытуга юнәлдерелгән эш оештырылды.

Социаль ярдәм чаралары сыйфатында республикада бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләре («Земство табибы», «Земство фельдшеры» программасы), Татарстан Республикасы хөкүмәте грантларын бирү программасы, «Социаль ипотека» программасы буенча медицина хезмәткәрләренә торак бирү программасы тормышка ашырыла. «Табиблар – яшь белгечләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2012 елның 9 июнендәге 501 нче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, сәламәтлек саклау дәүләт автоном (бюджет) учреждениеләренә эшкә кабул ителгән табиб-яшь белгечләргә өстәмә акча билгеләү каралган.

Шул ук вакытта, бу юнәлештә планлы эшкә карамастан, Вәкаләтле вәкил фикеренчә, нәкъ менә сәламәтлек саклау системасында кадрлар проблемалары булу халыкка медицина ярдәменең үтемлелеген һәм сыйфатын киметә.

Шуңа бәйле рәвештә, кадрлар кытлыгын хәл итү максатларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 31 декабрендәге 2568 номерлы «Сәламәтлек саклауның дәүләт һәм муниципаль системасына керүче һәм мәҗбүри медицина иминиятенең база программасында йә мәҗбүри медицина иминиятенең территориаль программаларында катнашучы медицина оешмаларының медицина хезмәткәрләренә өстәмә дәүләт социаль ярдәме турында»гы карары кече персонал өчен 4500 сумнан алып, үзәк район, район һәм участок хастаханәләре табиблары өчен 18 мең сумга кадәр махсус социаль түләүләрне күздә тота торган карары халыкка медицина ярдәме күрсәтү мөмкинлеген арттырырга һәм, үз чиратында, медицина хезмәткәрләре җилкәсенә төшкән авырлыкны киметергә мөмкинлек бирәчәк.

Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләрен анализлау медицина оешмаларында вакантлы урыннарда булган табибларның кытлыгы турында гына түгел, ә медицина оешмаларында тар белгечләрнең штат саны җитмәвен дә күрсәтте.

Әйтик, «Бөтенроссия саңгыраулар җәмгыяте» Бөтенроссия инвалидлар иҗтимагый оешмасының Татарстан Республика бүлеге әгъзасы шикаяте буенча тикшерү барышында ачыкланганча, 2021 елның ноябреннән 2022 елның мартына кадәр Казан шәһәрендә яшәүче инвалид «Республика клиник хастаханәсе» сәламәтлек саклау учреждениесенең табиб-сурдологына индивидуаль реабилитация һәм абилитация программасын рәсмиләштерү өчен кирәкле аудиограмма үткәрү өчен керә алмаган.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматы буенча Татарстан Республикасында табиб-сурдологлар тарафыннан халыкны кабул итү «Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә оештырылган, анда сурдология бүлеге бар, шулай ук Чаллы шәһәренең «Ишетүне реабилитацияләү үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә, «16 нчы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә, «12 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә, «Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 2 нче номерлы консультатив сырхауханәнең сурдология бүлегендә оештырылган. 2022 елның 1 гыйнварына штаттагы табиб-сурдологларның саны – 10, шуларның тугызы эшли.

Шул ук вакытта «Бөтенроссия саңгыраулар җәмгыяте» Бөтенроссия инвалидлар иҗтимагый оешмасының Татарстан бүлеге рәисе мәгълүматларына караганда, безнең республика башкаласында ишетү сәләте начар булган

3000нән артык кеше яши, һәм алар барысы да табиб-сурдолог тарафыннан системалы күзәтүгә мохтаҗ.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2022 ел дәвамында «Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесендә табиб сурдолог-оториноларингологның штат саны бер берәмлеккә арттырылган.

Шуңа бәйле рәвештә, Вәкаләтле вәкил фикеренчә, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан медицина оешмаларында профильле табиб-белгечләрнең штат саны халыкның ихтыяҗларын никадәр каплый, бу контрольдә булырга тиеш, чөнки аларның булмавы гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә көтү срокларын арттыруга нигез була алмый.

Әлбәттә, сыйфатлы медицина ярдәмен дарулар белән тәэмин итүдән башка оештыру мөмкин түгел.

2021 елдагы кебек үк, ташламага ия гражданнарга дару препаратларын вакытында бирү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатьләр дә үзенә игътибарны җәлеп итте.

Без әлеге мәсьәлә буенча республика халкының «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль кире элемтә платформасына кергән мөрәҗәгатьләре санының артуын билгеләп үттек.

2022 елда әлеге тематика буенча хәбәрләр 2021 ел белән чагыштырганда 70 процентка күбрәк килгән һәм 124 (2021 – 73) тәшкил иткән. Бер яктан, арту логистик тәэмин итү чылбыры бозылу сәбәпле, Россия Федерациясенә берничә төрле медицина препаратын китерүне тоткарлауга бәйле, икенче яктан – финанслау җитәрлек булмау белән.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2022 елга республиканың ташламалы дару препаратларына еллык ихтыяҗы 4921104,0 мең сум тәшкил иткән. Татарстан Республикасында ташламага ия затларны дару препаратлары белән тәэмин итү проценты фаразланган күрсәткечләр буенча 2022 елда якынча 70% тәшкил итте.

Әйтергә кирәк, 2021 елдан федераль ташламаларга ия булучылар өчен бик кирәкле һәм яшәү өчен әһәмиятле дару препаратлары исемлеген (406 атамадан 788гә кадәр) киңәйтүгә карамастан, финанслау элеккеге дәрәҗәдә калды. Шул ук вакытта 2022 елга гражданнарның ташламалы категорияләрен дару препаратлары белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан бүлеп бирелгән финанс чаралары күләме 1921104,2 мең сум тәшкил итте, республика бюджетыннан – 1321813,41 мең сум.

Үз чиратында Татарстан Республикасының 2022 елга ташламалы дару препаратларына еллык ихтыяҗы 4921104,0 мең сум тәшкил итте. Татарстан Республикасында ташламага ия затларны дару препаратлары белән тәэмин итү проценты фаразланган күрсәткечләр буенча 2022 ел нәтиҗәләре буенча якынча 70% тәшкил итте.

Дару препаратлары белән тәэмин ителмәү яки тиешенчә тәэмин ителмәү турында мәгълүмат булган мөрәҗәгатьләр Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җибәрелде, аларны карау барышы мөрәҗәгать иткән гражданны кирәкле дару препаратлары белән тәэмин итү турында мәгълүмат алганчы контрольгә алынды.

Әйтик, гепатолентикуляр регенерация (Вильсон авыруы) авыруы булган гражданка М.ның «Купренил» даруын даими кабул итүгә мохтаҗ булуы турындагы мөрәҗәгате уңай хәл итүнең бер мисалы булып тора. Шул ук вакытта ул 2021 елның апреленнән 2022 елның мартына кадәр 33 урынына нибары ике пакет дару препараты белән тәэмин ителде. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән тыгыз хезмәттәшлек нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүче дару препаратлары белән тулысынча тәэмин ителде.

Гражданнарның ташламалы категориясен дару препаратлары белән тәэмин итүне мониторинглау безнең тарафтан, шул исәптән «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы аша да башкарылды. Кирәкле препаратлар белән үз вакытында яки тулысынча тәэмин ителмәү очракларында без мөрәҗәгатьләрне яңадан карарга кайтардык.

Әйтик, «Халык контроле» системасына Балык Бистәсе районында яшәүче гражданка Г.дан улын кандагы шикәрен үлчәү өчен тест-полоскалар белән тәэмин итмәү мәсьәләсе буенча хәбәр алынды.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы 9 төргәк тест-полосканы (айга 3әр төргәк) даруханәгә мөрәҗәгать итүчегә бирү өчен җибәрү турында җавап җибәрде һәм хәбәргә «Мөрәҗәгать хәл ителде» статусы бирде. Без бу мөрәҗәгатьне эшкә кайтардык, чөнки фактта хәбәр юллаучыга бары бер әлеге генә бирелде. Аннан соң җавапны башкаручылар тарафыннан мәгълүмат системасында мөрәҗәгать итүчене тест-полоскалар белән тәэмин итү турында мәгълүмат бирелде.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның төбәкнең ташламага ия кешеләрен тормышта кирәкле һәм мөһим дару препаратлары белән тәэмин итү өчен төбәк исемлеген киңәйтүгә, шулай ук инвалид балаларны дару препаратлары, медицина эшләнмәләре белән тәэмин итү өчен федераль вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга 2023 елга республика бюджетыннан өстәмә акча бүлеп бирү турындагы карары әлеге проблемалы мәсьәләне уңай хәл итәргә мөмкинлек бирер дип ышанабыз.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына һәр муниципаль берәмлектә төбәкнең ташламага ия кешеләрен, инвалид балаларны кирәкле препаратлар белән тәэмин итү ихтыяҗын билгеләү буенча эшне оештырырга кирәк.

Агымдагы елда Вәкаләтле вәкил гражданнарга сәламәтлек саклауга һәм һәркемгә үтемле, сыйфатлы медицина ярдәме алуга хокукларын гамәлгә ашыруда ярдәм итүне дәвам итачәк.

2.4. БЕЛЕМ АЛУГА ХОКУК

Белем алу хокукы – кешенең төп һәм нигезле хокукларының берсе. Бер яктан, белем аны алучы кеше өчен кыйммәтле, икенче яктан, белемнең әһәмияте һәм сыйфаты иҗтимагый әһәмияткә ия, шуңа күрә белем алу хокукы кеше хокуклары системасында төп социаль категорияләрнең берсе булып тора һәм дәүләтнең катнашлыгын, аны тормышка ашыру өчен кирәкле шартлар тудырмыйча гына тормышка ашырыла алмый.

2022 елда Буа, Биектау, Түбән Кама, Тукай районнарында 705 урынга исәпләнгән 4 балалар бакчасы, Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама, Яшел Үзән шәһәрләрендә, Биектау, Саба, Кукмара, Мамадыш муниципаль районнарында гомуми күтә 7458 урынга исәпләнгән 10 мәктәп төзелде һәм кулланышка тапшырылды. 74 мәгариф оешмасында капиталь ремонт үткәрелде, мәктәпләрдәге фән кабинетларының 80,0 проценты интерактив һәм проекцион техника белән җиһазландырылды. Энтәлек үсеше белән бергә, укытучылар өчен лаеклы хезмәт шартларын булдыруга зур игътибар бирелә.

Күрелгән чараларга карамастан, балаларның белем алуга хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр актуаль булып кала.

2022 елда Вәкаләтле вәкил адресына мәгариф өлкәсендә хокукларны яклау мәсьәләләре буенча 224 мөрәҗәгать керде. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты һәм мәгариф идарәсенең муниципаль органнары белгечләрен җәлеп итеп, балаларның белем алуга хокукларын бозу турындагы мәгълүмат буенча һәр мөрәҗәгать каралды.

Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен мониторинглау, шулай ук үз дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм массакүләм мәгълүмат чараларында басылган материаллардан алынган мәгълүматны анализлау мәгариф өлкәсендә балаларның мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә кабул итүгә, балаларны мәгариф оешмаларына алып килүгә, белем бирү процессында катнашучылар арасында низаглы хәлләргә, белем бирү оешмаларында физик мөмкинлекләре чикләнгән балаларны укыту һәм тәрбияләү, укучыларның имин белем тәэмин итү өчен шартлар тудыруга бәйле проблемаларны ачыкларга, аларның әйбәрен, алга таба тәкъдимнәр кертергә мөмкинлек бирде.

Гадәттәгечә, белем бирү процессында катнашучылар белән актив хезмәттәшлек итү һәм мәгариф турындагы закон таләпләрен бозу фактларына оператив җавап бирү максатыннан, уку елы башында Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Мәрхәмәт–Милосердие» хатын- кыз депутатлар берләшмәсе белән берлектә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы прокуратурасы вәкилләрен чакырып, «кайнар элемтә» үткәрде, анда 84 шалтырату кабул ителде. Аның йомгаклары буенча, укучыларның дәреслекләр белән тәэмин итү, мәктәпләрдә су эчү режимын оештыру, бер учреждениедән икенчесенә күчерү, балаларга өстәмә белем бирүне оештыру, белем бирү процессын оештыру һәм башка мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең 22 мөрәҗәгате уңай чишелеш тапты, 28 гариза бирүчегә консультатив ярдәм күрсәтелде һәм 34 мөрәҗәгать итүченең үтенече алга таба шәхси оештыру өчен компетентлы органнарга җибәрелде.

Мөрәҗәгатьләрне анализлау шулай ук мәктәпкәчә белем бирүне тәэмин итүгә бәйле актуаль мәсьәләләрнең дәвам итүен күрсәтә.

Вәкаләтле вәкил фикеренчә, әлеге проблеманы бетерүгә комачаулый торган нигезләрнең берсе – балалар бакчаларыннан да урыннар белән тәэмин итүгә бәйле ихтыяҗларны исәпкә алмыйча торак кварталлар төзү. Аларның ихтыяҗларын планлаштыру һәм фаразлау булмау конкрет гаилә проблемаларына китерә.

Шикаятьләрне мониторинглау территориядә урыннар белән тәэмин итү проблемасының Питрәч муниципаль районының Яңа Шигали һәм Көек авылларында яшәүчеләр өчен кискен торуын күрсәтә. Яши торган җир янында балалар бакчаларында урыннар булмаганда, Питрәч муниципаль районы мәгариф идарәсе тарафыннан ни кына районның башка торак пунктларында урыннар тәкъдим ителә, бу Россия Федерациясе Конституция судының белем бирү учреждениеләренең якынлыгы турындагы позициясенә каршы килә.

Мәсәлән, «Усадьба Царево» торак комплексында яшәүче гражданка З.га өч яшьлек улын «Колокольчик» Колай балалар бакчасына яки Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Родничок» Ленино-Кокушкино балалар бакчасына күчерергә тәкъдим ителгән. Шул ук вакытта әлеге балалар бакчалары мөрәҗәгать итүченең яшәү урыныннан 26 км һәм 19 км ераклыкта урнашкан. Вәкаләтле вәкил Питрәч муниципаль районының мәгариф бүлеге начальнигы адресына мөрәҗәгать итте.

Бер үк вакытта социаль инфраструктура объектларын файдалануга кертмичә күп фатирлы йортларны файдалануга тапшыруның аерым фактлары исәпкә алып, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урыннар белән тәэмин итү буенча киеренкелекне, аларны торак йортларның беренче катларында урнаштыру кимәтер иде, дип саныйбыз.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитет җитәкчеләре белән берлектә проблемаларны хәл итү юлы буларак, торак йортларның беренче катларында мәктәпкәчә белем бирү оешмаларын ачу мөмкинлеген карарга тәкъдим итәбез.

Әлеге мәсьәләне хәл итү варианты инде файдалануга тапшырылган проектларга карата актуаль. Социаль инфраструктураны исәпкә алып, территорияләрне комплекслы үстерү, һичшиксез, яңа торак кварталларын проектлауда һәм төзүдә мөһим һәм нәтиҗәле механизм булып тора.

Шуңа бәйле рәвештә «ТР тирәлекне планлаштыру институты» җитәкчелегенә игътибарын территорияләрне төзүне җайга салу һәм агломерация планнарын формалаштыру вәкаләтләрен тормышка ашырганда, беренче чиратта, мәктәпкәчә белем бирү объектларын кертүне исәпкә алырга кирәклегенә юнәлтәбез.

Мәктәпкәчә белем бирү өлкәсендә тагын бер актуаль проблема булып бертуганнары өлкән апа-абыйлары йөргән мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына кабул итү хокукын гамәлгә ашыру тора.

Әйтик, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына кабул итү кампаниясе чорында, Вәкаләтле вәкил адресына Әлмәт муниципаль районының ата-аналарыннан, бертуганнары балалар бакчаларына кабул итүдән баш тарту турында мөрәҗәгатьләр килде. Әлмәт муниципаль районы мәгариф идарәсе мәгълүматларына караганда, әлеге бала йөри торган шул ук бакчада баланы кабул итү өчен буш урыннар булмаган. Шуңа бәйле рәвештә гариза бирүчеләргә кече балаларга башка мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына җибәрелгән.

Балаларны төрле мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә урнаштыру, балалар өчен дә, аларның ата-аналары өчен дә уңайсызлыклар тудыра һәм шуңа бәйле рәвештә гаиләне ныгытуга, республиканың демографик проблемалы чишүнең уңай шартларын булдыруга ярдәм итә алмый.

Россия Федерациясе Президентының 09.10.2007 ел, 1351 нче указы белән расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе демографик сәясәте концепциясе нигезендә, Россия Федерациясе демографик сәясәтенең төп бурычлары – икенче бала һәм аннан соңгы балалар туу хисабына гаиләләрдә балалар туу дәрәҗәсен күтәрү, гаилә институтын ныгыту.

Әлеге бурычларны хәл итү балалары булган гаиләләргә дәүләт ярдәмен көчәйтүне һәм аларның ихтыяҗларын тәэмин итүне таләп итә. Билгеләнгән мәсьәләләрне хәл итү максатыннан, Вәкаләтле вәкил Әлмәт муниципаль районы башлыгы адресына мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә урнаштыруның иң компромисс вариантларын эзләүдә һәр конкрет балага карата адреслы эш үткәрү үтенече белән мөрәҗәгать итте.

Әлеге проблема Татарстан Республикасының башка муниципаль берәмлекләре мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә дә булырга мөмкин.

Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында кадрлар кытлыгы проблемасы елдан-ел саклана. Бер яктан, педагогик кадрлар җитмәү балаларның сыйфатлы белем алуга, икенче яктан, аларны балалар бакчаларында урыннар белән тәэмин итүдә хокукларын бозуга китерә. 2021 елда Вәкаләтле вәкил тарафыннан, Лаеш муниципаль районы Усад авылында яңа төзелгән балалар бакчасында педагогик кадрлар һәм техник персонал җитмәү сәбәпле, сабыйларга урын бирүдән баш тарту факты ачыкланды.

2022 елда шундый ук хәл Биектау муниципаль районының катнаш төрдәге «Шаян» Биектау балалар бакчасында барлыкка килде, ул 2021 елда файдалануга тапшырылган иде.

Массакүләм мәгълүмат чараларында, 220 балага исәпләнгән әлеге балалар бакчасында 6 тәрбияче генә эшли, дигән материаллар басылып чыкты.

Әлеге мәсьәләнең әһәмиятен исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил Биектау муниципаль районы башлыгы адресына мәктәпкәчә белем бирү оешмасын педагогик кадрлар белән тәэмин итү буенча тулы чаралар күрү кирәклеге турында тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итте. Шуның белән бергә, район күргән чараларга карамастан, әлеге мәсьәләнең актуальлеге хәзерге вакытта да сакланып калуын билгеләп үтәбез. 2022 елның 27 декабренә булган мәгълүматка караганда, Биектау муниципаль районының «Шаян» Биектау балалар бакчасында 3 вакантлы урын бар иде.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2022 елның 20 декабренә республика буенча муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында 1955 вакантлы педагогик вазыйфа бар.

2021 елгы докладта Вәкаләтле вәкил муниципаль берәмлекләр җитәкчеләренә мәктәпкәчә белем бирү оешмаларын педагогик кадрлар белән тәэмин итү буенча чаралар күрү кирәклеге турында мөрәҗәгать итте. Муниципаль берәмлекләр тарафыннан күрелгән чараларның педагогик кадрлар кытлыгын бетерү өчен җитәрлек булмавын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына педагогик кадрлар кытлыгын бетерү буенча республика муниципаль берәмлекләре тарафыннан кабул ителгән чараларның нәтиҗәлелеген анализларга тәкъдим итәргә кирәк, дип саныйбыз.

Ел саен республиканың югары һәм урта һөнәри белем бирү оешмалары «мәгариф һәм педагогика фәннәре» юнәлеше буенча 800дән артык яшь педагог укытып чыгара (бюджет урыннарыннан), бары 75 проценты гына белем бирү оешмаларына эшкә килә.

Вәкаләтле вәкил фикеренчә, төп сәбәп хезмәткә түләү дәрәҗәсе һәм социаль гарантияләр белән бәйле мотивация булмау гына түгел, ә югары уку йортларын тәмамлаучыларның белем бирү оешмаларында эшләргә теләмәве дә булырга мөмкин. Педагогик эшчәнлеккә әзерлек – абитуриентларның булачак һөнәри педагогик эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге өчен кирәкле шарт.

Шуңа бәйле рәвештә, «мәгариф һәм педагогика фәннәре» юнәлеше буенча югары белем бирү программалары буенча укырга кабул иткәндә, гомуми шәхси культура дәрәҗәсен, һөнәри мотивацияне һәм абитуриентның педагогик юнәлештәге белем бирү программасын үзләштерергә әзерлеген билгеләү өчен, бу юнәлешкә керү мотивларын, гомуми мәдәниятне, эрудицияне, педагогика һәм психология белән кызыксыну, балалар белән эшләргә әзер булуны билгеләргә ярдәм итүче әңгәмә формасында өстәмә укырга керү сынавын билгеләргә кирәк, дип саныйбыз.

Узган ел гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алу хокукын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнарның кайбер мөрәҗәгатьләренә Вәкаләтле вәкил аерым игътибар бирде.

Әйтик, Вәкаләтле вәкил адресына гаиләсе белән Казанга Самара өлкәсеннән күчеп килгән гражданка А.дан мөрәҗәгать килде. Баланы мәктәпкә урнаштыру максатыннан, гариза бирүче якындагы белем бирү оешмаларына мөрәҗәгать итә, әмма барлык мәктәпләрдә баланы кабул итүдән баш тарталар. Шундый ук гариза белән ул район мәгариф бүлегенә мөрәҗәгать итә, анда баланы урнаштыру буенча тиешле тәкъдимнәр әйтелми. Бу вакыт эчендә бала белем алмыйча өйдә утырырга мәҗбүр була.

Бала хокукларын яклап, Вәкаләтле вәкил Казан шәһәре мәгариф идарәсе башлыгына мөрәҗәгать итте. Безнең катнашудан соң, Казан шәһәренең мәгариф идарәсе белән үзара хезмәттәшлек нигезендә, бала өй янындагы мәктәпкә кабул ителде.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар һәм инвалид балалар гомуми белем бирү мәктәпләренә кабул итүдә кыенлыклар белән очрашуны дәвам итәләр.

Әйтик, узган елның сентябрендә Биектау районында яшәүче балаларның ата-аналарыннан Вәкаләтле вәкил адресына балаларны яшәү урыны буенча мәктәпләргә урнаштыру мөмкинлеге булмау турында мөрәҗәгать керде.

Вәкаләтле вәкил район җитәкчелеге адресына балаларны яшәү урыны буенча укытуны оештыру үтенече белән мөрәҗәгать итте. Алынган җаваптан күренгәнчә, кабул итүдән баш тартуның төп сәбәбе – район мәктәпләрендә инвалид балаларны укыту өчен махсус шартлар булмау.

Шуның белән бергә, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендә дөнья күргән 273-ФЗ нче федераль закон нигезендә, сәламәтлеге чикле балаларны укыту өчен махсус шартлар тудыру белем бирү оешмаларының бурычы булып тора, Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә, сәламәтлеге чикле һәм инвалид балаларның хокукларын чикләүгә юл куймас өчен, өстәмә чаралар күрергә тәкъдим ителде.

Вәкаләтле вәкил гражданка Д.ның мөрәҗәгате буенча да үз позициясен белдерде, яшәү урыны буенча теркәлмәү сәбәпле, аның сәламәтлеге чикле баласын Казан шәһәре Киров районының сәламәтлеге чикле балаларны укыту өчен база мәктәбе булган 188 нче күппрофильле лицеенда кабул итүдән баш тартканнар.

Әлеге мөрәҗәгатьне объектив һәм һәрьяклап карау максатында күчмә тикшерү оештыру турында карар кабул ителде, аның барышында 2022 елның 1 июлендә белем бирү учреждениесендә беркетелгән территориядә яшәмәүче балаларның ата-аналарыннан гаризалар кабул итү башлануы ачыкланды. Шуның белән бергә 188 нче лицей администрациясе мәгълүмат стендында да, рәсми сайтта да беренче сыйныфка алу турында гаризалар кабул итүнең икенче этабы башлану датасы турында мәгълүмат урнаштырмаган.

Өстәвенә мөрәҗәгать итүче, 2022 елның 30 июнендә улын ресурс сыйныфына алуны сорап, шәхсән мәктәп директорына мөрәҗәгать иткән. Ләкин гаризалар кабул итүнең икенче этабы башлану турында мәктәп җитәкчелеге хәбәр итмәгән. Мәгълүмат булмагач, мөрәҗәгать итүче мәктәптә гаризалар кабул итүнең икенче этабының беренче көнендә гариза бирүдән мәхрүм калган, ә мөрәҗәгать итүче билгеләнгән срокта – 2022 елның 6 июлендә мөрәҗәгать иткәндә, буш урыннар булмавын сәбәп итеп, кабул итүдән баш тартканнар. Вәкаләтле вәкил катнашканнан соң бала әлеге мәктәпкә алынды.

Мөрәҗәгатьләрнең әлеге категориясенең аеруча әһәмиятле булуын исәпкә алып, октябрьнең беренче декадасында Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты һәм «Үзәк психология-медик-педагогик комиссия» ДБУ белән бергә мәгариф оешмалары тарафыннан мәгариф өлкәсендә законнарда билгеләнгән таләпләрнең, сәламәтлеге чикләнгән һәм инвалид балаларны укыту һәм тәрбияләүне оештыру өлешендә үтәлүенә мониторинг оештырды.

Мониторинг кысасында комиссия әгъзалары республиканың эре шәһәрләрендә – Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәттә урнашкан 11 мәктәптә булдылар.

Мониторинг барышында бер мәктәпкә хас булган төгәл проблемалар да, системалы проблемалар да ачыкланды: бу – белем бирү оешмаларын квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү, тьютор ярдәмен оештыру, мәктәпләрдә психологик-педагогик консилиумнар эшләтү, сәламәтлеге чикле балалар укый торган гомуми белем бирү оешмаларын финанслау, белем бирү программасын үзләштерүдә сәламәтлеге чикле балалар белән белем алучы укучыларның уңышлылыгын бәяләү, ата-аналар белән эшләүне оештыру, белем бирү оешмаларын тар белгечләр белән тәэмин итү, инклюзив классларны тулыландыру һәм башкалар.

Мониторинг нәтиҗәләре, шулай ук проблемалар һәм аларны чишү юллары турында 2022 елның декабрь башында, без оештырган «түгәрәк өстәл» кысасында, Россия Федерациясе Дәүләт Думасы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының мәгариф һәм фән комиссиясе әгъзалары, Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы вәкилләре, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләре, мәгариф идарәсенең муниципаль органнары җитәкчеләре, гомуми белем бирү мәктәпләре директорлары, шулай ук иҗтимагый оешмалар вәкилләре чакырылган иде.

Әлбәттә, сенсор бүлмәсенең (психологик бушану бүлмәсе) гомуми белем бирү оешмаларында эшләве сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар үсешенә комплекслы якын килүне тормышка ашыруда һәм федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә ашыруда мөһим элемент булып тора. Шул ук вакытта гомуми белем бирү оешмалары сәламәтлекләре чикле балаларны сыйфатлы укыту һәм аларга коррекцион ярдәм күрсәтү өчен кирәкле җиһазлар белән тулысынча комплектланмаган.

Белем бирү оешмаларының финанс мөмкинлекләрен исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы җитәкчелеге адресына, төп белем бирү оешмаларын сәламәтлекләре чикле балаларны укыту һәм тәрбияләү өчен кирәкле җиһазлар белән тәэмин итү максатында республика бюджетыннан өстәмә акча бүлеп бирү мәсьәләсен карау үтенече белән мөрәҗәгать итте.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган балаларны укыту өчен база мәктәпләрен җиһазлауга республика казнасыннан акча бүлеп бирү турындагы хатны карап, Татарстан Республикасы Президенты уңай карар кабул итте. Нәтиҗәдә, 8 мәктәп сәламәтлеге чикле балаларны укыту һәм тәрбияләү өчен 8957,952 мең сумлык кирәкле җиһазлар белән тәэмин ителәчәк.

Вәкаләтле вәкил сәламәтлеге чикле балаларның ата-аналарының мөрәҗәгатьләрен караудан тыш, җәмгыятьтә толерантлык дәрәҗәсен күтәрүгә, инвалид һәм сәламәтлеге чикле булган балаларга яшәү һәм тормышка яраклаштыру өчен уңайлы шартлар тудыруга, мәгариф системасында инклюзияне үстерүгә, инвалид балаларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) аларның хокуклары һәм бурычлары, хокукларын яклау һәм торгызу ысуллары турында хокукый белем бирүгә юнәлдерелгән социаль проектларны гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы иҗтимагый оешмалары белән актив эш алып барды.

Узган ел дәвамында Вәкаләтле вәкил тарафыннан белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар арасында килеп туган низаглы хәлләр турында гражданнарның мөрәҗәгатьләренә зур игътибар бирелде.

Практика шуны күрсәтә: мәктәптә сәламәтлегендә үзенчәлекләр булган «зәгыйфь» балалар низаг тозагына эләгә. Вәкаләтле вәкил фикеренчә, конфликт үсешенә китергән сәбәп – мәгариф оешмаларының низаглы хәлләрне чишүдә кызыксынмавы.

Әйтик, Яшел Үзән районының 5 нче гимназиясендә килеп туган низаглы вазгыять мәсьәләсе буенча 5 нче сыйныфта укучы баланың әнисе Вәкил адресына мөрәҗәгать итте. Мөрәҗәгатьнең эчтәлегеннән күренгәнчә, сыйныфташлары мөрәҗәгать итүченең улын гел мыскыллаганнар, үртәгәннәр, соңгысы үз чиратында моңа тискәре, кайвакыт агрессив җавап биргән. Һичшиксез, мондый караш аның укуында да чагылыш тапкан: укытучылар баланы соңгы партага күчергән, ә гимназия директоры, баланы психиатрга алып барып, өйдә укытырга тәкъдим иткән. Балага неврология диагнозы куелган, ел саен табиб – неврологларда тикшеренгән. Шул ук вакытта ата-анасы аны психиатрия хастаханәсенә салу өчен нигез күрмәгән. Бала сәнгать мәктәбенә йөри, анда коллектив белән мөнәсәбәтләре яхшы.

Шуның белән бергә, ата-анасының баланы психиатрия хастаханәсенә салудан баш тартуы, гимназиядә баланың үз-үзен тотышы һәм сыйныфташлары белән киеренке мөнәсәбәте белем бирү оешмасы җитәкчелеге тарафыннан баланың ата-анасы үз вазыйфаларын тиешенчә үтәми дип бәяләнгән.

Күчмә тикшерү барышында без мәгариф оешмасы директорының үз вазыйфаларын тиешенчә үтәмәвен ачыкладык. Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча мәгариф оешмасы җитәкчесе дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

Икенче буллинг очрагы гражданка Н. гаризасын карау барышында, Казан шәһәренең «Вахитов районы олимпия резервы спорт мәктәбе» оешмасында төркем тренеры ягыннан кабул ителмәү сәбәпле, яшьтәшләре ягыннан баланы рәнҗетү очрагы ачыкланды. Мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча балалар арасындагы низаглы хәл җайга салынды. Спорт мәктәбе хакимияте әлеге төркемдә тренерны алыштыру турында карар кабул итте.

Кызганычка каршы, бу – мәктәптә бала газапланган бер генә очрак түгел. Узган ел мәгариф оешмалары җитәкчелегенең, аерым алганда, низаглы вазгыятьне җайга салу буенча чаралар күрмәвен без шулай ук Казан шәһәре Совет районының Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназиядә, Буа муниципаль районының Иске Суыксу урта гомуми белем бирү мәктәбендә ачыкладык.

Мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре шуны күрсәтә: буллинг локаль масштабтагы күренешкә, ягъни бер мәктәптә генә түгел, ә иҗтимагый күренешкә әверелә.

Вәкаләтле вәкил фикеренчә, мәктәпләрдә аны профилактикалау тәрбия процессының мәҗбүри өлешенә әверелергә тиеш. Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына укучыларның уңай социаль күнекмәләрен һәм социаль яктан яраклы үз-үзен тотышын формалаштыру, шулай ук балаларны буллингка нәтиҗәле җавап бирү һәм белем бирү оешмасындагы психологик хәлне бәяләү чараларын укыту буенча чараларны үз эченә алган буллингны профилактикалауның комплекслы программасын эшләргә тәкъдим итәбез.

Урта һөнәри белем алуга хокукны гамәлгә ашыру өлкәсендә гражданнарның шикаятьләре дә Вәкаләтле вәкил игътибарыннан читтә калмады.

Әйтик, Вәкаләтле вәкил адресына гражданка С.дан мөрәҗәгать килде, аны уку планнарында аерма булуын сәбәп итеп, П.В. Дементьев исемендәге Казан авиация-техник көллиятенә күчерү тәртибендә кабул итүдән баш тартканнар.

Мөрәҗәгатьне карау барышында Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре мөрәҗәгать итүченең тиешле гариза белән көллият администрациясенә мөрәҗәгать итүен ачыкладылар. Гаризаны карау йомгаклары буенча, гражданкага бу учреждениедә укуны дәвам итү мөмкинлеге турында уңай җавап бирелде, бу шулай ук көллият җитәкчесе имзалаган белешмә белән расланды. Әлеге белешмә нигезендә гариза бирүче алдагы белем бирү оешмасыннан чыгарылды.

Шуның белән бергә, кабат мөрәҗәгать иткәндә, аны П.В. Дементьев исемендәге Казан авиация-техник көллиятенә укырга алудан баш тартканнар, моңа уку планнарында булган академик аерманы сәбәп иткәннәр. Шул ук вакытта белем бирү учреждениесенең локаль норматив акты нигезендә, уку планнарындагы аерма учреждениегә күчерелгәннән соң, семестр дәвамында бетерелергә тиеш иде.

Гражданка С.ның белем алуга хокуклары бозылуы ачыклангач, Вәкаләтле вәкил П.В. Дементьев исемендәге Казан авиация-техник көллияте директоры адресына мөрәҗәгать итүченең бозылган хокукларын торгызу буенча мөмкин һәм кирәкле чараларны күрүне сорап тәкъдимнәр җибәрде, аларны карау йомгаклары буенча мөрәҗәгать итүче һөнәри белем бирү учреждениесенә кабул ителде.

Мәгариф мәсьәләләрен караганда мәгариф оешмалары биналарының торышы турындагы мәсьәләгә кагылмый булмый. Белем бирү оешмаларының матди-техник базасын яңарту һәм даими ремонтлау – устав бурычларын гамәлгә ашыру өчен мөһим шарт.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2022 елда 74 мәгариф оешмасында капиталь ремонт үткәрелгән.

Шул ук вакытта «Халык контроле» системасында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен модерацияләү барышында без урынлы проблемалар, шул исәптән оешма җитәкчеләре тарафыннан белем бирү оешмалары биналарын карап тоту буенча тиешле чаралар күрмәү фактларын ачыкладык. 2021 елның декабрендә «Халык контроле» системасына Менделеевск муниципаль районының «Микай (М.С. Герасимов) исемендәге Илнет урта гомуми белем бирү мәктәбе» спорт залында ремонт кирәклеге турында республикада яшәүчедән хәбәр килде. Әлеге мөрәҗәгатьнең планлаштырылган вакытында үтәлмәве фактын билгеләп үтеп (01.09.2022), Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе адресына мөрәҗәгать итте. Безнең муниципаль берәмлек хакимияте белән хезмәттәшлек итү нәтиҗәсендә мәсьәлә уңай хәл ителде.

Күргәнебезчә, дәүләт тарафыннан мәгариф өлкәсендә кабул ителгән чараларга карамастан, күп кенә проблемалар актуальлеген саклый. Белем бирү процессында катнашучыларның мәнфәгатьләре балансын исәпкә алып, аларны ачыклау һәм хәл итү дәүләтнең һәм җәмгыятьнең өстенлекле бурычларының берсе булып тора.

2.5. ТОРАККА ХОКУК

Торак алуга конституциячел хокук күпкырлы һәм һәркем өчен закон белән гарантияләнгән даими торак белән тәэмин ителү мөмкинлеген, булган торактан тотрыклы файдалану мөмкинлеген, торак шартларын яхшырту хокукын, шулай ук торак урыннарында яшәүче гражданнар өчен сәламәт һәм куркынычсыз мохит тәэмин итүне күздә тота.

Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплый, гражданнарның үз конституциячел хокукларын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра.

Татарстан Республикасында яңа торак төзелеше программалары уңышлы тормышка ашырыла. 2022 елда, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәгълүматлары буенча, 2022 елның 20 декабренә 3092 мең квадрат метр торак кулланышка тапшырылган, шул исәптән социаль ипотека программасы буенча – 150,1 мең квадрат метр.

2078,5 мең квадрат метрлы 213 күпфатирлы йорт – төзелеш стадиясендә.

Алданган өлешчеләр проблемаларын чишү буенча системалы эш дәвам итте. 2022 ел нәтиҗәләре буенча өч проблемалы объект буенча 302 өлешче үз хокукларын торгызган.

Татарстан Республикасында яңа торак төзү программалары уңышлы тормышка ашырыла. 2022 елда, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2022 елның 20 декабренә 3092 мең квадрат метр торак, шул исәптән социаль ипотека программасы буенча 150,1 мең квадрат метр торак файдалануга тапшырылган.

Ташламага ия булган 25 күпбалалы гаилә, 50 яшь гаилә һәм 5 чернобыльче фатирлы булган.

Шуның белән бергә, башкарылган эшкә карамастан, әлеге төркем гражданнарының мөрәҗәгатьләре саны кимеми.

2022 елда гражданнарның торак хокукларын яклау мәсьәләләре буенча Вәкаләтле вәкил адресына килгән мөрәҗәгатьләр саны 529га җитте.

Шул ук вакытта торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә без Вәкаләтле вәкилгә турыдан-туры килгән мөрәҗәгатьләрне генә түгел, ә мәгълүмат системаларын мониторинглау аша да карыйбыз. Бу өлкәдәге проблемалар турында хәбәр итү өчен безнең республика халкы «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасыннан, ГЛОНАСС +112 системасыннан актив файдалана.

2022 елда «Торак-коммуналь хуҗалык» юнәлеше буенча мәгълүмат системасында 4335 мөрәҗәгать бастырылган. Мөрәҗәгатьләрнең күпчелеге «коммуналь хезмәтләр» – 2 374 мөрәҗәгать һәм «йортны карап тоту» төрләре буенча килде – 1 441 гариза. Мөрәҗәгатьләрнең күбесе Казан шәһәре (2601), Яр Чаллы шәһәре (330), Әлмәт (700), Түбән Кама (147), Бөгелмә муниципаль районнарыннан (109) килгән.

«Халык контроле» системасына кергән мөрәҗәгатьләрне, шулай ук гаризаларны анализлау нәтиҗәләрен карасак, узган елда Вәкаләтле вәкилгә гражданнарның социаль яктан якланмаган категорияләрен торак белән тәэмин итү, халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен уңайлы тирәлек оештыру мәсьәләләре буенча мөрәҗәгать иттеләр. Торак йортларда үткәрелгән агымдагы һәм капиталь ремонт нәтиҗәләреннән канәгать булмаудан, шулай ук идарәче һәм ресурс белән тәэмин итүче оешмаларның җитәрлек эшләмәвеннән зарландылар.

Гражданнарның мөрәҗәгатьләре Татарстан Республикасы дәүләт Торак инспекциясе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм җирле үзидарә органнары белән тыгыз бәйләнештә каралды.

Республикада яшәүчеләрне борчыган торак-коммуналь хуҗалыгы тармагындагы сорауларның киң спектрын исәпкә алып, Вәкаләтле вәкил гражданнар тарафыннан кызыксындырган мәгълүматны алуга юнәлдерелгән эшнең төрле ысулларын кулланды. Әлеге өлкәдә Татарстан Республикасы дәүләт Торак инспекциясе, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, «Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә иҗтимагый контроль төбәк үзәге» һәм «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар белән идарә итүче оешмалар бердәмлеге» ассоциациясе белгечләрен җәлеп итеп, тематик «кайнар элемтә»ләр уздыру халык белән хезмәттәшлекнең бер ысулы булып торды.

Узган ел Вәкаләтле вәкилнең аерым игътибары Татарстан Республикасы торак сәясәтенең мөһим юнәлешләренең берсенә – ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итүнең актуаль социаль проблемасына юнәлтелде, монда аерым хокук бозулар ачыкланды.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тәкъдим иткән мәгълүмат буенча, 2022 елның 19 декабренә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан 561 граждан торак белән тәэмин ителгән.

Әйтик, 2022 елның февралендә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган бала буларак торак шартларын яхшырту хокукын гамәлгә ашыра алмауга карата шикаять белән иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән граждан Ж. мөрәҗәгать итте.

Мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүченең 2011 елда торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ ятим балалар исемлегенә кертелүе ачыкланды. Мөрәҗәгать итүчегә махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыны бирү турындагы мәсьәлә төзәтү учреждениесендә җәза срогы үтәү сәбәпле туктатылган. 2022 елда мөрәҗәгать авторы җәза үтәүдән вакытыннан алда азат ителә һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына аңа махсус найм килешүе буенча торак урыны бирү турында гариза белән мөрәҗәгать итә. Әмма асылда аның гаризасы каралмаган.

Вәкаләтле орган гамәлләрендә махсуслаштырылган найм шартнамәсе буенча торак урыны бирү турындагы гаризаны карау өчен билгеләнгән срокны бозу ачыклануга бәйле рәвештә, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры адресына гражданның торак хокукларын гамәлгә ашыру буенча законда куела торган таләпләрне бозуга юл куймау һәм чаралар күрү зарурлыгы турында хат җибәрде. Мөрәҗәгать итүченең соравы уңай хәл ителде һәм гражданга Казан шәһәрендә махсуслаштырылган торак фондыннан уңайлы торак бирелде.

Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның мөлкәткә хокукларының өстәмә гарантиясе булып, авыр тормыш хәлен җиңәргә ярдәм итү зарурлыгы турында дәлилләүче хәлләр булмаганда махсуслашкан торак наймы килешүенең гамәлдәге вакыты тәмамланганнан соң торакка социаль наем шартнамәсен төзү мөмкинлеге тора. Үз чиратында, социаль наем шартнамәсе төзү бирелгән торакны киләчәктә хосусыйлаштыруга хокук бирә.

«Торак фонды белән идарә итү департаменты» ДБУ мәгълүматлары буенча 2022 елда ятим балалар арасыннан 145 кеше социаль наем шартнамәсе төзегән. (2022 елның 21 декабренә булган мәгълүматлар.)

Шуның белән бергә 2022 елда Вәкаләтле вәкил, вәкаләтле орган тарафыннан, ятим балалар арасыннан аның белән төзелгән махсус торак урынына наем шартнамәсенең гамәлдә булу срогы тәмамланганнан соң торакка социаль наем шартнамәсе төзүдән нигезсез баш тарту һәм әлеге затны ул яшәгән махсуслашкан торак фондыннан чыгаруның аерым очракларын ачыклады.

Әйтик, узган елның мартында Вәкаләтле вәкилгә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының ятим бала буларак яңа бишьеллыкка махсуслаштырылган наем шартнамәсен озайту турындагы карары белән килешмәү турында Түбән Камада яшәүче кеше мөрәҗәгать итте.

Үз чиратында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан Вәкаләтле вәкил соравы буенча тәкъдим ителгән материалларда, шулай ук «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кергән һәм махсуслашкан торак биналары наемы килешүе буенча махсуслашкан торак фондының торагын яллап торучы 23 яшькә җиткән затларга авыр тормыш хәлен җиңәргә ярдәм итү кирәклеген раслаучы шартларны ачыклау тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 30 апрелендәге 371 номерлы карары белән каралган шартлар турында мәгълүмат булмады.

Вәкаләтле вәкилнең тәкъдимнәрен карап, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы безнең фикер белән килеште һәм мөрәҗәгать итүче белән киләчәктә аның белән торакка социаль наем шартнамәсе төзү өчен махсуслашкан торак наем шартнамәсен өзү турында карар кабул итте.

Ачыкланган хокук бозуларны анализлаудан чыгып, Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгына ятим балаларга авыр тормыш хәлен җиңеп чыгарга ярдәм итү кирәклеген күрсәтүче шартлар турында бәяләмә әзерләгәндә яисә булмавы хакында бәяләмә әзерләгәндә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 30 апрелендәге 371 номерлы карары белән каралган, ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кергән һәм махсуслашкан торак биналары наемы килешүе буенча махсуслашкан торак фондының торагын яллап торучы 23 яшькә җиткән затларга авыр тормыш хәлен җиңәргә ярдәм итү зарурлыгын раслаучы шартларны ачыклау тәртибендә билгеләнгән таләпләрне үтәүне тәэмин итүне тәкъдим итүне максатка ярашлы дип саныйбыз.

Инвалидлар хокуклары турындагы халыкара конвенциягә ярашлы рәвештә мөмкинлекләре чикләнгән гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыруга кагылышлы мөрәҗәгатьләре Вәкаләтле вәкилгә аеруча борчылу тудырды.

Безнең адреска керүче мөрәҗәгатьләргә еш кына мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә урамда түгел, ә аларның яшәү урынында очрый торган кыенлыклар турында сүз бара, анда аларга баскычка менү, баскыч арасын узып китү, лифтка эләгү, фатирда турыдан-туры хәрәкәт итү бик авыр.

Күпфатирлы йортта инвалид өчен торак бинаның һәм гомуми мөлкәтнең үтемле булуы, инвалидның торак бинага тоткарлыксыз үтеп керүен тәэмин итү өчен, аның тормыш эшчәнлеген чикләү үзенчәлекләренә карап, аларны яңадан җиһазлау ярдәмендә тәэмин ителә.

Әйтик, коляскадагы инвалид күршесе мәнфәгатьләрен кайгыртып, күпфатирлы йорт подъездына кергәндә пандус булмау сәбәпле, Бөгелмәдә яшәүче гражданка М. мөрәҗәгать итте, инвалид тышкы дөньядан аерылган. Вәкаләтле вәкил, Бөгелмә шәһәре хакимияте һәм идарәче оешманың уңышлы хезмәттәшлеге нәтиҗәсендә мөстәкыйль хәрәкәт итүдән мәхрүм булган граждан яшәгән йорт подъездына керү пандус һәм култыкса белән җиһазландырылган.

Тагын бер мисал китерик. 2022 елның маенда инвалид коляскасын күтәрү/төшерү өчен торак йорт подъездында техник ярдәмче җайланма урнаштыруда ярдәм күрсәтүне сорап Казан шәһәренең Идел буе районында яшәүче гражданка К. мөрәҗәгать итте.

Вәкаләтле вәкилнең һәм Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе районнары хакимиятенең, идарәче оешманың торак йортның баскычларын инвалид ихтыяҗына яраклаштыру буенча уртак эше нәтиҗәсендә үтенеч үтәлде, ә мөрәҗәгать итүче әлеге мәсьәләне оператив хәл иткән өчен рәхмәт белдерде.

Безнең тарафтан торак-коммуналь хуҗалык тармагына кагылышлы турыдан-туры килгән мөрәҗәгатьләр генә түгел, ә мәгълүмат системаларын күзәтү аша да карала.

Татарстан Республикасы «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәре өчен торак йортларда уңайлы мохит булдыру мәсьәләләре буенча 21 мөрәҗәгать керде.

Вәкаләтле вәкилнең Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе, Совет районнары хакимиятләре, Яр Чаллы шәһәре башкарма комитеты, Түбән Кама һәм Зәй муниципаль районнары хакимиятләре һәм идарәче оешмалар белән уртак эше нәтиҗәсендә республикабыз гражданнарының 10 мөрәҗәгате буенча инвалидларга күпфатирлы йортларга керү мөмкинлеге бирелә.

Мисал итеп, Яр Чаллы шәһәре башкарма комитетының Автозавод районы хакимияте һәм идарәче оешманың Чаллы шәһәренең Хәсән Туфан проспектындагы 4 нче күпфатирлы йорт подъездына кергәндә пандус урнаштыру буенча уртак эшен күрсәтергә була.

Күпфатирлы йортларда инвалидлар һәм башка аз хәрәкәтләнүче халык төркемнәре өчен уңайлы мохит тәэмин итү дәүләт, муниципаль органнар һәм идарәче оешмалар җайга салынган очракта мөмкин дип саныйбыз.

Кызганычка, торак биналарны һәм гомуми файдаланудагы урыннарны адаптацияләү буенча чараларны, техник мөмкинлекләре булмау сәбәпле, халыкның аз хәрәкәтләнүче төркемнәре яши торган барлык күпфатирлы йортларда да үткәрергә мөмкин түгел.

Шуның белән бергә Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварында дөнья күргән 47 нче «Торакны, торак урынын яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карары белән инвалидлар алып торган биналарны, инвалидлар ихтыяҗларын исәпкә алып, торак йортны яраклаштыру мөмкинлеге булмау турында ведомствоара комиссия заключениесе нигезендә гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары яшәү өчен яраксыз дип тану мөмкинлеге каралган.

Шул ук вакытта, органнар вәкаләтләренең җентекле регламенты булуга карамастан, Вәкаләтле вәкил инвалидларның гаризаларын караганда гражданнар хокукларын бозу очракларын ачыклады.

Әйтик, үзенең балигъ булмаган улы мәнфәгатьләрен кайгыртып, инвалидның торак урынын аның яшәү өчен яраксыз дип тану турындагы гаризаны озак караудан (ике айдан артык) зарланып, узган елның июлендә Казан шәһәрендә яшәүче гражданка Ф. мөрәҗәгать итте. Мөрәҗәгатьтә хәбәр ителгәнчә, торак урынны инвалидлар өчен яраксыз дип тану мәсьәләсе белән мөрәҗәгать итүче, башта Казан шәһәренең Совет районы хакимиятенә мөрәҗәгать иткән, алар аның документларын торак урынын яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки төзекләндерелергә тиешле дип тану буенча шәһәр ведомствоара комиссиясенә җибәргән.

Шикаять материалларын карау нәтиҗәләре буенча, шәһәр ведомствоара комиссиясе тарафыннан Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварында дөнья күргән 47 нче карары белән расланган торакны, торак урынын яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки төзекләндерелергә тиеш, бакча йортын торак йорт, торак йортны бакча йорты дип тану турындагы нигезләмәнең 46 пунктында билгеләнгән гаризаны карауның 30 көнлек срогы бозылганга күрә, шәһәр ведомствоара комиссиясе рәисе адресына Вәкаләтле вәкил гражданка Ф.ның бозылган хокукларын торгызу буенча кирәкле чаралар күрү турында тәкъдимнәр җибәрде.

Аны карау нәтиҗәләре буенча гражданка Ф. гаризасы кыска вакыт эчендә каралды һәм инвалид һәм аның гаилә әгъзаларының торагы яшәү өчен яраксыз дип танылуы турында карар кабул ителде.

Әлеге факт торакка мохтаҗ гражданга социаль наем шартнамәсе буенча чираттан тыш торак урыны бирү өчен нигез булып торачак.

Торак урынны яшәү өчен яраксыз дип, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында гаризалар кабул иткәндә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты эшендә дә хокук бозулар ачыкланды.

Мәсәлән, «ГЛОНАСС+112» системасы аша кергән мәгълүматны карау йомгаклары буенча җирле үзидарә органыннан Нурлат шәһәре, Гыйматдинов урамы, 162 нче йорт адресы буенча урнашкан күпфатирлы йортны бәяләү һәм тикшерү авария хәлендә дип тану, аны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында, күпфатирлы йорттагы барлык милекчеләрдән гариза һәм административ регламент белән каралган документлар кергән очракта ведомствоара комиссия тарафыннан тормышка ашырылачак, дигән җавап алынды.

Шуның белән бергә, Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган торак урынын, торак йортны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы нигезләмәнең 42 пункты нигезендә, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә һәм үзгәртеп корылырга тиешле дип тану максатларында бәяләүне һәм тикшерүне үткәрү өчен күрсәтелгән йорттагы милекчеләрнең берсенең гаризасы җитә.

Җирле үзидарә органының гамәлләрендә торак законнары нормаларын бозуны ачыклау һәм гариза бирүчегә үз хокукларын гамәлгә ашырганда таләпләрне арттырулары сәбәпле, Вәкаләтле вәкил Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе адресына кисәтү җибәрде.

Бәян ителгән мисаллар нигезендә, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына һәм торак урынын, торакны яшәү өчен яраксыз дип тану буенча ведомствоара комиссияләргә бина милекчесе, хокук иясе яки граждан (яллаучы) гаризаларын караганда (кабул иткәндә) Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварында дөнья күргән 47 нче карары белән расланган торак урынын, торакны яшәү өчен яраксыз дип, күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип, торак йортны бакча йорты һәм бакча йортын торак йорт дип тану турындагы нигезләмәдә каралган таләпләрне үтәүне тәэмин итәргә тәкъдим итәбез.

Торак-коммуналь хуҗалык тармагындагы мәсьәләләр дә актуальлеген югалтмады. Узган елда Вәкаләтле вәкил адресына 258 мөрәҗәгать керде.

Контроль-күзәтчелек органы статистикасы да проблеманың системалы факторын раслый.

Татарстан Республикасы дәүләт Торак инспекциясе мәгълүматларына караганда, узган елда (2022 елның 20 декабренә) торак-коммуналь хуҗалык тармагында 19179 закон бозу очрагы ачыкланган, шул исәптән гомуми милекне тиешенчә карап тоту фактлары буенча – 11870 һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүне хокук бозып исәпләү фактлары буенча – 46 очрак. Кабул ителгән чаралар нәтиҗәсендә кулланучыларга торак-коммуналь хезмәтләр өчен 2,03 млн сум акча яңадан исәпләп, кире кайтарылды.

Тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча торак законнары таләпләрен бозуга юл куймау турында 3373 кисәтү бирелде һәм 5,1 миллион сумга административ штраф рәвешендә административ җәза билгеләү турында 1884 карар төзелде.

Шуның белән бергә, торак законнары өлкәсендә хокук бозуларны ачыклау буенча планлы эш алып баруга карамастан, әлеге өлкәдә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләре күрсәткәнчә, кайбер очракларда гражданнарның дәлилләре контроль-күзәтчелек органы тарафыннан игътибарга алынмаган.

Әйтик, 2022 елның маенда Вәкаләтле вәкил адресына гражданка К.ның Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында яшәүче әбисе мәнфәгатьләрен кайгыртып, җир кишәрлеген һәм каралты корылмаларын кулланганда салкын су белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәт өчен нигезсез исәпләү турында мөрәҗәгате килгән. Хәлне ачыклау һәм бирелгән материалларны анализлау ресурс белән тәэмин итүче оешманың әлеге хезмәт өчен түләтүенең нигезле булмавын күрсәтте.

Вәкаләтле вәкилнең торак законнары нормаларын бозу турындагы позициясе Алабуга районара торак инспекциясе тарафыннан хупланмады.

Шуның белән бергә, без тәкъдим иткән прокурор урынга барып тикшереп, безнең позициябезне хуплады һәм хокук бозулар расланды, бу Татарстан Республикасы Мамадыш районы прокуратурасының ресурс белән тәэмин итүче оешмасы адресына аларны бетерү турындагы күрсәтмәне кертү өчен нигез булды, ә мөрәҗәгать итүчегә 2525,98 сумга яңадан исәп-хисап ясалды.

Узган ел контроль-күзәтчелек органнары белән берлектә торак-коммуналь хуҗалык тармагындагы башка мөрәҗәгатьләр буенча да нигезсез исәпләнгән түләүне яңадан исәпләүгә ирешелде.

Әйтик, Әлмәт шәһәрендә яшәүче Г. кайнар су белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәт күрсәткән өчен бурычларын нигезсез исәпләү мәсьәләсе буенча Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итте.

«Әлмәт ИК» ЖЧҖ идарәче компаниясе тарафыннан исәпкә алу приборының торышын чираттагы тикшерү барышында мөрәҗәгать итүче фатирында 6 ай элек коммуналь хезмәт күрсәтелгән. Бу исәпкә алу приборы эшенә санкцияләнмәгән тыкшыну фактын тану һәм әлеге хезмәт өчен түләүне яңадан исәпләүне үткәрү өчен нигез булган.

Әлеге мөрәҗәгатьне карап тикшерү барышында Вәкаләтле вәкил тарафыннан исәпкә алу приборының эшенә рөхсәтсез тыкшыну факты буенча идарәче компания тарафыннан, хокук бозу фактын ачыкланганнан соң 6 ай узгач, коммуналь хезмәт күрсәтүгә түләүне яңадан исәпләү кагыйдәләре бозылган, ә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 6 маенда дөнья күргән 354 нче карары белән расланган коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләренең 81 (11) пункты нигезендә, күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда бинаның милекчеләренә һәм файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләренә ярашлы рәвештә, мондый яңадан исәпләү өч ай алдан үткәрелә.

Татарстан Республикасы дәүләт Торак инспекциясе тарафыннан Вәкаләтле вәкил инициативасы белән планнан тыш документар тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә коммуналь хезмәт күрсәтүгә исәпләнгән түләүне кулланучыга артык кайтарылган факты расланды. Тикшерү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә «кайнар су белән тәэмин итү» хезмәте буенча артык исәпләнгән 59705 сум акча кире кайтарылды, ә «Әлмәт ИК» ЖЧҖ идарәче компаниясенең вазыйфаи заты РФ КоАП 14.1.3 маддәсенең 2 өлеше буенча административ җаваплылыкка тартылды.

Тулаем алганда, гражданнарның торак-коммуналь хуҗалык тармагына кагылышлы хокукларын бозу турындагы шикаятьләрне карау нәтиҗәләре буенча Вәкаләтле вәкил күзәтчелек органнарына мондый мөрәҗәгатьләрне тикшерү үтенече белән генә түгел, ә оператив рәвештә бетерү максатыннан, хокук бозуларга юл куйган оешма җитәкчеләренә үз позициясен дә белдерде.

Казан шәһәренең Бауман урамындагы күпфатирлы йортта яшәүче хатын-кыз Ш.ның коммуналь хезмәтләр өчен түләүнең күләме белән килешмәве турында шикаяте буенча Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча гариза бирүче тарафыннан тапшырылган материаллар һәм түләү документларын өйрәнде. Тикшерү барышында ресурс белән тәэмин итүче оешма тарафыннан каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча коммуналь хезмәт күрсәтүгә түләү дөрес булмаган тариф буенча исәпләнүе ачыкланды һәм аның нәтиҗәләре буенча җитәкчесе адресына Вәкаләтле вәкил тәкъдимнәре җибәрелде. Аларны карау нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә, 2019 елның 1 гыйнварыннан башлап, хокук бозу ачыкланган вакытка кадәр, коммуналь хезмәт күрсәтүгә түләүне яңадан исәпләделәр.

Узган елда язгы-көзге чорда күпфатирлы йортларда идарәче оешмаларның, аерым алганда торак йортларның түбәләрен тиешенчә карап тотмаулары буенча мөрәҗәгатьләр арту тенденциясе күзәтелде.

Әйтик, «УК «Жилкомплекс» ЖЧҖ идарәче компаниясе тарафыннан 2022 елның апрелендә Яшел Үзән шәһәренең Энгельс урамындагы күпфатирлы йортның түбәсеннән агуны бетерү турында гамәлгә көтеп тормыйча, граждан З. Вәкаләтле вәкил адресына мөрәҗәгать итте. Вәкаләтле вәкил үтенече буенча Татарстан Республикасы дәүләт Торак инспекциясе урынга чыгып тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә идарәче оешма җитәкчесе адресына хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирелде, нәтиҗәдә идарәче оешма тарафыннан узган елның май аенда түбәне ремонтлау эшләре башкарылды.

Түбәне вакытында ремонтламауга карата шикаятьләр «Халык контроле» Татарстан Республикасы мәгълүмат системасы аша да килде.

Әйтик, әлеге мәгълүмат системасында гражданнарның мөрәҗәгатьләренә мониторинг уздыру нәтиҗәләре буенча әлеге төрдәге хәбәрләр буенча, Вәкаләтле вәкилнең турыдан-туры катнашлыгы белән аларның соң түбәләрне ремонтлау эшләре башкарылды.

Әйтик, әлеге мәгълүмат системасында гражданнарның белдерүләренә мониторинг уздыру нәтиҗәләре буенча, Әлмәт шәһәренең Фәхретдин урамындагы күпфатирлы йортта яшәүченең мөрәҗәгате буенча түбәне ремонтлау буенча озак вакытлар (9 айдан артык) чаралар күрелмәү факты ачыкланды. Вәкаләтле вәкил катнашканнан соң ремонт буенча эш башкарылды.

Республика халкына торак-коммуналь хезмәтләрне вакытында һәм сыйфатлы итеп күрсәтү бурычларын чишү максатыннан, узган елда без барлык муниципаль берәмлекләрдә торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә турыдан-туры җавап бирүче идарәче компанияләрне, торак милекчеләре ширкәтләрен һәм башка оешмаларны «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына тоташтыру буенча киң колачлы эш башкардык.

Мондый чараларны уздыру, үз чиратында, «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы аша килүче мөрәҗәгатьләрнең сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген арттырырга ярдәм итә.

2022 елның августында Вәкаләтле вәкил инициативасы буенча, «Халык контроле» системасында шикаятьләр буенча җаваплы башкаручылар сораулары барлыкка килү сәбәпле җирле үзидарә органнары, идарәче компанияләр һәм торак милекчеләре ширкәтләре җитәкчеләре өчен семинар-киңәшмә оештырылды.

Докладта гражданнарның торак хокуклары өлкәсендәге проблемалы мәсьәләләр масштабы һәм проблеманың кискенлеге буенча аерыла, әмма аларның һәркайсы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм ресурс белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан игътибар таләп итә.

2.6. УҢАЙЛЫ ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ МОХИТ

Уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокук кешенең тормыш сыйфаты критерийларын билгели, дәүләтнең күрелә торган гражданнарның тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлтелгән чараларның бер өлеше булып тора. Бу хокукны нәтиҗәле гамәлгә ашыру кешенең һәм гражданның башка хокукларын, ирекләрен һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле шартлар тудыра.

«Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында керүче мөрәҗәгатьләрне бар модераторы хокукларында Вәкаләтле вәкил тарафыннан, системага тиешле төрләр буенча керүче мөрәҗәгатьләрне көндәлек модерацияләү юлы белән, уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукларның үтәлешенә даими мониторинг үткәрелде.

«Халык контроле» системасында «Экология» юнәлеше буенча мөрәҗәгатьләрнең ел саен артуын билгеләп үтәргә кирәк. 2022 елда мәгълүмат системасына 1761 мөрәҗәгать килгән, бу 2021 ел белән чагыштырганда 4 процентка күбрәк. Шул ук вакытта әлеге юнәлеш буенча гражданнардан иң күп мөрәҗәгатьләр «Чүплек» төре буенча килгән – 1192, «Һава» – 223 мөрәҗәгать һәм «Санитар халәт» – 194 мөрәҗәгать.

Экологик куркынычсызлык мәсьәләләре буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре спектры Татарстан Республикасының барлык муниципаль берәмлекләрен диярлек колачлый. «Чүплек» төре буенча шикаятьләрнең күпчелеге Казан шәһәре (402 шикаять), Яр Чаллы (163), Түбән Кама (335), Питрәч (43), Тукай муниципаль районнары (42 шикаять) буенча мәгълүмат системасына керде. Шул ук вакытта җаваплы башкаручыларның гражданнар мөрәҗәгатьләрен тиешенчә вакытында карамаган очраклары да булды.

Әйтик, 2022 елның маенда без Зәй шәһәре территориясендә санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү мәсьәләсе буенча «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында шикаятьләрне озак вакытлар үтәмәү фактын билгеләдек. Зәй муниципаль районы башкарма комитеты эшләр башкару срогын 2022 елның ноябренә билгеләгән иде. Мөрәҗәгатьләрне үтәүнең шундый озак сроклары белән риза булмау сәбәпле, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башлыгы адресына мөрәҗәгать итте. Зәй муниципаль районы башкарма комитеты Вәкаләтле вәкилнең хатын карап, 2022 елның июнендә санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү буенча эш башкарды.

Җирле үзидарә органнары белән берлектә Тукай муниципаль районының Әҗмәкәй, Калмаш, Мәләкәс, Теләнче-Тамак авыл җирлекләре территорияләрендә законсыз чүплекләрне бетерү буенча зур эш башкарылды. Гомумән алганда, узган елда «Халык контроле» системасында гражданнарның уңай әйләнә-тирә мохиткә хокукларын яклау максатларында мөрәҗәгатьләрне мониторинглау нәтиҗәләре буенча Вәкаләтле вәкил җаваплы башкаручылар адресына 30 дан артык тәкъдимнәр җибәрде.

Тулаем алганда, экологик законнарны үтәү һәм санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү мәсьәләләре, аерым алганда, узган ел дәвамында муниципаль районнардагы эш киңәшмәләрендә фикер алышу предметы булды.

Республика муниципаль берәмлекләре хакимиятләре белән уртак эш нәтиҗәләре буенча Казан шәһәре, Әлмәт, Бөгелмә, Югары Ослан, Биектау, Яшел Үзән, Алабуга, Кама Тамагы, Лаеш, Түбән Кама, Яңа Чишмә, Спас муниципаль районнары территорияләрендә санкцияләнмәгән чүплекләр бетерелде.

Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башлыгы адресына узган елның июлендә Габишево авыл җирлегендә яшәүчеләрдән килгән мөрәҗәгать буенча, Приозерная һәм Октябрь урамнарында санкцияләнмәгән чүплекләрне юкка чыгаруны сорап мөрәҗәгать итте. Безнең катнашу нәтиҗәсендә җыелган чүп-чар тиешле урынга чыгарылды.

Бу төркемнең мөрәҗәгатьләре безнең мәгълүмат системаларын мониторинглау аша гына каралмый. Контроль-күзәтчелек органнары һәм җирле үзидарә органнары белән үзара бәйләнештә Вәкаләтле вәкил безнең адреска турыдан-туры кергән уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукларны массакүләм бозу турында мәгълүматлар булган гражданнар мөрәҗәгатьләрен карады.

Әйтик, узган елның гыйнварында Вәкаләтле вәкил адресына Казан шәһәренең Константиновка торак массивы янындагы законсыз кар һәм төзелеш чүп-чары чүплеге мәсьәләсе буенча гражданка М. мөрәҗәгать итте. Татарстан Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының без оештырган тикшерүе мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслады, гаепле зат РФ КоАП 8.2 маддәсе 1 өлеше һәм ТР КоАП 3.6 маддәсе 1 өлеше буенча административ җаваплылыкка тартылды, шулай ук әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыян 47320 сум дип исәпләнде. Башкарылган эш нәтиҗәләре буенча хокук бозулар бетерелде, зыян һәм штраф гаепле зат тарафыннан түләнде.

Вәкаләтле вәкилнең шәхси кабул итүендә 2022 елның октябрендә Казан шәһәренең Волгодонская урамында яшәүчеләрдән йорт яны территориясен тиешенчә карап тотмау турында коллектив мөрәҗәгать килде. Мөрәҗәгать итүчеләр раславынча, территориянең каты төзелеш һәм көнкүреш калдыклары белән пычрануы санитар-эпидемиологик таләпләрнең бозылуына китергән.

Җирле үзидарә органы һәм Татарстан Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән уртак эш йомгаклары буенча җир кишәрлеге милекчесе адресына күзәтчелек органы тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозуга һәм җир кишәрлеге территориясендә рөхсәтсез калдыклар җыюны бетерүгә юл куймау турында кисәтү җибәрелде. Бу мәсьәлә Татарстан Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы һәм Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил контролендә кала.

Җитештерү һәм куллану калдыклары барлыкка килү кеше тормышы белән турыдан-туры бәйле һәм нәтиҗәдә аларны урнаштыру, зарарсызландыру, эшкәртү һәм утильләштерү буенча даими эшчәнлек таләп итә.

Узган ел «Халык контроле» системасына «Каты коммуналь калдыклар» юнәлеше буенча гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләрне вакытында үтәүне контрольдә тотуга Вәкаләтле вәкил аерым игътибар бирде.

2022 елда «Халык контроле» системасына әлеге юнәлеш буенча 2210 мөрәҗәгать килгән, бу 2021 ел белән чагыштырганда 10 процентка күбрәк. Үз мөрәҗәгатьләрендә республика халкы каты коммуналь калдыкларны вакытында чыгаруны оештыру, аларны җыю өчен контейнерларның һәм мәйданчыкларның тиешенчә торышы белән бәйле проблемалар турында ешрак хәбәр итте.

Узган елда «Каты коммуналь калдыкларны чыгару» төре буенча «Халык контроле» системасына 866 мөрәҗәгать килгән, шуларның иң күп саны Казан шәһәре буенча (376 мөрәҗәгать), Лаеш (81 мөрәҗәгать) һәм Әлмәт районнары буенча (78 мөрәҗәгать).

Чүп-чарны вакытында чыгармауга шикаятьләр «Инцидент-Менеджмент» системасы аша да килде, ул социаль челтәрләр аша гражданнар белән диалог алып барырга мөмкинлек бирә. Әлеге төр буенча системага гражданнардан 802 мөрәҗәгать керде, шуларның иң күбесе Яр Чаллы шәһәре (105), Казан (99), Әлмәт (86), Алабуга (85), Түбән Кама (76) муниципаль районнарыннан.

Контроль-күзәтчелек органнары белән нәтиҗәле хезмәттәшлектән тыш, Вәкаләтле вәкил «Халык контроле»нә һәм «Инцидент-Менеджмент» системасына килгән мөрәҗәгатьләрне каты көнкүреш калдыклары җыю буенча төбәк операторы вәкилләре һәм җирле үзидарә органнары катнашында каты көнкүреш калдыкларын җыю өлкәсендә төбәк операторлары эшчәнлеген карау буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының эш штабы утырышларында атна саен карады.

Штабның 10 утырышында барлыгы 70тән артык мөрәҗәгать каралды.

Узган ел гражданнарның республиканың авыл торак пунктларында каты коммуналь калдыклар җыелу мәйданчыклары белән җиһазландырылмаган каты коммуналь калдыкларны чыгару мәсьәләләренә кагылышлы кайбер мөрәҗәгатьләренә Вәкаләтле вәкилнең аерым игътибары юнәлтелде.

Әйтик, «Халык контроле» системасында гражданнарның мөрәҗәгатьләренә мониторинг уздыру нәтиҗәләре буенча «Гринта» ҖЧҖ төбәк операторының Зәй муниципаль районының кайбер торак пунктларында чүп чыгаруның вакытын үзгәртүдән нигезсез рәвештә баш тартуы ачыкланды. Көн саен җылы вакытта (уртача тәүлеклек температура +5°С булганда) каты көнкүреш калдыкларын чыгару аена нибары 1–2 тапкыр башкарылды, бу исә халыкның системага шикаятьләре артуга китерде.

Вәкаләтле вәкил тәкъдимнәрен үтәп, «Гринта» ҖЧҖ төбәк операторы Зәй муниципаль районының кайбер торак пунктлары территориясеннән каты көнкүреш калдыкларын чыгару вакытын арттыру буенча төзәтмәләр кертте. Хокук бозуларны бетерү буенча төбәк операторлары тарафыннан чаралар күрелмәгән очракта, Вәкаләтле вәкил гражданнарның хокукларын яклау максатыннан күзәтчелек органнарына мөрәҗәгать итте. Безнең инициатива буенча Мамадыш районы прокуратурасы органнары тарафыннан Мамадыш районы Васильево авылы территориясендә каты көнкүреш калдыкларын чыгарганда төбәк санитар кагыйдәләрен бозу турында гражданин З.ның мөрәҗәгате буенча тикшерү оештырылды. Мөрәҗәгатьне карау барышында гражданинның дәлилләре расланды.

2022 елның сентябрендә Мамадыш районы прокуратурасының «Гринта» ҖЧҖ төбәк операторына Мамадыш муниципаль районы торак пунктлары территориясендә каты көнкүреш калдыклары чыгару графикларының туры килмәве һәм аларны чыгару вакытын арттыру факты буенча дәгъва белдерүе канәгатьләндерелде. Рөхсәтсез чүплекләр барлыкка килүнең бер сәбәбе – торак пунктларда каты көнкүреш калдыклары җыелу урыннарының җитәрлек булмавы.

«Халык контроле» системасында контейнер мәйданчыклары булмау һәм ремонтлау мәсьәләләре буенча 2022 елда республикабыз халкы тарафыннан 431 хәбәрнамә бастырылган.

Контейнер мәйданчыкларын ремонтлау һәм алар булмау мәсьәләләре буенча 2022 елда республикабыз халкы тарафыннан «Халык контроле» системасында 431 мөрәҗәгать бастырылды, шуларның 293е уңай хәл ителде.

Контейнер мәйданчыкларын төзү мәсьәләсе буенча гражданнардан иң күп мөрәҗәгатьләр Казан шәһәре буенча – 209, Яр Чаллы – 23, Әлмәт – 43, Лаеш – 27, Спас – 20, Яшел Үзән – 15, Түбән Кама муниципаль районнары буенча килде.

Вәкаләтле вәкилнең «Халык контроле» мәгълүмат системасында урнаштырылган мөрәҗәгатьләрне карау йомгаклары буенча Казан шәһәренең җирле үзидарә органнары белән уртак эше нәтиҗәсендә 2022 елда Казан шәһәренең Академик Губкин, Яңа Азино, Җимешле урамнары, Константиновка бистәсенең Привольная һәм Интернационал урамнары, Казан шәһәренең Зур Клыки торак массивындагы Октябрь урамы, Казан шәһәренең Ян һәм Юл тыкрыклары урамнарында контейнер мәйданчыклары яңартылды.

Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендәге мәсьәләләрне карауда башка мәйданчыкларда да катнаштык, шул исәптән республиканың муниципаль районнарына да бардык.

2022 ел дәвамында Вәкаләтле вәкил, шулай ук 2021 елның декабрендә үткәрелгән «Төбәк белән идарә итү үзәге» проектын гамәлгә ашыру буенча Проект офисының ачык утырышы нәтиҗәләре буенча җитештерү һәм куллану калдыклары әйләнешендә кеше сәламәтлеген һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре буенча беркетмә йөкләмәләренең үтәлешен контрольдә тотты.

2022 елда әлеге йөкләмәләрне үтәү сәбәпле, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең рәсми сайтларында контейнер мәйданчыклары урнашу схемалары урнаштырылды, «ПЖКХ» ИК һәм «Гринта» ҖЧҖнең төбәк операторлары сайтларында торак пунктларда каты көнкүреш калдыкларын чыгару графигы урнаштырылды.

Каты коммуналь калдыклар белән эш итү проблемасын хәл итүдә, һичшиксез, мөһим һәм нәтиҗәле механизм – калдыклар урнаштыру буенча яңа инфраструктура булдыру.

Бу уңайдан 2023 елда, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан 2022 елда расланган инвестицион программалар кысаларында: республиканың Актаныш, Баулы, Нурлат муниципаль районнарында чүп станцияләре, Көнчыгыш полигонының 2 нче картасы һәм Чаллы шәһәрендә каты көнкүреш калдыклары туплау мәйданчыклары файдалануга тапшырылыр дип өметләнәбез.

Уңайлы әйләнә-тирә мохиткә кеше хокукларын яклау максатларында «Халык контроле» системасына гражданнардан «Су» төре буенча керүче белдерүләрне вакытында һәм сыйфатлы башкаруны контрольдә тоту буенча максатчан эш дәвам итте.

Гражданнарның уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукын тормышка ашыру халыкны тиешле күләмдә сыйфатлы эчә торган су белән тәэмин итү бурычларыннан башка мөмкин түгел.

2010 елдан башлап Татарстан Республикасында «Татарстан Республикасы торак пунктларында халыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү» озак сроклы республика программасы тормышка ашырыла. 2022 елда әлеге программа кысаларында 243,3 чакрым сүүткәргеч челтәр, 41 суүткәргеч манара, 43 артезиан скважинасы төзекләндерелде.

2019 елдан республика «Торак һәм шәһәр мохите» милли проектының «Чиста су» федераль проектын гамәлгә ашыруда катнаша, аның кысасында су белән тәэмин итүнең гамәлдәге системаларында су сыйфатын яхшырту буенча чаралар гамәлгә ашырыла.

Бу юнәлештә эш башкарылуга карамастан, әлеге төр буенча 2022 елда мөрәҗәгатьләр саны ике тапкыр диярлек арткан – 585.

Мөрәҗәгатьләрне модерацияләү барышында әлеге төр буенча 2022 елда башкарылган эшкә карамастан, Вәкаләтле вәкил тарафыннан төгәл проблемалар, шул исәптән җаваплы башкаручыларның гаризаларны карау вакытларын сузу һәм аларны тиешенчә карап тикшермәү фактлары ачыкланды.

Әйтик, гражданка А.ның 2022 елның июнендә Казан шәһәренең Чабакса күлендә су тирәнлеге кимү мәсьәләсе буенча шикаяте республиканың 176 кешесе тарафыннан якланды, бу гражданнарның әлеге проблемага битараф булмавын күрсәтте.

Татарстан Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының әлеге шикаятьне карау йомгаклары буенча табигать саклау законнары таләпләрен бозмау турындагы җавабы белән килешмичә, Вәкаләтле вәкил Казан районара табигатьне саклау прокуроры адресына сулыкның саегу факты буенча тикшерү уздыру өчен мөрәҗәгать итте. Безнең тәкъдим буенча оештырылган прокурор тикшерүе «Водоканал» МУПның Татарстан Республикасында балыкчылык буенча федераль агентлыкның территориаль идарәсе белән тиешенчә килештермичә, «Балыкчылык һәм су биологик ресурсларын саклау турында» 20.12.2004 ел, № 166-ФЗ Федераль закон таләпләрен бозып, ремонт эшләре үткәрүен ачыклады һәм «Водоканал» МУП генераль директоры адресына күрсәтмә җибәрде.

«Водоканал» МУП кагыйдә бозуларны бетерү максатларында, бүлеп бирелгән субсидия кысасында, Чабакса авылындагы плотина аша су агып чыкканда су бүлү торбасын әзерләү һәм монтажлау һәм гидротехник корылманың югары бьефын ремонтлау эшләрен башкарды, бу күлдә су дәрәҗәсен күтәрүгә ярдәм итәргә тиеш.

«Халык контроле» системасында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен мониторинглау барышында Азнакай муниципаль районының Якты Юл авылында җәйге чорда су белән тәэмин ителмәү очрагы турында хәбәр иткән гражданка С. шикаяте ачыкланды.

Вәкил мөрәҗәгатен карау нәтиҗәләре буенча Азнакай районы башлыгы адресына әлеге торак пунктны су белән тәэмин итү проблемасын хәл итү кирәклеге турында хат җибәрелде. Җаваплы башкаручылар суүткәргечнең иң проблемалы участогын алыштырдылар, ә алдагы елларда торак пунктта бөтен суүткәргеч системасын ремонтлау планлаштырылган.

2022 елның декабрендә Алабуга муниципаль районының Малореченский бистәсендә яшәүче гражданка А. да су белән тәэмин итмәү турында хәбәр итте. Вәкаләтле вәкилнең Алабуга муниципаль район башлыгы адресына җибәрелгән хатын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча торак пунктта ике көн эчендә су белән тәэмин итү хәл ителде.

Республикада «Чиста су» федераль проектын гамәлгә ашыру республика гражданнары тормышының бу өлкәсендәге киеренкелекне киметер дип ышанам.

Докладта куелган проблемаларны хәл итү буенча уртак эш әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтыны киметергә мөмкинлек бирәчәк.

Бүлек 3. МАХСУС ХӘРБИ ОПЕРАЦИЯ ҺӘМ ӨЛЕШЧӘ МОБИЛИЗАЦИЯ ШАРТЛАРЫНДА ГРАЖДАННАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ

Безнең ил катлаулы геосәяси низагта булган чорда, Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр институты мигрантларның хокукларын яклау өлкәсендә Украинадагы сугыш зонасыннан кешеләрне массакүләм эвакуацияләү шартларында аерым рольгә һәм әһәмияткә ия булды.

2022 елда кеше хокукларын яклау өлкәсендә ике принципиаль яңа юнәлеш формалашты, бу эвакуацияләнгәннәр белән эшләү һәм махсус операциягә бәйле рәвештә Россия Федерациясе гражданнарының хокукларын яклау.

Вәкаләтле вәкил Украинадагы хәрби хәрәкәтләргә бәйле рәвештә Россия территориясенә эвакуацияләнгән гражданнарның хокукларын яклау буенча барлык мәсьәләләргә һәм эш формаларына тулысынча кушылды.

Качакларның күпчелеген өлкән яшьтәге кешеләр, хатын-кызлар һәм балалар тәшкил итә. Татарстан Республикасы территориясенә эвакуацияләнүчеләр 2167 кеше, шуларның 478е – балалар.

Республикада әлеге категория гражданнарын вакытлыча урнаштыру буенча сигез пункт эшли, аларның дүртесе Казанда урнашкан.

Махсус хәрби операция башланганнан бирле пунктларда миграция хезмәте, пенсия фонды, социаль яклау, прокуратура һәм башка белгечләрнең көндәлек кабул итүләре оештырылды.

Гражданнарны эшкә урнаштыру, аларның белемен, һөнәри тәҗрибәсен һәм теләкләрен исәпкә алып вакансияләр сайлау мәсьәләләренә аерым игътибар бирелде. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәҗбүри күчеп килүчеләргә тиешле түләүләрне рәсмиләштерүдә ярдәм оештырды. Мәктәпкәчә, гомуми белем бирү һәм һөнәри белем бирү оешмаларына 411 бала урнаштырылды.

Шул ук вакытта халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан вакытлыча урнаштыру пунктларында эш бирүченең күчмә көннәре оештырылды, анда предприятие вәкилләре белән шәхси әңгәмәдә алар тәкъдим ителгән вакансияләр, хезмәткә түләү системасы һәм социаль гарантияләр буенча тулы мәгълүмат алдылар.

Яңа уку елы алдыннан Вәкаләтле вәкил Луганск һәм Донецк Халык Республикаларыннан һәм Украинадан күченергә мәҗбүр булган күченүчеләрнең балаларын «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит» хәйрия акциясе кысасында аларны кирәкле мәктәп кирәк-яраклары, мәктәп формасы, аяк киеме, канцелярия товарлары белән тәэмин итү мөмкинлеген карау үтенече белән Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарына мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы һәм Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе белән партнерлыкта Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнашу пунктларында яшәүче Донбасстан һәм Украинадан күченергә мәҗбүр булган хатын-кызларга һәрьяклап ярдәм күрсәтү проектын гамәлгә ашыруны хуплады. Проект кысасында консультацияләр, психоэмоциональ ярдәм һәм күнекмәләрне үстерү тренинглары, шулай ук гражданнарның мәдәни программа кысаларында урыннарга чыгу оештырылды.

Вәкаләтле вәкил әлеге категориядәге гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау белән беррәттән, вакытлыча урнаштыру пунктларына да йөрде. Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән берлектә, бердәм түләүсез хокукый ярдәм көнен уздыру кысасында, пунктларда 22 тапкыр гражданнарны кабул итү уздырды.

Кабул итү эше Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек ярдәмчесе тарафыннан да башкарылды. Мөрәҗәгатьләр, нигездә, миграция документларын рәсмиләштерүгә, эшкә урнаштыруга, РФ паспортын алганда дәүләт пошлинасын түләүгә һәм бер тапкыр бирелә торган пособие түләүгә кагылышлы иде. Үз чиратында, гражданнарның республика территориясенә килү шартларын исәпкә алып, гражданнарның финанс мөмкинлеге булмаган очракта өйләренә кайтырга теләүләре турында мөрәҗәгатьләренә аерым игътибар бирелде.

Әйтик, узган елның май аенда элеккеге яшәү урыны территориясенә әйләнеп кайтырга булышуны сорап, Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек ярдәмчесенә Мариуполь шәһәреннән килгән дүрт кешедән торган гаилә мөрәҗәгать итте. Хәйрия оешмалары белән тыгыз элемтәдә гаиләгә юл йөрү билетлары алуда адреслы финанс ярдәме күрсәтелде һәм гражданнар туган шәһәрләренә кайтырга чыктылар.

Гамәлдәге миграция законнары вакытлыча сыену алган затларның вакытлыча яшәү үзәгеннән элекке яшәү урыннарына кайтырга булышу хокукларын күздә тотмый. Россия Эчке эшләр министрлыгының җәмәгатьчелек фикер алышуына чыгарылган «Россия Федерациясе территориясендә сыену урыны бирү турында» федераль закон проекты нигезләмәләре белән әлеге мәсьәләне хәл итү дә чагылдырылмаган.

Моны игътибарга алып, әлеге мәсьәлә Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы эксперт советының халыкара хезмәттәшлек һәм мигрантлар хокукларын яклау мәсьәләләре буенча секциянең узган елның июнендә уздырылган киңәйтелгән утырышы кысасында күтәрелде, аның барышында «Россия Федерациясе территориясендә сыену урыны бирү турында» федераль закон проектына нигезләмәләрдә каралган хокуклар белән беррәттән, сыену урыны алган затка Россия Федерациясеннән чыгу өчен ярдәм алу хокукы кирәклеге дә билгеләнде.

Россия Федерациясе территориясенә ДНР, ЛНР һәм Украинадан килгән гражданнардан Вәкаләтле вәкилгә җибәрелгән күп кенә мөрәҗәгатьләр 9 нчы һәм 11 нче сыйныфларны тәмамлаганнан соң урта һөнәри һәм югары белем бирү оешмаларына балаларны кабул итү мәсьәләсенә кагылды.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: ДНР, ЛНР һәм Украинадан килгән балалар өчен белем бирү оешмаларына кабул итүнең гадиләштерелгән тәртибе булдырылган. «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга белем алуга квота билгеләү турында» 2020 елның 18 декабрендәге 2150 нче Россия Федерациясе хөкүмәте карары нигезендә, әлеге категория өчен урта һөнәри белем, югары белем һәм өстәмә һөнәри белем бирү программалары буенча белем бирү оешмаларына кергәндә квота – 23 мең урын билгеләнгән.

Шуның белән бергә, Россия Федерациясендә урта һөнәри белем бирү программалары буенча гражданнарның күрсәтелгән категориясе өчен федераль бюджет, Россия Федерациясе субъектлары һәм җирле бюджетлар бюджет ассигнованиеләре исәбеннән финанслана торган урыннарга кабул итү «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 нче федераль закон нигезендә гомуми һәркем алырлык һәм түләүсез гарантияләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

Бәян ителгәннәрдән чыгып һәм алардан бәйсез сәбәпләр аркасында ДНР, ЛНР һәм Украина балаларының укудан мәхрүм ителүләрен исәпкә алып, узган елның июлендә Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына Вәкаләтле вәкил тарафыннан Россия Федерациясе хөкүмәтенә ДНР, ЛНР һәм Украина балаларына федераль бюджетның бюджет ассигнованиеләре хисабына урта һөнәри белем бирү программалары буенча укыганда махсус ташлама бирү турында мөрәҗәгать итү мөмкинлеген карау үтенече белән хат җибәрелде.

Мобилизация чаралары уздырылганда чакырылучы затларда Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 нче указын гамәлгә ашыру тәртибенә бәйле күп сораулар туды.

Төбәк белән идарә итү үзәге рәисе һәм «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасының баш модераторы буларак, Вәкаләтле вәкил гражданнарның дәүләт

хакимияте органнарына кергән мөрәҗәгатьләрен һәм хәбәрләрен гомумиләштерде.

Республиканың Вәкаләтле вәкиленә мобилизация мәсьәләләре буенча 4087 мөрәҗәгать һәм хәбәр керде, шул исәптән «Дәүләт хезмәтләре. Бергәләп хәл итәбез» Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталының кире элемтә платформасы» аша «Халык контроле» дәүләт мәгълүмати системасына 2287 хәбәр керде.

2022 елның 5 октябреннән «Халык контроле» системасында 10 тематик категорияне үз эченә алган «өлешчә мобилизация» дигән яңа юнәлеш эшли башлады.

Өлешчә мобилизация мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләргә һәм хәбәрләргә җаваплар 24 сәгать эчендә, Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты, Татарстан Республикасы чакырылыш комиссиясе, Казан гарнизоны Хәрби прокуратурасы, Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары белән тыгыз элемтәдә торганда, шулай ук кирәк булганда – өлешчә мобилизацияләү процессында катнашучы башка дәүләт органнары һәм оешмалар белән тыгыз бәйләнештә булган очракта бирелде.

Әйтик, узган елның октябрендә Вәкаләтле вәкил адресына Түбән Кама шәһәрендә яшәүче граждан М., мобилизация кысасында хәрби хезмәткә чакырылган 1 төркем инвалид улы мәнфәгатьләрен яклап мөрәҗәгать итте. Ул улының аны тәрбияләүче һәм булышчы бердәнбер якыны булуын күрсәтте. Татарстан Республикасы Прокуратурасы органнары һәм хәрби комиссариаты белән үзара хезмәттәшлектә, мобилизациягә алынган кеше өенә кире кайтарылды. Ләкин моңа ирешү өчен беркадәр вакыт кирәк булды.

Вәкаләтле вәкил шулай ук судта мобилизацияләү буенча чакырылыш комиссиясе карарлары белән килешмәгән гражданнар тарафыннан бирелгән 7 административ дәгъва гаризасын карау барышында кызыксынулы зат сыйфатында җәлеп ителде. Аларның һәрберсе буенча эш позициясен бәян итеп, бәяләмәләр әзерләнде.

Эш махсус хәрби операциядә катнашучыларның һәм аларның гаилә әгъзаларының язмача мөрәҗәгатьләрен һәм хәбәрләрен карау белән генә чикләнмәде. Мобилизацияләнгән кешеләр оператив һәм кирәкле юридик ярдәмне урнаштыру пунктларында турыдан-туры алсын өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы оештырган мобиль мәгълүмат-консультация төркеме төзелде, аның эшендә Вәкаләтле вәкил һәм Аппарат хезмәткәрләре катнашты. Төркем эшләгән чорда 4300дән артык граждан хокукый ярдәм сорап мөрәҗәгать итте.

Ирләре мобилизацияләнгән, инвалид балалар тәрбияләүче гражданнар мөрәҗәгатенә аерым игътибар бирелде. Балачактан инвалид яки инвалид баласы булган гаиләләрдә ана күбесенчә тәрбияләү белән мәшгуль, ә ата кеше бала һәм гаилә ихтыяҗларын тәэмин итеп кенә калмый, ә физик ярдәм дә күрсәтә. Аларның туганнарына кирәкле ярдәм күрсәтү максатыннан, без кергән мөрәҗәгатьләрне карау кысасында республиканың профильле министрлыкларына һәм ведомстволарына мөрәҗәгать иттек, муниципаль берәмлекләр хакимиятләре башлыкларының аерым игътибарын авыр хәлдә, аеруча матди яктан авыр хәлдә калган гаиләләрнең көндәлек ихтыяҗларына юнәлттек.

Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәттән 16 яшькә кадәрге өч баласы булган күпбалалы аталарны мобилизацияләүне кичектерүне тәэмин итү буенча киң колачлы эш Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары белән берлектә уздырылды.

Узган елның октябрендә мобилизацияләнүчеләрне урнаштыру үзәкләренә күп тапкыр чыгу оештырылды; әлеге категория гражданнарының статусын раслаучы рапортлары җыелды һәм системалаштырылды; Татарстан Республикасы чакырылыш комиссиясенә соңыннан кичектерелгән затлар исемлеге әзерләнде һәм җибәрелде. Татарстан Республикасыннан 200гә якын күпбалалы әти туганнары һәм якыннары янына әйләнеп кайтты.

Республика оешмаларында хезмәт эшчәнлеген башкаручы мобилизацияләнгән гражданнарның туганнарыннан кергән мөрәҗәгатьләр Вәкаләтле вәкилнең аерым игътибарына лаек булды.

Бу мәсьәләдә, бер яктан, эш бирүчеләрнең үзләре, икенче яктан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре запастагы гражданнарны хәрби исәпкә алуны һәм бронь бирүне гамәлгә ашыру оешмаларында үз вакытында тикшерүләр уздыру буенча хәрби комиссариатларның әзер булмавы билгеләп үтелде.

Казан шәһәренең Идел буе һәм Вахитов районнары хәрби комиссариатының вазыйфаи затларын җәлеп итеп, гражданка Л.ның Казан шәһәренең муниципаль унитар предприятиеләренең берсенә эшкә урнашкан запаста булган, вазыйфасы буенча мобилизация һәм сугыш вакытында бронь бирелергә тиешле ире мәнфәгатьләрен яклаган мөрәҗәгате буенча инициативалы тикшерү нәтиҗәсендә Вәкаләтле вәкил әлеге оешма җитәкчелеге тарафыннан аларның хезмәткәрен мобилизациягә кадәр броньлау мөмкинлеге булу турында нәтиҗә ясады, Казан шәһәренең Идел буе һәм Вахитов районнары хәрби комиссары адресына әлеге факт буенча тикшерү уздыру турында мөрәҗәгать итте (доклад әзерләнгән вакытта хат карала иде).

Татарстан Республикасының Балык Бистәсе һәм Кукмара муниципаль районнарында яшәүче, өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган дәүләт һәм дәүләткә булмаган мәгариф оешмалары студентларының мөрәҗәгатьләре Вәкаләтле вәкилдә нигезле борчу тудырды.

Шулай итеп, 2022 елның сентябрендә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган, дәүләт аккредитациясе булган мәгариф оешмасында беренче тапкыр көндезге бүлектә белем алучы 1 курс студентының әнисе мөрәҗәгатен карау кысасында, Татарстан Республикасы Хәрби комиссары адресына Вәкаләтле вәкил мөрәҗәгать итүе улының белем алуга карата бозылган хокукларын торгызу һәм муниципаль район хәрби комиссариатының аны хәрби хезмәткә чакыру хакында карарын кире кагу турында иде. Аларны карау нәтиҗәләре буенча, мөрәҗәгать итүченең улына мобилизация буенча хәрби хезмәттән кичектерү бирелде.

Ачыкланган моментлар булган проблемалы мәсьәләләрне күрергә һәм чакырылыш комиссияләренең эшен заманча чынбарлыкка карата оештыру зарурлыгы турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирде. Хәзерге тормыш сыйфатын, хәзерге цифрлы технологияләр, сервисларны һәм хезмәтләрне нәтиҗәле үстерү шартларында «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53 нче федераль законның 10 маддәсендә беркетелгән үз бурычларын үтәмәгән гражданнарга карата законнарны катгыйландыру ягыннан чыгу юлы түгел, узган елның ноябрендә үткәрелгән миграция өлкәсендә кеше хокукларын яклау, шулай ук махсус хәрби операция һәм өлешчә мобилизация шартларында гражданнар хокукларын саклау мәсьәләләрендә омбудсменнарның роленә багышланган Бөтенроссия координация советы утырышында Вәкаләтле вәкил тарафыннан автоматлаштырылган системаны актуальләштерү юлы белән хәрби комиссариатларның цифрлы трансформациясе буенча тәкъдимнәр әйтелде, шул исәптән чакыру кәгазьләре тапшыру. Моңа кайбер дәүләт органнары, шул исәптән граждан тарафыннан Россия Федерациясе дәүләт хезмәтләренең бердәм порталы мөмкинлеген файдаланып, ведомствоара хезмәттәшлек юлы белән мәгълүмат алу кирәклеге керә.

Күп кенә мөрәҗәгатьләр мобилизацияләнгән гражданнарга тиешле күләмдә акча түләнмәү мәсьәләләренә кагылды. «Дәүләт хезмәтләре. Бергәләп хәл итәбез» Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы һәм «Халык контроле» мәгълүмат системасына әлеге категориядәге 938 мөрәҗәгать керде. Вәкаләтле вәкил Аппаратына турыдан-туры – 157. Барлык мөрәҗәгатьләр дә оператив тәртиптә Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты һәм Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Жуков орденлы Кызыл байраклы Казан югары танк команда училищесы белән берлектә каралды.

Мобилизацияләнгән кешеләрдән һәм аларның туганнарыннан Вәкаләтле вәкилгә килгән мөрәҗәгатьләрнең аерым категориясен мобилизацияләнгән гражданнарның сәламәтлеге торышына һәм хәрби табиб комиссиясе тарафыннан медицина тикшерүе үткәрүгә кагылышлы сораулар буенча шикаятьләр тәшкил итте.

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты хезмәткәрләре белән берлектә хәрби хезмәткәрләрнең хәрби хезмәткә яраклылыгын медицина тикшерүе мәсьәләләре буенча хәрби табиб комиссиясе уртак тикшерүләрендә катнаштылар, гражданнарга тикшерү нәтиҗәләре буенча тиешле яраклылык категорияләре билгеләнде.

Мобилизацияләү пунктларында аларның һәм аларның туганнары кабул итү барышында кайбер фактлар буенча безнең турыдан-туры катнашу кирәклеген ачыкладык.

Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткән мобилизацияләнгән кешеләрнең туганнары хәрби хезмәткәрләрнең сәламәтлеге торышына борчылуларын белдерде, чөнки аларда булган эчке әгъзалар яки әгъзалар системасы авырулары хәрби хәрәкәтләрдә тулысынча катнашырга мөмкинлек бирми. Хәрби хезмәткәрләрнең кайбер авыруларын (мәсәлән, инсулинга бәйле диабет, псориаз һәм башкалар) нәтиҗәләре (аларга «В» категориясе билгеләнгән – хәрби хезмәткә өлешчә яраклы), авыру дәрәҗәләре буенча хәрби хезмәт узу мөмкинлеге чикләнгән, әмма шуның белән бергә аны тулысынча кире какмаган.

Хәрби хезмәткәрләрдә булган авыруларның организм функцияләрен бозуына китерүен һәм хәрби хәрәкәтләрдә тулысынча катнашырга мөмкинлек бирмәвен исәпкә алып, без, Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына «В» категориясендә (хәрби хезмәткә өлешчә яраклы) һәм хәрби хезмәткәрләрне, Россия Федерациясе Коралды Көчләренең тылдагы бүлекчәләрендә хәрби хезмәт узарга рөхсәт бирү тәкъдиме белән Россия Федерациясе Оборона министрлыгына мөрәҗәгать итүне сорап, хат җибәрдек.

Гражданнарны мобилизация буенча Россия Федерациясе Коралды Көчләренә хәрби хезмәткә чакыру хәрби хезмәткә чакырылучының гына түгел, ә бөтен гаиләсенең тормыш рәвешен үзгәртте.

Россия Федерациясенең барлык субъектларында күрелгән мобилизацияләнгән гражданнар гаиләләренә ярдәм итү чаралары, беренче чиратта, балигъ булмаган балалары булган гаиләләргә ярдәм итүгә – гомуми белем мәктәпләрендә түләүсез туклану белән тәэмин итүгә, балалар бакчаларына йөрү өчен түләүне алып ташлауга, бер тапкыр бирелә торган түләүләр бирүгә, транспортта түләүсез йөрүне һәм башка әһәмиятле чараларны билгеләүгә юнәлдерелгән иде.

Моңа кадәр мобилизацияләнгән ир белән хатын башкарган күп кенә гаилә бурычларының, шул исәптән югары һәм урта һөнәри белем бирү оешмаларында коммерция нигезендә белем алучы студентлар өчен финанс йөкләмәләре дә хатынның һәм туганнары җилкәсенә төшүе Вәкаләтле вәкилне нигезле борчыды. Украинада өлешчә мобилизацияләү кысасында хәрби хезмәткә чакырылган затларның һәм махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларына белем бирү преференцияләрен билгеләү мәсьәләсе буенча Вәкаләтле вәкилнең мөрәҗәгате Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан хупланды һәм компетентлы органнар һәм фәнни җәмәгатьчелек белән өстәмә эшләү өчен җибәрелде.

Мобилизацияләнгән гражданнарның һәм аларның гаилә әгъзаларының мөрәҗәгатьләре белән эшләгәндә, аларның күпчелеге хокукый белемнәре булмауга бәйле булуын исәпкә алып, закон чыгару инициативасы субъектларының берсе буларак, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Дәүләт Советына «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 нче маддәсенең 1 өлешенә Россия Федерациясе Коралды Көчләрендә хәрби мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Херсон һәм Запорожье өлкәләре территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашу шартларында ирекле оешмалары (Россия Федерациясе Коралды көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм күрсәтү турында) катнашу турында контракт төзегән гражданнар, шулай ук аларның гаилә әгъзаларының бушлай юридик ярдәм алуга хокуклары закон дәрәҗәсендә беркетергә мөмкинлек бирүче үзгәрешләр кертү турында закон проекты кертелде.

2022 елның декабрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында Вәкаләтле вәкил инициативасы парламент депутатлары тарафыннан хупланды. Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 26 декабрендәге 102-ТРЗ Татарстан Республикасы Законына кул куелды.

Бүлек 4. МӘҖБҮРИ ТОТУ УРЫННАРЫНДА КЕШЕ ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ

4.1. ҖИНАЯТЬ-БАШКАРУ СИСТЕМАСЫ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ КЕШЕ ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ

Кешелекле мөгамәлә һәм шәхес абруен хөрмәт итү хокукы халыкара һәм илкүләм законнар нормаларында каралган.

2022 елда пенитенциар системасы учреждениеләре эшчәнлеге контрольдә тотылды, сак астында тотылган, ирекләр мәхрүм итү яки мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәүче шикләнелүчеләр һәм гаепләнүчеләрнең, җинаять-суд эшчәнлеге тәртибендә медицина характерындагы мәҗбүри чаралар кулланылган гражданнарның, административ арест рәвешендә җәза билгеләнгән затларның хокукларын яклауны тикшереп тору эше дәвам иттерелде.

Узган ел Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты җинаять-башкару системасы учреждениеләрендә булган затлардан барлыгы 344 мөрәҗәгать керде.

Шикаятьләрне карап тикшерүдән тыш, узган елда хөкем ителүчеләргә җәзаларны үтәү мәсьәләләре буенча хокукый ярдәм күрсәтү кысаларында, Россия Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе әгъзалары белән төзәтү учреждениеләрендә җәзаларны үтәү мәсьәләләре буенча видеоконференц-элемтә режимында кабул итү эше дәвам итте.

Хисап елында Хокукый ярдәм көннәре кысасында 10 уртак тематик кабул итү уздырылды.

Аерым проблемалы мәсьәләләрне хәл итү максатларында Вәкаләтле вәкил прокуратура органнары, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Россия Җәзаларны үтәтү хезмәтенең 16 нчы медицина часте, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек киңәшмәләр уздырды.

Мәсәлән, коллегиаль форматта, шул исәптән Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Экспертлар советында җинаять-башкару системасы учреждениеләрендә шикләнелүчеләрнең, гаепләнүчеләрнең һәм хөкем ителгән затларның хокукларын үтәүгә, аларга, шул исәптән тикшерү изоляторларында сак астында булган балигъ булмаган затларга, шулай ук сак астында булган балигъ булмаган затлар төп гомуми һәм урта гомуми белем алсын өчен шартлар тудыруга бәйле мәсьәләләр каралды.

Җинаять-башкару системасы учреждениеләрендә медицина тәэминаты мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр Вәкаләтле вәкил адресына килгән мөрәҗәгатьләрнең шактый өлешен тәшкил итә.

Әлеге тематика буенча Вәкаләтле вәкил адресына барлыгы 78 мөрәҗәгать керде. Мөрәҗәгать итүчеләр дәвалау тактикасы белән килешмәүләрен белдерделәр, ведомстводан тыш сәламәтлек саклау учреждениеләрендә тикшерү һәм дәвалану узуда, махсуслаштырылган һәм югары технологияле медицина ярдәме алуда ярдәм итүләрен сорадылар.

Иң еш очрый торган авыруларны профилактикалау, диагностикалау, дәвалау һәм реабилитацияләүнең заманча ысулларын гамәлгә кертү ярдәмендә төзәтү учреждениеләрендә ВИЧ-инфекция авырулары һәм актив туберкулез белән беренчел авырулар санының кимүе тенденциясен танырга кирәк. Җинаять-башкару системасы учреждениеләрендә хөкем ителүчеләр, шикләнелүчеләр һәм гаепләнүчеләрнең йогышлы чирләр (туберкулез, ВИЧ-инфекция) белән авыруы кими.

Шуның белән бергә, хөкем ителгәннәрне һәм сак астындагы затларны медицина ярдәме белән тәэмин итүне камилләштерү, хөкем ителүчеләрнең һәм сак астындагы затларның, тоткарланмыйча сәламәтлек саклау муниципаль системасы һәм дәүләт сәламәтлек саклау системасы медицина оешмалары табиб-белгечләр консультацияләрен алуга гарантияләнгән хокукын гамәлгә ашыруны тәэмин итүне күздә тота. Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматлары буенча 2022 елның 1 декабренә Татарстанның төзәтү учреждениеләрендә һәм тикшерү изоляторларында булган затларның гомуми саны 8175 кеше тәшкил иткән. Шулардан ел дәвамында Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тикшерү изоляторларында уртача 30га якын балигъ булмаган шикләнүче һәм гаепләнүче булырга мөмкин.

Балигъ булмаган затларны медицина белән тәэмин итү Россия Җәзаларны үтәтү хезмәтенең 16 нчы медицина часте филиалларының медицина белгечләре тарафыннан башкарыла, ә кирәк булганда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау учреждениеләре белән төзелгән дәүләт контрактлары кысаларында күрсәтелә.

Узган елның мартында Вәкаләтле вәкил тарафыннан «Җинаять-башкару системасы учреждениеләрендә шикләнелүчеләрнең, гаепләнүчеләрнең һәм хөкем ителүчеләрнең, шул исәптән балигъ булмаганнарның хокукларын үтәү» темасына прокуратура, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе һәм җәмәгатьчелек вәкилләре катнашында берничә чара оештырылды.

Аларны үткәрү алдыннан республика территориясендә урнашкан тикшерү изоляторларында балигъ булмаган затларны медицина белән тәэмин итүне оештыру, Аппарат хезмәткәрләре һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе әгъзалары белән берлектә тикшерелде.

Чарада кабул ителгән резолюция нәтиҗәләре буенча, Казан шәһәре тикшерү изоляторларының берсендә сак астында булган балигъ булмаган затларга медицина ярдәме күрсәтү өчен шартнамә төзү кирәклеге турындагы тәкъдим Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан исәпкә алынды.

Узган ел дәвамында Вәкаләтле вәкил тарафыннан инвалид хөкем ителүчеләрне җәмгыять тормышында катнашу өчен башка хөкем ителүчеләр белән тигез мөмкинлекләр булдыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар күрелде.

Россия Җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматы буенча, 2022 елның 1 декабренә җинаять-башкару системасы учреждениеләрендә 1, 2, 3 нче төркем инвалид булган шикләнелүчеләр, гаепләнүчеләр һәм хөкем ителгәннәр саны 260 (2021 ел – 238 кеше) тәшкил иткән.

Шуңа бәйле рәвештә Вәкаләтле вәкил шикләнелүчеләрне, гаепләнүчеләрне һәм хөкем ителүчеләрне җинаять-башкару системасы учреждениеләрендә тоту тәртибен һәм шартларын тәэмин итүне, шулай ук аларның матди-көнкүреш тәэминаты дәрәҗәсен күтәрүне, шул исәптән шикләнелүчеләр, гаепләнүчеләр һәм хөкем ителүчеләр арасыннан инвалидлар өчен уңайлы мохит булдыруны мониторинглауны дәвам иттерде.

Аларда хөкем ителүче инвалидлар өчен киртәләрсез мохит булдыру буенча хәлне анализлау барышында Россия Җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 4 нче төзәтү колониясендә статодинамик (хәрәкәт) функциясен бозып, хәрәкәт итүләре чикләнгән аз хәрәкәтле тоткыннар өчен гомуми инфраструктура (медицина өлеше, ашханә) мөмкин булмау фактлары билгеләнде.

Хөкем ителгән инвалидлар яши торган бүлмәләргә керү һәм аларда матди-көнкүреш шартлары да җайлаштырылмаган һәм инвалид коляскалары белән йөрү өчен юл да юк.

Ачыкланган хокук бозулар нәтиҗәләре буенча Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы адресына хөкем ителгән инвалидлар өчен, күрсәтелгән төзәтү колониясендә уңайлы мохит булдыруга юнәлдерелгән чаралар күрү зарурлыгы турында хат юлланды (доклад язган вакытта Вәкаләтле вәкилнең хаты карауда иде).

Тормышның барлык өлкәләрендә инвалидлар өчен тигез мөмкинлекләр булдыру зарурлыгын исәпкә алып, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә киләчәктә республика территориясендә пенитенциар учреждениеләр челтәрен оптимальләштерү буенча чаралар үткәргәндә, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затларның да, учреждениеләрдәге өлкән яшьтәге затларның ихтыяҗларын һәм физик торышын исәпкә алып, торак биналар һәм бәдрәф бүлмәләре белән файдалану мөмкинлеген тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

Әлеге сегментта Вәкаләтле вәкилнең аерым игътибарын хөкем ителүчеләрнең җәза үтәү шартлары белән канәгать булмавы җәлеп итә.

Вәкаләтле вәкилнең Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе әгъзалары белән берлектә мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокукларын тәэмин итүгә карата планлы рәвештә булуы барышында, хөкем ителүчеләр, көндез алар җәза үтәүнең катгый шартлары отрядында булган бинада санитар-техник җайланмалар булмаудан зарландылар.

Вәкаләтле вәкилнең Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгате нәтиҗәсендә көндезге бүлмә санитар узел һәм сулы раковина белән җиһазландырылган.

Россия Юстиция министрлыгының төзәтү учреждениеләренең эчке тәртибе кагыйдәләре 2022 елның 4 июлендәге 110 нчы боерыгы белән раслануга бәйле рәвештә, хөкем ителгәннәргә төзәтү учреждениесендә озак вакытлы күрешү бирелгәндә, күрешүгә килгән кешегә рөхсәт ителгән әйберләрнең һәм азык-төлек продуктларының максималь авырлыгы мәсьәләләре буенча ирektән мәхрүм ителгән затларның якын туганнарыннан мөрәҗәгатьләр килү артты.

Шундый хәл туды. Кагыйдәләрнең 235 нче пункты шуны күздә тота: очрашуга килгән кеше китерә торган әйберләрнең һәм азык-төлек продуктларының авырлыгы бер тапшыру өчен билгеләнгән максималь рөхсәт ителгән авырлыктан артмаска тиеш. РФ УИК 90 нчы маддәсенең 1 өлеше нигезендә бер тапшырган әйбернең яки посылканың максималь авырлыгы 20 килограммнан артмаска тиеш. Шундый ук нормалар кагыйдәнең 103 нче пункты белән беркетелгән. Шул ук вакытта әлеге авырлыкка азык-төлек, балалар ризыгы (кече яшьтәге балалар белән килгән очракта) шешәле су, шәхси әйберләр һәм гигиена чаралары, шулай ук урын-җир әйберләре керә. Шул ук вакытта төзәтү учреждениеләре хакимиятләре тарафыннан бер тапшыру өчен билгеләнгән максималь рөхсәт ителгән авырлык хөкем ителгән затлар белән очрашуга килгән кешеләрнең гомуми санына карап аңлатыла.

Әлеге алым белән ризалашмыйча, без Россия Федерациясе Юстиция министры адресына төзәтү учреждениесе территориясендә озак вакытлы күрешүгә килгән һәр кеше (шул исәптән балигъ булмаган бала) өчен алып керә торган әйберләрнең һәм ризыкларның максималь рөхсәт ителгән авырлыгын билгеләү өлешендә кагыйдәләрнең 103 нче, 235 нче пунктлары нигезләмәләрен аңлатуны сорап, хат юлладык. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: бер тапшыруның максималь рөхсәт ителгән авырлыгы 20 килограммнан да артмавы озак вакытлы күрешүгә килгән һәр кеше өчен билгеләнгән.

Вәкаләтле вәкил хөкем ителүчеләрнең язма мөрәҗәгатьләрен караганда, шулай ук төзәтү учреждениеләрендә булганда, ирektән мәхрүм итү урыныннан азат ителгәч аларга дәүләт тарафыннан ярдәм булмавына борчылуларын белде. Әлеге борчылуны үз чиратында Россия Федерациясендә дә, башка дәүләттә дә яшәүгә рөхсәт документлары булмаган, гражданлыгы теркәлмәгән затлар белдерә.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматлары буенча республиканың төзәтү учреждениеләрендә гражданлыгы булмаган 47 зат җәза үти.

Хөкем ителүчеләрне уңышлы тормышка яраклаштыруның мөһим шарты булып, җәза үтәүче затларга, шул исәптән гражданлыгы булмаган затларга документ бирү буенча Россия Җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең махсус учреждениеләре тарафыннан алып барыла торган эш тора.

2021 елның 24 августыннан үз көченә кергән «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы федераль законга үзгәрешләрдә, гражданлыгы булмаган затның шәхесен билгеләү процедурасын үткәргәннән соң 10 ел гамәлдә булу срогы белән вакытлыча документ бирү каралган.

Вакытлы таныклык алу, гражданлыгы булмаган затка аны азат иткәндә депортацияләү турындагы карарны гамәлдән чыгарырга һәм хезмәт эшчәнлеген патент яки эшкә рөхсәт алмыйча башкарырга, шулай ук квотасыз вакытлыча яшәүгә рөхсәт рәсмиләштерү һәм киләчәктә Россия Федерациясе гражданлыгы һәм яшәү төре алуга хокуклы булырга мөмкинлек бирәчәк.

Әлеге хәлне исәпкә алып, ел дәвамында Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре Вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек ярдәмчесе белән берлектә төзәтү учреждениеләрендә булганда, хөкем ителгән гражданлыгы булмаган затлар арасында вакытлы таныклык алу кирәклеген аңлату эшен алып барды.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматы буенча, республика төзәтү учреждениеләрендә җәза үтүче һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль бүлекчәләренә гаризалар белән мөрәҗәгать итүче 27 гражданга карата уртак эш нәтиҗәсендә шәхесне билгеләү процедурасы үткәрелә. Гражданлыгы булмаган өч затка Россия Федерациясендә гражданлыгы булмаган затның вакытлы таныклыгы бирелгән. Бу эш 2023 елда да дәвам итәчәк.

4.2. ГРАЖДАННАРНЫҢ КЫСКА ВАКЫТЛЫ МӘҖБҮРИ ТОТУ УРЫННАРЫНДА КЕШЕ ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ

Гражданны кыска сроклы тоткарлау яки җәзаларны үтәү стадиясендә закон таләпләрен үтәү мәҗбүри тоту урыннарындагы затларның конституциячел һәм башка хокукларын яклау функциясенең төп өлешләренең берсе буларак карала.

Үз чиратында, мәҗбүри тоту урыннарында торучы затларның гамәлдәге законнар белән беркетелгән, гигиена, санитария һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләренә җавап бирә торган көнкүреш шартлары тудыруга хокукларын үтәү, кешенең кыска вакытлы тору урыннарында сәламәтлеген саклап калу һәм нормаль яшәвен тәэмин итү максатыннан башкарыла.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматлары буенча, Татарстан Республикасы Эчке эшләр органнарында 2022 елда шикләнелүчеләрне һәм гаепләнүчеләрне вакытлыча тотуның 40 изоляторы, административ тәртиптә кулга алынган затларны тоту өчен 13 махсус кабул итү урыны, административ тәртиптә тоткарланган затлар өчен 201 бина һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының Чаллы шәһәре буенча идарәсенең чит ил гражданнарын вакытлыча тоту үзәге эшләде. Аларда тотылган гражданнарның гомуми саны 2022 елның 11 аенда 127981 тәшкил итте.

2022 елда федераль бюджеттан бүлеп бирелгән ассигнованиеләр кысаларында Россия Эчке эшләр министрлыгының Зәй районы буенча эчке эшләр бүлеге бинасын, вакытлыча тоту изоляторын төзекләндерү төгәлләнде. Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча бүлегенең махсус кабул итү бүлмәсе, Россия Эчке эшләр министрлыгының Яшел Үзән районы бүлегендә вакытлыча тоту изоляторы, махсус кабул итү бүлмәсе ремонтланды. Россия Эчке эшләр министрлыгының Лениногорск һәм Минзәлә районнары буенча бүлекләрендә вакытлыча тоту изоляторында шлюзлар төзелде. Төбәк бюджетыннан бүлеп бирелгән ассигнованиеләр кысаларында Россия Эчке эшләр министрлыгының Нурлат районы буенча бүлегенең вакытлыча тоту изоляторына капиталь ремонт ясалды.

Вакытлыча тоту урыннарында матди-көнкүреш шартларын яхшырту өлешендә тоту шартлары үзгәрүгә карамастан, Вәкаләтле вәкилгә әлеге учреждениеләрдәге затлардан 18 мөрәҗәгать керде. Вакытлыча тоту урыннарындагы гражданнар мөрәҗәгать иткән сораулар спектры киң. Мөрәҗәгатьләрнең темалары төрле сорауларга — тоту шартларына карата шикаятьләрдән, бердәм тукլануга кагылышлы шикаятьләрдән алып азат итүдә булышуны сораган мөрәҗәгатьләргә кадәр кагылды.

Узган елда Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре тарафыннан Россия Эчке эшләр министрлыгының республика районнарындагы вакытлыча тоту изоляторларында, махсус кабул итү бүлмәләрендә һәм административ тәртиптә тоткарланган өчен биналарда көнкүреш шартларын тикшерү эше дәвам ителде.

Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәре, Татарстан Республикасы Иҗтимагый күзәтү комиссиясе әгъзалары белән берлектә, тоту шартларын тикшерү максатыннан, Россия Эчке эшләр министрлыгының Югары Ослан муниципальара бүлегенә, Россия Эчке эшләр министрлыгының Балык Бистәсе районы буенча бүлегенә, Россия Эчке эшләр министрлыгының Әлмәт районы буенча бүлегенә, Россия Эчке эшләр министрлыгының Яшел Үзән районы буенча бүлегенә, Россия Эчке эшләр министрлыгының Алабуга районы буенча бүлегенә, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенең административ арестка дучар ителгән затларын тоту өчен махсус кабул итү бүлмәсенә, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенең 3 нче «Зареченский», 16 нчы «Япеев», 17 нче «Ямашев», 1 нче «Авиатөзелеш», 11 нче «Восход», 13 нче «Азино-2», Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенең 15 нче «Танкодром» полиция бүлекләрендә булды.

Административ тәртиптә кулга алынган затларны, гаепләнүчеләрне тоту өчен махсус кабул итү бүлмәләрен һәм вакытлыча тоту изоляторы камераларын тикшерү барышында, Россия Эчке эшләр министрлыгының Әлмәт районы бүлегенең эчәргә яраклы су баклары булмау рәвешендә монда тотылучыларның матди-көнкүреш тәэмин ителешенә хокукын бозу очраклары ачыкланды. Моннан тыш, шикләнелүчеләрне һәм гаепләнүчеләрне вакытлыча тоту изоляторы камераларында булган вентиляция кирәкле һава алмашын, шулай ук нәтиҗәле һава алмашын тәэмин итмәде, бу бөркүлек тудырды. Тикшерү нәтиҗәләре буенча кирәкле чаралар күрүне сорап, Вәкаләтле вәкил тәкъдимнәрен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрына җибәрде. Аларны карап кимчелекләрне бетерү буенча эш башкарылды. Күрсәтелгән учреждениеләрнең эчәргә яраклы су савытлары булмауга бәйле җитешсезлекләре бетерелде.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматы буенча, шикләнелүчеләрне һәм гаепләнүчеләрне вакытлыча тоту камераларында тиешле һава алмашы булдыру өчен мәҗбүри суырту вентиляциясе өстәмә системасын кую планлаштырылган һәм электрон торглар үткәрү, тиешле контракт төзү буенча эш алып барыла.

Россия эчке эшләр министрлыгының Алабуга һәм Яшел Үзән районнары буенча бүлекләрен тикшерү барышында эчәргә яраклы су өчен савытлар булмау ачыкланды.

Эчке эшләр министрлыгының Алабуга районы буенча бүлегенең административ тәртибендә кулга алынган затларны тоту өчен махсус кабул итү бүлмәләрендә юыну бүлмәсенә кайнар су кертелмәгән.

Эчке эшләр министрлыгының Алабуга районы буенча бүлегенең мәҗбүри тоту урыннарындагы затларның көндез һава суларга чыгуын оештыру, ишегалларында кар күп булу һәм аның территориясенә керүне кыенлаштыручы башка предметлар тору сәбәпле тиешенчә булмаган.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы Вәкаләтле вәкилнең Россия Эчке эшләр министрлыгының Алабуга һәм Яшел Үзән буенча бүлекләрендә ачыкланган кимчелекләрне карау нәтиҗәләре буенча, камераларда эчәргә яраклы су баклары булмауга бәйле җитешсезлекләр бетерелде.

Эчке эшләр министрлыгының Алабуга районы буенча бүлегендә һава сулый торган ишегалларын чистарттылар, ә гаепләнүчеләр һәм административ арестка алынган затларның саф һавага чыгуы федераль законнар һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының норматив документлары таләпләре нигезендә оештырылды. Үз чиратында Россия Эчке эшләр министрлыгының Алабуга районы буенча бүлегенең махсус кабул итү бүлмәсе камераларын кайнар су белән тәэмин итү капиталь ремонт кысаларында планлаштырылган.

РФ Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенең 16 нчы «Япеев» һәм 17 нче «Ямашев» полиция бүлекләренә чыгу нәтиҗәләре буенча, гражданнар Х. белән С.ның көнкүреш шартлары канәгатьләнерлек түгел, дигән шикаятьләрен карау барышында 16 нчы «Япеев» полиция бүлегенең тоткарланган затлары өчен махсус биналарда өслекләрнең пычрануы фактлары ачыкланды. Россия Эчке эшләр министрлыгы Казан шәһәре буенча идарәсе комплекслы җыештыру буенча дәүләт контракты төзегән булса да, мондый хәлләр оешманың җыештыруны даими башкармавы аркасында килеп чыккан дип уйлап, Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры адресына бүлек биналарын тиешенчә җыештыру буенча кичекмәстән чаралар күрү турында хат юллады.

Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе җитәкчелеге, Вәкаләтле вәкилнең хатын карау барышында, полиция бүлекләрендә биналарны җыештыручы оешмага аны җентекләп уздыру кирәклеге турында мәгълүмат җиткерде. Шуңа бәйле рәвештә, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе җитәкчелегенең полиция бүлекләре биналарын җыештыруга төзелгән контракт кысаларында, оешмаларның үз өсләренә алган йөкләмәләрне үтәвен тиешле контрольдә тотуны тәэмин итүгә игътибар итәргә кирәк, дип саныйбыз.

Илебез катлаулы геосәяси низаг эчендә булган вазгыятьтә Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча идарәсенең чит ил гражданнарын вакытлыча тоту үзәгендә гражданлыгы булмаган затларны һәм чит ил гражданнарын озак вакытлы тоту мәсьәләләре дә игътибарсыз калдырылмады.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматы буенча, 2022 елда Россия Эчке эшләр министрлыгының Чаллы шәһәре буенча идарәсенең вакытлыча тоту үзәгенә урнаштырылган затларның гомуми саны 809 тәшкил иткән. Үзәктә булган булган затлар турында 52 мөрәҗәгать (2021 ел – 47, 2020 ел – 88) булды.

Бу уңайдан вакытлыча тоту үзәгендә булган затларны видеоконференц-элемтә режимында чит ил гражданнарының һәм гражданлыгы булмаган затларның хокукларын саклау мәсьәләләре буенча кабул итү практикасы дәвам итте. Хисап елында әлеге форматта 4 кабул итү уздырылды, аларда 36 чит ил кешесе һәм гражданлыгы булмаган затлар кабул ителде.

Шул ук вакытта мөрәҗәгатьләрнең шактый өлешен, илдән административ чыгару турындагы карарны үтәүне тизләтү турындагы үтенечләр, вакытлыча тоту үзәгендә озак тотуга карата шикаятьләр тәшкил итте.

Әлеге хәлне исәпкә алып, узган елның май аенда Вәкаләтле вәкил чит ил гражданнарын вакытлыча тоту үзәге базасында прокуратура, вакытлыча тоту үзәге җитәкчелеге һәм суд приставлары хезмәте вәкилләре катнашында берничә чара оештырды. Үткәрелгән уртак эшнең нәтиҗәсе – вакытлыча тоту үзәгендә ике айдан артык тотылган Үзбәкстан Республикасының 15 гражданын Россия Федерациясеннән чыгарып җибәрү буенча суд приставлары хезмәте кабул иткән чаралар.

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматлары буенча, үткәрелгән чаралар нәтиҗәсендә Төрекмәнстан Республикасының 13 гражданына, шул исәптән 5 айдан артык вакытлыча тоту үзәгендә булганнарына да Төрекмәнстан Генераль Консуллыгының Вербаль нотасы нигезендә, Россия Федерациясендә COVID-19 вакцинациясе үткәрелде һәм аларны Россия Федерациясеннән чыгарып җибәрү буенча чаралар күрелде.

Мәҗбүри тоту урыннарында кеше хокукларын яклау мәсьәләләре элеккечә үк, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты контролендә кала.

4.3. ХӨКЕМ ИТЕЛГӘННӘРНЕ ҺӘМ ИРЕКТӘН МӘХРҮМ ИТҮ УРЫННАРЫННАН АЗАТ ИТЕЛГӘН ЗАТЛАРНЫ ТОРМЫШКА ЯРАКЛАШТЫРУ

Кеше хокукларын саклауның мөһим юнәлеше һәм дәүләтнең хәзерге сәясәтенең актуаль проблемаларының берсе – хөкем ителгәннәрне һәм ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны тормышка яраклаштыру.

Ел саен меңләгән кеше ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителә. 2022 елның 9 аенда төзәтү учреждениеләреннән 2,9 мең хөкем ителгән кеше чыгарылган.

Әлеге бурычның актуальлеге җинаятьләр кылган затларның яртысы диярлегенә хөкем карары юкка чыгарылмау белән билгеләнә. Бу яктан наркотик матдәләр әйләнеше өлкәсендә җинаятьләр кылган хөкем ителүчеләрнең югары проценты (хөкем ителүчеләрнең гомуми саныннан 16 проценттан артыгы) игътибарны җәлеп итә. Шул ук вакытта хөкем ителгән һәр өченче кеше исерек хәлдә яки психоактив матдәләр тәэсирендә җинаять кылган.

Хөкем ителүчеләр җәзаны үтәгән чорда җәмгыять белән социаль файдалы элемтәләрне кире кайтарырга кирәк, һәм рецидив тәртипкә китергән сәбәпләрне бетерергә кирәк дип санап, Вәкаләтле вәкил тарафыннан төзәтү колонияләрендә җәза үтәүче затларга һәм ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән гражданнарга ярдәм итүгә юнәлдерелгән иҗтимагый оешмалар проектларын яклау эше дәвам иттерелде.

Аерым алганда, Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Россия Җәзаларны үтәтү хезмәтенең 16 номерлы медицина часте, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм прокуратура органнары һәм Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 19 нчы төзәтү колониясе, 2 нче төзәтү колониясе белән берлектә, республиканың төзәтү учреждениеләрендә махсус оештырылган «реабилитация отрядлары» базасында психоактив матдәләргә бәйлелеккә эләккән хөкем ителүчеләрне психик яктан коррекцияләү проектын гамәлгә ашыру дәвам итте.

2022 елда әлеге төзәтү учреждениеләре тоткыннары белән төзелгән «реабилитация отрядлары»нда 564 кече психотерапевтик төркем, 230 лекция, 77 тренинг һәм 800дән артык шәхси консультация үткәрелде. 80 хөкем ителгән кеше «отряд»ларда реабилитацияләү программасын узды. Узган ел ахырында реабилитация яки реабилитациядән соңгы курсны берничә дистә кеше үтте.

Тормышка яраклаштыру процессы социумда яшәүчеләрне кире кайтаруга юнәлтелгән. Үз чиратында, ирektән мәхрүм итү рәвешендәге җәзаны йомшак җәза төре белән алыштыру хөкем ителүченең адаптация этапларының берсе булып тора.

Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2022 елның 1 декабренә булган мәгълүматларына караганда, Россия Федерациясе законнары нигезендә 2471 хөкем ителүче суд карары буенча ирektән мәхрүм итүне мәҗбүри эшләргә алыштырырга хокуклы һәм киләчәктә җәза үтәү өчен төзәтү үзәкләренә җибәрелергә мөмкин.

2030 елга кадәр җинаять-башкару системасын үстерү концепциясе нигезендә төзәтү үзәкләре челтәрен бурычларның берсе буларак киңәйтү хөкем ителүчеләрне тормышка яраклаштыруга ярдәм итә, дип саныйбыз.

Хәзерге вакытта республика территориясендә Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 350 урынлы 1 нче төзәтү үзәге, 50 ир-атка исәпләнгән, 2021 елда «КВАРТ» АҖ тулай торагы базасында төзелгән беренче үзәк участогы, шулай ук Россия Җәзаларны үтәтү хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 4 нче төзәтү колониясе каршында төзәтү үзәге буларак эшләүче участок бар (Түбән Кама шәһәре), анда 100 хөкем ителүчене урнаштыру мөмкин.

Төзәтү үзәкләрендә исәптә торучы 459 хөкем ителүченең 454е төрле милек формалары булган 28 эш бирүчедә хезмәткә җәлеп ителгән.

Үз чиратында, хөкем ителгәннәрнең тиешле категориясен тагын да киңрәк хезмәткә җәлеп итү бурычын билгеләгәндә, хөкем ителүчеләргә лаеклы хезмәт хакы алу гарантияләнергә тиеш, ул зыянны каплау, алиментларны, штрафларны яки

башка мөлкәти түләтүләр өлешендә эзләтеп алучыларның таләпләрен тизрәк канәгатьләндерергә мөмкинлек бирәчәк.

Әйтик, хезмәт хакы бирүне югарырак дәрәҗәдә оештыруда ярдәм итү мәсьәләсе буенча Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе төзәтү учреждениеләрендә җәзаларны үтәтү мәсьәләләре буенча хокукый ярдәм көне үткәрү кысасында, Вәкаләтле вәкилнең урынга чыгып кабул итүе вакытында, узган елның май аенда Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 1 нче төзәтү үзәгендә җәза үтәүче хөкем ителүчеләр мөрәҗәгать итте. Эш бирүче хөкем ителүчеләргә Россия Федерациясендә яшәү минимумы (13793 сум) күләмендә хезмәт хакы түләгән.

Һичшиксез, төзәтү үзәкләре хакимиятенең хөкем ителгәннәрне хөкем ителгәннәр хезмәтеннән файдаланучы оешмаларда яшәү минимумы күләмендә түләнә торган мәҗбүри эшләргә урнаштыруы гамәлдәге законнарны бозу булып тормый. Үз чиратында Татарстан Республикасында 2021 елның 24 декабрендә Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе, Татарстан Республикасы Эш бирүчеләр берләшмәләренең координация советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелгән Татарстан Республикасында минималь хезмәт хакы турында килешү гамәлдә, аның нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә эшләүче хезмәткәрләр өчен минималь хезмәт хакы, федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджетлардан финанслана торган оешмалар хезмәткәрләреннән тыш, 2022 елның 1 гыйнварыннан аена 16,7 мең сум күләмендә билгеләнгән.

Хөкем ителүченең мәҗбүри эшләргә хезмәт хакы дәүләт керемен тотылганнан соң башкарма документлар буенча башка дәгъвалар чыгымнарын да капларга тиеш дип санап, Вәкаләтле вәкил Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, хөкем ителгәннәрне мәҗбүри эшләргә эшкә урнаштырырга әзер булган оешма белән килешү төзегәндә, аның үз ихтыяҗларына булган чыгымнарын капларга, 2021 елның 24 декабрендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында теркәлгән, Татарстан Республикасы Профсоюзлар федерациясе, Татарстан Республикасы Эш бирүчеләр берләшмәләренең координация советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелгән Татарстан Республикасында минималь хезмәт хакы түләү турында килешүгә кушылырга тәкъдим итә.

Мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга Россия Федерациясенең җинаять, җинаять-башкару һәм башка законнары белән билгеләнгән чикләүләр белән Россия Федерациясе гражданнарының хокуклары һәм ирекләре гарантияләнә. Әлеге категория гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау эшчәнлеге дәвам итәчәк.

Бүлек 5. КЕШЕ ХОКУКЛАРЫН САКЛАУ ҺӘМ ЯКЛАУ МАКСАТЛАРЫНДА НӘТИҖӘЛЕ ХЕЗМӘТТӘШЛЕК

5.1. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА КЕШЕ ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛНЕҢ ХАЛЫКНЫ ХОКУКЫЙ АГАРТУ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Хокукый агарту – гражданнарга үз хокукларын һәм үзләрен, җәмгыятьнең башка әгъзаларын, социаль кыйммәтләрне хөрмәт итеп, җәмгыятьтә, дәүләттә реаль мөмкинлекләрен күрсәтү ысулы. Беренче чиратта, хокукый агарту дәүләт хакимияте органнары тарафыннан башкарылырга тиеш.

Вәкаләтле вәкил эшчәнлегендә кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре өлкәсендә хокукый агарту мөһим юнәлешләрнең берсе булып тора. «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2000 елның 3 мартындагы 95-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Вәкаләтле вәкилнең төп бурычларыннан берсе – кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре, аларны яклау формалары һәм ысуллары өлкәсендә хокукый агартуга ярдәм итү.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: халыкны хокукый агарту буенча Вәкаләтле вәкил эшчәнлеге, профильле белем бирү процессын оештыру һәм җәмгыятьтә тиешле хокукый белемнәр тарату өчен җаваплы дәүләт органнары эшчәнлеген алыштырмый, әмма аны тулыландыра. Бүген социаль үзгәртеп коруларның зур темплары, хокукый мөнәсәбәтләрнең прогрессив катлауланулары, хокукый агарту, тәрбия һәм мәгарифне мәгълүматлаштыру һәм цифрлаштыру процесслары арту сәбәпле, актуаль булып кына калмыйлар, яңа яңгыраш та алалар.

Гомумән алганда, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең соңгы берничә елда эшләү тәҗрибәсе цифрлаштыруның омбудсменның республика халкы белән элемтә каналларын киңәйтүен, кире элемтәне тизләтүен һәм гадиләштерүен, хокукый агарту, шулай ук мәгълүматларны төбәкара һәм халыкара дәрәҗәдә оператив алмашу мөмкинлекләрен киңәйтүен күрсәтә.

Бу 10 елдан артык эшләп килүче «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы), ул интернет челтәрен (Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы яки «Халык контроле» мобиль кушымтасы аша) кулланып, халыкның төрле өлкәләрендәге проблемалары хәбәрдарлыгын тәкъдим итә һәм гражданнарның башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү механизмын тәэмин итә. 2021–2022 елларда «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы һәм «Бергә хәл итәбез» Россия Федерациясе дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының (функцияләр) кире элемтә платформалары интеграцияләнде, ул Россия Федерациясенең күпчелек төбәкләрендә төбәк белән идарә итү үзәкләре кире элемтәнең төп платформасына әверелде.

2022 елда гражданнарны хокукый агарту максатларында Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты тарафыннан даими эш формаларын гамәлгә ашыру дәвам итте.Болар:

- инвалид балаларның ата-аналары өчен Вәкаләтле вәкил каршындагы Хокукый белемнәр мәктәбе дәресләре;
- «Өченче буын» университеты студентлары өчен Вәкаләтле вәкил каршындагы Хокукый белемнәр мәктәбе дәресләре;
- Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе карамагындагы төзәтү учреждениеләрендә хокукый ярдәм көннәре;
- «Кеше хокуклары бердәм дәресе» бөтенроссия акциясе кысасында чаралар;
- тематик «кайнар элемтәләр»;
- Казан дәүләт медицина университеты студентлары өчен лекцияләр үткәрү;
- массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү: интервью һәм видеорепортажлар.

2020 елдан инвалид балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) өчен Хокукый белемнәр мәктәбе социаль проекты гамәлгә ашырыла. Шулай, төрле элемтә платформаларын (Zoom, Яндекс.Телемост, Труконф һ. б.) кулланып, 2022 елда түбәндәге темалар буенча 7 дәрес үткәрелде:

- «Татарстан Республикасында балаларның җәйге ялын һәм сәламәтләндерүне оештыру»;
- «Мирас хокукы»;
- «Медик-социаль экспертиза узу»;
- «Нотариаль теркәү»;
- «Интернет челтәрендә куркынычсызлык».

Әлеге дәресләрнең максаты – ата-аналар өчен хокукый агарту лекцияләре, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләре белән очрашулар уздыру һәм гомуми максатлар һәм омтылышлар белән берләшкән инвалид балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) бергәлеген булдыру. Хәзерге вакытта мәктәп чатларында 300дән артык кеше бар, алар дәресләргә керә ала. Һичшиксез, гавами процессларның гомум цифрлашуы компьютерларны, «Интернет» челтәрен һәм заманча мәгълүмат технологияләрен үзләштерүдә кыенлыклар кичергән гражданнар өчен өйрәтү һәм белем бирү чараларын үткәрү белән бергә алып барылырга тиеш.

«Өченче буын» университеты студентлары өчен Вәкаләтле вәкил каршындагы Хокукый белемнәр мәктәбе дәресләре традиция буенча уку елы кысасында үткәрелә, 2022 елга туры китереп, ике уку елының ике яртыеллыгын – 2021/2022 һәм 2022/2023 үз эченә алды.

2022 елның беренче яртысында видеоэлемтәнең төрле формаларын кулланып, 5 дәрес үткәрелде. «Өченче буын» университеты студентларына дәресләрдә гражданнарның сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә хокукларын тәэмин итү, мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендә гражданнарның хокуклары, торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре: гомум йорт мөлкәте, күпфатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрү һәм башкалар турында сөйләделәр.

Яңа уку елында «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеге һәм Татарстан Республикасында халыкка түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында», «Пенсия белән тәэмин итү өлкәсендә гражданнарның хокукларын яклау», «Өлкән яшьтәге гражданнарга социаль хезмәтләр күрсәтү (социаль хезмәт күрсәтү)» темалары буенча 3 дәрес үткәрелде, шулай ук «Казаноргсинтез» җәмгыятенә экскурсия планлаштырыла.

Берничә ел дәвамында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының «Парламент дәресе» уртак проекты уңышлы тормышка ашырыла. 2022 елда «Мин – гражданин! Минем хокукларым һәм бурычларым» дигән темага дәрес Татарстан Республикасы Конституциясен кабул итүгә 30 ел тулуга багышланган иде, аның кысасында Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Сәрия Сабурская «Гражданның конституциячел хокуклары һәм бурычлары» дигән доклад белән чыгыш ясады.

Ел саен Вәкаләтле вәкил Аппараты тарафыннан уздырыла торган «кайнар элемтә»ләргә шалтыратучылар саны кимеми, түләүсез юридик ярдәм күрсәтүнең әлеге форматына ихтыяҗ зур булуын һәм алдагы чорларда мондый элемтәләрне оештыру эше дәвам иттереләчәген раслый.

2022 елда Вәкаләтле вәкил Аппаратында мәнфәгатьле ведомстволар катнашында 8 «кайнар элемтә» үткәрелде, алар барышында республика һәм илнең башка төбәкләреннән 409 шалтырату булды:

Үткәрү көне	«Кайнар элемтә» темасы	Шалтыратучылар саны
02.03.2022	«Хатын-кызлар сораву»: хатын-кызлар сәламәтлеге, балаларны белем бирү учреждениеләренә урнаштыру, балалы гаиләләргә социаль ярдәм, пенсия белән тәэмин итү, торак-коммуналь өлкә, гаилә-көнкүреш низагларыннан саклау, хезмәт хокуклары үтәү мәсьәләләре	31
26.04.2022	«Хатын-кыз соравы»: бала карау буенча ялда булган хатын-кызларның актуаль сораулары турында	16
10.06.2022	Балаларның җәйге ялын һәм сәламәтләндерүне оештыру мәсьәләсе	42
23.08.2022	Торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре	65
29.09.2022	Гражданнарның белемгә хокукын яклау	84
01.10.2022	Өлкән яшьтәге гражданнарның хокукларын яклау	50
09.12.2022	Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле гражданнар хокукларын яклау мәсьәләләре	114
22.12.2022	Гражданнарның хезмәткә хокукларын яклау мәсьәләләре	7

Һичшиксез, халыкны хокукый агарту кысасында Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратының нәтиҗәле эшен гавами хакимият органнары, коммерциячел булмаган оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка оешмаларның тыгыз хезмәттәшлегеннән башка төзү мөмкин түгел. Татарстан омбудсмены тарафыннан төрле иҗтимагый оешмалар белән 50дән артык килешү төзелгән.

Мәсәлән, Татарстан Республикасы Адвокатлар һәм Нотариуслар палаталары белән төзелгән килешүләр нигезендә халыкка түләүсез юридик ярдәм күрсәтү максатларында 2022 елда әлеге ведомство белгечләре тарафыннан ай саен гражданнарны кабул итү оештырылды. Ел дәвамында барлыгы 24 кабул итү уздырылды һәм 100дән артык граждан кабул ителде.

Уртак социаль проектларның зур тарихы бар. 2022 елның августында «Сообщество» социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар өчен V республика форумы кысаларында Вәкаләтле вәкил Аппараты тарафыннан җәмәгатьчелек ярдәмчеләре һәм коммерциячел булмаган оешмалар вәкилләре өчен семинар оештырылды. Әлеге очрашу Татарстан Республикасында омбудсмен институтының төп программа документы – 2014 елда безнең төбәктә (гомумән илдә) беренче тапкыр кабул ителгән һәм хәзер 2028 елга кадәр озайтылган Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Стратегиясе гамәлгә ашыру чаралары планын үтәү максатыннан да оештырылды.

Халыкара кеше хокуклары көнен (10 декабрь) һәм Россия Федерациясе Конституциясе көнен (12 декабрь) бәйрәм итү кысаларында, 2022 елның декабрендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы ярдәмендә Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында Кеше хокуклары буенча бердәм дәрес үткәрелде, ул «Россия Федерациясендә Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 1997 елның 26 февралендәге 1-ФКЗ номерлы федераль конституциячел законга кул куелуның 25 еллыгына туры китерелде һәм 167819 укучы өчен 1256 гомуми белем бирү оешмасында үткәрелде.

Кеше хокуклары буенча бердәм дәрестә 9000нән артык педагог укучыларның игътибарын Россия Федерациясе Конституциясенә, Бала хокуклары турында Конвенциясенә, Кеше хокуклары декларациясенә һәм Кеше хокуклары өлкәсендә башка халыкара һәм милли норматив актларның төп нигезләмәләренә юнәлтте. Укучылар кеше хокукларын яклауның гамәлдәге системасы, Россия Федерациясендә һәм Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил институты белән таныштылар.

2022 елның 10 декабрендә Түбән Кама шәһәренең «10 нчы урта гомумбелем мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе базасында Түбән Кама районы мәктәпләренең социаль-иҗтимагый юнәлеше укучылары өчен Кеше хокуклары буенча шәһәр турниры үткәрелде. Җюри рәисе, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Түбән Кама муниципаль районында җәмәгатьчелек ярдәмчесе Ч.А. Ульданова укучыларның югары белем дәрәҗәсен билгеләп үтте. Укучылар хокукый хәлләргә хокукый бәя бирү һәм хокукый төшенчәләрне ачу сәләтен генә түгел, ә алар алдына куелган бурычларны хәл итүгә иҗади якын килүләрен дә күрсәттеләр. Чара Кеше хокуклары көненә «Барлык кешеләр дә тигез» лозунгы астында узды.

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгатьчелек ярдәмчесе О.И. Гречко катнашында «Минем хокукларым һәм бурычларым» мәктәп парламенты фракцияләре утырышы Казан шәһәре Идел буе районының 139 нчы гимназиясендә узды.

Казан шәһәре Идел буе районының «83 нче лицей – мәгариф үзәге»ндә Кеше хокуклары буенча бердәм дәрес үткәрүдә Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Экспертлар советы әгъзасы һәм вәкилнең җәмәгатьчелек ярдәмчесе Г.Г. Балафендиева катнашты.

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил С.Х. Сабурская Казан шәһәре Совет районының 187 нче күп профильле лицеенда һәм Казан шәһәре Вахитов районының 39 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбендә Кеше хокуклары буенча бердәм дәрес үткәрде.

2022 ел Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миннеханов указы белән Цифрлаштыру елы дип игълан ителде. Бүгенге дөньяда мәгълүмат таратуның иң уңайлы һәм җайлы ысулы – социаль челтәрләр. Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил «ВКонтакте» (https://vk.com/sariyasaburskaya,https://vk.com/club193048141),«Одноклассники» (https://ok.ru/u.popravamchelovekavt, https://ok.ru/group/60702086135920), социаль челтәрләрендә, шулай ук үзенең (https://t.me/tat_ombudsman) телеграмм-каналында битләр алып бара.

2022 елда күрсәтелгән өч социаль челтәр мәйданчыкларында, шулай ук Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең рәсми сайтында 300 дән артык материал бастырып чыгарылды. Социаль челтәрләрдә көн саен гамәлдәге законнарга һәм яңалыкларга аңлатмалар бастырыла, алар халык арасында уңай бәяләнә.

5.2. ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛ ИНСТИТУТЫНЫҢ ҖӘМӘГАТЬ ХАКИМИЯТЕ ОРГАННАРЫ ҺӘМ ГРАЖДАНЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ ИНСТИТУТЛАРЫ БЕЛӘН ҮЗАРА ХЕЗМӘТТӘШЛЕГЕ

Үз чараларын гамәлгә ашырудан тыш, Вәкаләтле вәкил социаль проектларны гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтә.

Мәсәлән, 2022 елда Президент грантлары фондына, граждан җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы грантларын бирү буенча республика комиссиясенә, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм буенча Республика ресурс үзәгенә Татарстан Республикасы һәм илнең башка төбәкләрендә яшәүчеләрнең хокукларын һәм ирекләрен яклауга юнәлдерелгән иҗтимагый нәтиҗәле 16 партнер – оешмаларга ярдәм итүне сораган хатлар җибәрелде.

2022 елда торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә җәмәгатьчелек контроле төбәк үзәге белгечләре белән берлектә (башкарма директоры – Д. С.Романов) түбәндәге чаралар үткәрелде:

Торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә түләүсез консультация ярдәме күрсәтелде. Күпфатирлы йортларда яшәүчеләрдән дә, шәхси секторда да 2022 елда торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә җәмәгатьчелек контроле төбәк үзәгенә 1670 мөрәҗәгать керде. Халык мөрәҗәгатьләре буенча Вәкаләтле вәкил Аппараты вәкилләре белән берлектә җәмәгать торак тикшерүләре үткәрелде. 2022 елгы мөрәҗәгатьләрнең иң актуаль темалары – торак-коммуналь хезмәтләр өчен исәпләүләр буенча хокук бозулар (19%), сыйфатсыз коммуналь хезмәтләр (10%) һәм күпфатирлы йортларны тиешенчә карап тотмау (10%).

Торак-коммуналь хуҗалыгы, торак фонды белән идарә итү, торак-коммуналь хезмәтләрне куллану өлкәсендә гражданнарның хокуклары буенча укыту чаралары үткәрелде – хакимият һәм идарә органнары өчен барлыгы 28 семинар үткәрелде. Хисап елында, торак буенча хокукый агарту кысаларында, 1000гә якын кеше укыды. Идарәче оешмалар эшчәнлегеннән канәгать калуны арттыру максатыннан, идарә оешмалары өчен укыту семинарлары үткәрелде, халык мөрәҗәгатьләре белән эшләү кагыйдәләре, күпфатирлы йорт советлары активистлары һәм әгъзалары белән диалогны җайга салу кирәклеге аңлатыла. Белгечләрнең барлык тикшерүләре һәм семинарлары идарә оешмалары белән үзара хезмәттәшлекне яхшыртуга, гражданнарның хокукларын торгызуга ярдәм итүгә юнәлдерелгән.

2022 елда торак-коммуналь хуҗалыгының иң актуаль мәсьәләләре буенча онлайн-сораштырулар һәм мониторинглар үткәрелде, аларның нәтиҗәләре хакимият органнарына тапшырылды, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил сайтында һәм социаль челтәрләрдә урнаштырылды, массакүләм мәгълүмат чаралары аша республика халкына җиткерелде. Барлыгы 5 онлайн сораштыру һәм мониторинг үткәрелде. Күпфатирлы йортларны җылыту һәм тоту буенча онлайн-сораштырулар – 2021-2022 елларның кышкы чорында кардан чистарту сыйфаты, 2021–2022 елларда торак-коммуналь хезмәтләр тарифлары, капиталь ремонт тору (агымдагы ремонт кирәклеге), каты көнкүреш калдыклары белән эш итүнең сыйфатына кагылды. Сораштыру нәтиҗәләре уңай һәм куркынычсыз яшәү шартларын тәэмин итү буенча чаралар күрү өчен тиешле органнарга һәм оешмаларга җибәрелде.

Үзәк һәм Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты белгечләре Татарстан Республикасы дәүләт Торак инспекциясе белән берлектә Ачык ишекләр көнендә кабул итүләр оештырдылар.

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил «Яңа гасыр» автоном хәйрия коммерциячел булмаган оешмасы (генераль директоры – Л.А.Таишева) белән берлектә Татарстанда һәм Идел буе федераль округының 5 төбәгендә үткәрә торган «Җиңү өчен тест. Ярдәм янәшә» уртак проекты кысаларында түбәндәге чаралар оештырылды:

3 мобиль медицина комплексының мультисциплинар команда белән урыннарга чыгуы (Вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләреннән тыш, социаль, медицина хезмәткәрләре, психологлар, волонтерлар да бар иде). «Тест-мобиль» базасында ВИЧ, С вирусы гепатитына бушлай экспресс-тест узарга, кан басымын, пульсны һәм канның кислородка туенуын үлчәргә мөмкин иде.

Аның максаты – кешеләрне сәламәтлекне саклау тәртибенә өйрәтү, сәламәтлекне даими тикшереп тору, социаль әһәмиятле авыруларга тест үткәрү. Урынга чыгу вакытында Вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итү мөмкинлеге турында 230дан артык кешегә, шул исәптән мобилизацияләнүчеләрнең туганнарына хәбәр ителде. «Тест-мобиль» дә өч тапкыр урынга чыгу барышында 90 кеше консультация алды.

«МАХСУС БАЛАЛАР» автоном коммерциячел булмаган оешмасы (җитәкчесе – С.А.Салихова) белән Вәкаләтле вәкил 2020 елдан бирле эшли. Әлеге проектның төп максаты – балалар белән эшләүдә үз-үзеңне тотышны гамәли анализлауның нәтиҗәле методикаларын турыдан-туры куллану исәбенә аутизм белән чирле балаларны өйрәтү, абилитацияләү һәм үстерүнең уңышлы тәҗрибәләрен тарату, шулай ук белем һәм күнекмәләрне башка белгечләргә: педагогларга, психологларга, тьюторларга, волонтерларга, социаль хезмәткәрләргә һәм башкаларга тапшыру.

2021 елның 10 декабреннән Вәкаләтле вәкил белән партнерлыкта оешма тарафыннан үзенчәлекле балалар белем ала торган мәгариф учреждениеләре педагоглары өчен «Чиксез Казан» толерантлык тренинглары сериясе оештырылды.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты һәм Казан шәһәре мәгариф идарәсе ярдәме белән тренинглар аудиториясен киңәйтү һәм аңа беренче чиратта балалар белән эшләүче педагог-белгечләрне кертү турында карар кабул ителде. Тренинг нәтиҗәләре буенча педагоглар үз сыйныф укучылары өчен шундый ук толерантлык тренинглары үткәрүгә әзерләнде.

Проектны гамәлгә ашыру вакытында 45 мәктәптән 589 педагог өчен семинарлар үткәрелде. «Чиксез Казан» проекты кысаларында «Дружелюбный мир» балалар рәсем бәйгесе һәм иң яхшы инклюзив чараларга бәйге үткәрелде. Анда «Чиксез Казан» тренингында катнашучылар чакырылды, җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил С.Х. Сабурская һәм Казан шәһәре башкарма комитетының мәгариф идарәсе башлыгы И.А. Ризванов алып барды.

2022 елның сентябреннән «МАХСУС БАЛАЛАР. ТАТАРСТАН» коммерциячел булмаган оешмасы «Үзенчәлекле баланы ничек үстерергә?» проектын тормышка ашыра.

Проектның төп бурычы – Татарстан Республикасында яшәүче аутизм белән авыручы бала диагнозы белән беренче тапкыр очрашкан ата-аналарга мәгълүмати ярдәм күрсәтү. Проект «Татнефть» җәмгыятенең «Халыкның зәгыйфь катлауларын яклау» номинациясендә җиңгән грантын кулланып гамәлгә ашырыла.

2022 елның 23 сентябрендә без бергәләп балаларга һәм аларның гаиләләренә хокукларны яклау һәм дәүләт ярдәме, аутизм авырулы балаларга социаль күнекмәләр һәм гигиена күнекмәләрен өйрәтү темасы буенча программада катнашучылар өчен семинар үткәрдек. Семинар Татарстан Республикасы Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы вәкилләре катнашында узды. Семинарларны онлайн һәм язмада 60тан артык кеше карады.

Октябрь аенда Татарстан Республикасының эре шәһәрләрендә: Казан, Әлмәт һәм Яр Чаллы шәһәрләрендә белгечләрнең күчмә гамәли семинарлары һәм консультацияләре узды. Ике көн дәвамында гамәли тәртип анализы (ПАП) белгечләре, психиатр ата-аналар өчен теоретик-практик тренинглар һәм аутизм авырулы балалар өчен турыдан-туры консультацияләр үткәрделәр.

2023 елның апрелендә Әлмәт, Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләрендә күчмә гамәли семинарлар һәм консультацияләр планлаштырыла.

Проектны тормышка ашыру нәтиҗәсендә балалар тормышның беренче этапларында нәтиҗәле ярдәм ысулларына ия булган белгечләрдән үзвакытында квалификацияле ярдәм алачаклар. Күпләр өчен бу тулы абилитация дигәнне аңлатачак, калганнар өчен үсештә гадәттәгедән күпкә сизелерлек алгарыш.

Аутизм авыруы булган балаларның ата-аналары үсеш үзенчәлекләре булган балаларына коммуникация һәм ярдәм күрсәтү күнекмәләрен алачаклар, үзенчәлекле балалар үсешенең уңыш нигезе булып торган психологик халәтләрен яхшыртачаклар. Гаиләләр дәүләт ярдәме чаралары сорап мөрәҗәгать итә һәм аларны тулы күләмдә ала алачак.

Проект аутизм авырулы балалары булган гаиләләрдән торган җәмгыять үсешенә, аутизм мәсьәләләре буенча ышанычлы белгечләргә мөрәҗәгать итүгә, шулай ук аерым гаиләләргә ярдәм итүче коммерциячел булмаган оешмалар берләшмәсен үстерүгә, шулай ук тиешле дәүләт ведомстволары белән мондый авырулы балаларның ата-аналары арасындагы хезмәттәшлекне яхшыртуга өстәмә этәргеч бирәчәк.

Татарстан Республикасы Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил шулай ук инвалид балаларның һәм 18 яшьтән өлкәнрәк инвалид балаларның ата-аналарының Бөтенроссия оешмасының төбәк бүлеге (җитәкчесе – Ж.В.Халтурина) белән актив хезмәттәшлек итә.

Төбәк бүлеге «Гаилә кабул итү бүлмәсе» кысаларында зур эш алып бара. Бөтенроссия оешмасының төбәк бүлеге гаилә кабул итү хезмәте – балаларны һәм инвалид булган өлкәннәрне тәрбияләүче гаиләләр социаль ярдәм һәм консультацияләр, мәсәлән, инвалидлыкны рәсмиләштерү, реабилитация һәм абилитация, мәгариф һәм социаль яклау проблемалары буенча мөрәҗәгать итә ала торган хезмәт.

Мәсәлән, «Гаилә кабул итү бүлмәсе» кысаларында без Казан шәһәреннән килгән С. инвалид баласы булган әнигә (Ульяновск өлкәсендә теркәлгән) 2021 елның 26 маендагы № 151-ФЗ федераль закон нигезендә, ялгыз ата-анага тиешле пособие билгеләүдә ярдәм иттек.

Баш тарту сәбәбен Россия Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча идарәсе «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181- ФЗ номерлы федераль законның 11 нче маддәсе нигезендә мөстәкыйль сатып алынган техник тернәкләндерү чаралары өчен компенсация гаиләнең җан башына туры килгән уртача кеременнән артып китүе белән дәлилли. РФ законнары нигезендә, инвалидларны техник тернәкләндерү чаралары белән тәэмин итү хокукы федераль бюджет акчалары исәбеннән гарантияләнә. Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эше нәтиҗәсендә күрсәтелгән пособие алуга мөрәҗәгать итү хокукы торгызылды. Инвалид баланың әнисенә пособие аның Пенсия фондының Татарстан буенча идарәсенә мөрәҗәгать иткән көненнән түләнгән.

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ярдәме белән Казан шәһәреннән инвалид баланың (15 яшь) әнисе К.га ярдәм күрсәтелде, аңа опека органнары килешү өчен алдан рөхсәт бирүдән баш тарта, чөнки бала физик хәле аркасында мөстәкыйль рәвештә гаризага кул куя алмый, бу кресло-коляскада йөрүче бала өчен уңайлы тирәлек элементлары белән уңайлы яшәү шартлары булдыруга киртә булды. Омбудсмен ярдәме белән, РФ хөкүмәтенең «Инвалидлар ихтыяҗын исәпкә алып, күпфатирлы йортта торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне җайга салу чаралары турында» 2016 елның 9 июлендәге 649 нчы карары нигезендә, Казан шәһәреннән күпбалалы гаилә кешесе П.ның торакны инвалид балалары өчен яраксыз дип тану хокукы торгызылды. Нәтиҗәдә мөрәҗәгать итүче торагы инвалидлар яшәү өчен яраксыз дип табылды.

Эш барышында инвалидларның торагын яшәү өчен яраксыз дип тану хезмәтенең этапларын билгели торган төгәл регламентның булмавы ачыкланды, шуның нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүче Ф. 6 айдан артык үз мөрәҗәгате буенча нәтиҗәгә ирешә алмады. Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан РФ хөкүмәтенең 2016 елның 9 июлендәге 649 нчы карары нигезендә торакны инвалидлар яшәү өчен яраксыз дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтү регламентын билгеләү буенча Казан шәһәре Совет районы хакимиятенә тәкъдимнәр әзерләнде һәм җибәрелде.

